ЯНӘШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

№03 (398)
МАРТ 2025

1920 ЕЛДАН НӘШЕР ИТЕЛӘ

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

ТРАДИЦИЯЛӘРНЕ САКЛАУЧЫ

ӨЧЕНЧЕ МЕҢЬЕЛЛЫК ХАТЫН-КЫЗЫ ТУРЫНДА

4 612750 670011

АКАДЕМИК

ЖИЛОЙ КОМПЛЕКС

Уңайлыкның иң югары дәрәҗәсе



Премиум-класслы торак комплексы

akademikdom.ru сайтында фатир сайлагыз



Академик ТК – гармония хөкем сөргән урын

- шәһәрнең үзәк районы
- авторлык архитектурасы
- үзгә планлаштыру
- пыяла кирпечтән эксклюзив фасад

+7 (843) 590-83-83
Сату бүлеге: Казан ш., Әмәт магистрале, 18, 1 к
Эш сәгатьләре: дшм. – җом.: 9:00 – 18:00

РЕКЛАМА. Застройщик: ООО «Специализированный застройщик «АСД-2»». ИНН1686027870. Представленная информация носит исключительно ознакомительный характер, ни при каких обстоятельствах не является публичной офертой, определяемой положениями статьи 437 ГК РФ. Построенные объекты могут отличаться от представленных 3Э-визуализаций, изображений. Все представленные материалы, изображения являются ориентировочными, в них могут быть внесены любые изменения и дополнения. Срок завершения строительства IV кв. 2027 г. Проектная декларация №16-002062 от 25.12.2024 на сайте наш.дом.рф.

№03 (398)
МАРТ 2025

16+

Редакция:
Адрес: 420066, Россия,
Татарстан Республикасы,
Казан, Декабристлар ур., 2,
тел. (843) 222-09-79
tatarstan@tatmedia.com

Баш мөхәррир: Татьяна Николаевна Вафина, vafina@tatmedia.com
Шеф-редактор: Әскәр Сабиров, sabirov@tatmedia.com
Баш мөхәррир урынбасары: Фәридә Әхмәтҗанова
Әдәби мөхәррир: Луиза Янсуар
Бүлек мөхәррирләре: Руфия Фазылова, Николай Коновалов, Евгения Чеснокова, Дмитрий Сивков
Авторлар: Айдар Шәйхин, Ольга Туманская, Наилә Хәйретдинова
Фотографлар: Александр Ефремов, Антон Катушонок, Ната Смирнова
Дизайн-макет: Олег Бурилов
Вёрстка: Анастасия Хатыйпова
Препресс: Игорь Глушков
Корректор: Айсылу Корманова
Тышлыкта: Рима Сафиуллова. Александр Сафронов фотосы. Тышлыгыбыз героинясы «Милли хәситә» тарафыннан бирелгән Казан сәүдәгәр хатыннары киеменнән

Журнал 1920 елдан нәшер ителә
1977 елда Халыклар дуслыгы ордены белән бүләкләнә

ММЧ исеме: ТАТАРСТАН TATARSTAN

Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәттә теркәлгән. Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС 77 – 66045, 10.06.2016.

Тираж:
2 400 данә
Бәясе ирекле

Редакциянең язма рөхсәтеннән башка «Татарстан» журналындагы материалларны күчереп бастыру тыела. Күчереп бастырганда, журналның исемен күрсәтү мәҗбүри. Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Реклама материалларының эчтәлеге өчен редакция җавап бирми.

«Татарстан» журналы шулай ук рус телендә 2350 данә тираж белән чыга.
Гомуми тираж: 4750 данә.
Реклама 16+

Журнал «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы типографиясендә басылды. Адрес: 420066, Россия, Татарстан Республикасы, Казан, Декабристлар ур., 2

Заказ №: М-0306
Басарга кул куелды: 13.03.2025
Чыгу көне: 18.03.2025

Коммерция директоры:
Рәшит Хәйретдинов,
тел.: (843) 222-09-76, +7-9600-487-900
Коммерция директоры урынбасары:
Алина Майорова,
тел.: (843) 222-09-76, +7-9033-132-741
Дистрибуция һәм трафик бүлеге җитәкчесе:
Ирина Захарова, irinamoroz10@mail.ru
Бухгалтерия:
Ольга Басаркина, тел.: (843) 222-09-80

РЕДАКЦИЯДӘН

«ТАТАРСТАН»ның 105 НЧЕ ЯЗЫ

«Татарстан» журналы язны 104 мәртәбә каршы алды инде. Һәм ул яз ел саен – төрле. Зәмһәрир суык вакытлары да булган аның, ачлыктан тилмерткән чаклары да, сугыш афәте алып килгән мизгелләре дә, Җиңү белән сөендергән онытылмас мәле дә...

Яз безне ташу сулары белән дә юган, кышкы бураннары белән дә күмгән, шау чәчәктә утырган бакчаларның башны әйләндергеч исе белән дә исерткән, җылы җилләре белән дә кочаклап төргән. Әле моңарчы билгеле булмаган сырхау белән хәвефләндергән, хәтәр китергән...

Шундый инде ул яз – үзгәрүчән, җилбәзәк, җиләс... Бер үк вакытта сагынычлы, кадерле һәм газиз дә. Кар көртләре буйлап йөгереп узып, ул аларны шаян гөрләвекләргә әйләндерә, ялангач кулы белән агачларга бер орынуы була – кәүсәләр яшелгә күмелә. Юкка гына «март аеның нечкә билле җиле сузылып ятып җиргә кар ашый» дип язмаган шагыйрь.

Ә аннан... бөтен түбә-кыеклардан песиләрнең хор коллективлары концерт бирергә керешә. Ир-егетләр исә, гүзәл затларның күз карашын гына эләктереп алып та, шигырь белән сөйли башлый. Кайчакта ак шигырь белән, әлбәттә, әмма бит монда эш рифмада түгел, ә теманы сайлый белүдә. Мәхәббәт очкынында...

Яз белән сезне, татарстанлылар!

2025 елның язы иң ямьлесе һәм тылсымлысы булсын!

Сезнең кыштан соң уянып килүче редакциягез

Редакция советы:
АЛЕКСАНДРОВСКАЯ Ирина Алексеевна
ӘХМӘТШИН Равил Кәлимуллович
БЕЛЯКОВ Роман Юрьевич
БИКЧӘНТӘЕВ Фәрит Рәфкатович
БОЛЬШАКОВ Андрей Георгиевич
ВӘЛИЕВА Зилә Рәхимҗановна
ГАЛИЕВ Марат Гадыевич
СӘЛАХОВ Мәгъзүм Хәлимуллович
ФАЗЛЫЕВА Ләйлә Ринатовна
ФӘЙЗУЛЛИН Равил Габдрахманович
ХӘКИМОВ Рафаэль Сибгатович
ХОМЕНКО Вадим Васильевич

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла

Басма Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча федераль агентлык ярдәмендә нәшер ителә

ТАТ МЕДИА

Гамәлгә куючы: «ТАТМЕДИА» АҖ
Нәшер итүче: «ТАТМЕДИА» АҖ
Адрес: 420097, Россия, Татарстан Республикасы, Казан, Академическая ур., 2

«Татарстан» журналына ТРның барлык элемтә бүлекләрендә язылырга мөмкин:
Индекс **П2381** – татар телендә ярты елга
Индекс **ПА468** – татар телендә бер елга

Индекс **П2378** – рус телендә ярты елга
Индекс **ПА471** – рус телендә бер елга

2025 елның ярты еллыгына ТР буенча язылу бәясе:
1305 сум 00 тиен китереп бирешле,
1274 сум 28 тиен соратып алганда.
2025 елга ТР буенча язылу бәясе:
2610 сум 04 тиен китереп бирешле,
2548 сум 46 тиен соратып алганда.

«Татарстан» журналына РФ буенча онлайн-язылу:
Индекс **П7077** – татар телендә
Индекс **П7076** – рус телендә

«ТАТАРСТАН» ЖУРНАЛЫНА 104 ЯШЬ

ТАТАРСТАННЫҢ 100 ҖӘҮҺӘРЕ

БАРЫ ТИК ТАТАРСТАНДА

БАТЫРЛЫК ҺӘМ САН-ФРАНЦИСКО ШӘҺӘРЕ АЧКЫЧЫ

1960 елның 7 мартында АКШ авианосецы океанда баржа белән дүрт совет
солдатын табып ала. Алар барысы да соң чиккә җитеп йончыган, ярымтере
хәлдә була. Әмма дәрәҗәсе буенча иң өлкәне, кече сержант Әсхәт Җиһаншин
американнардан бары тик азык-төлек белән солярка гына сорый…
Итуруп утравы янындагы ураган аларны дәрья култыгыннан чыгарып ташла-
ганнан соң, ачык океанда баржа 49 көн дәвамында тирбәлеп йөри. 16 кашык
ярма, бер ипи, бераз бәрәңге белән су – бортта булган бу ризык тиз арада
ашалып та бетә. Баржадагылар яңгыр суын җыеп эчә, күн каешлары белән
гармун мехларын пешереп ашый. Аннары чират кирза итекләргә җитә…
Сан-Францискода аларны каһарманнар буларак каршы алалар. Шәһәрнең
почетлы гражданнары дип игълан итәләр, каланың символик ачкычын кул-
ларына тоттыралар. Әле, шуңа өстәп, костюмнар бүләк итәләр һәм йөзәр дол-
лар акча бирәләр, АКШда калырга өндиләр. Әсхәт белән иптәшләре бу тәкъ-
димнән баш тарта…
Өйгә солдатлар «Куин Мэри» океан лайнерында кайта. СССРда дүртесен
дә Кызыл Йолдыз ордены белән бүләклиләр. Барлык бүләкләрдән дә кадерле-
се халыкның зурлавы һәм мәхәббәте була. Ул елларда совет диңгезчеләренең
даны һич кенә дә «Битлз»ныкыннан калышмый.
СССР бию мәйданнарында әле бик озак: «Зиганшин буги, Зиганшин рок. Зи-
ганшин ест сырой сапог…» - дигән юллар яңгырап тора.

© «Татарстан» журналы

WWW.PROTATARSTAN.RU

ЭЧТӘЛЕК

акыллы гамәлләр

6. Кайсы төбәктә яшәү яхшырак
Рейтинг нәрсә күрсәтте

8. Дөнья мәдәниятенә кертелгән өлеш
Ни өчен Казан 2026 елда ислам дөньясының мәдәни башкаласы итеп сайланды

10. Гасырлар хәзинәсе һәм буыннар зирәклеге
Музей артефактлары нәрсә турында сөйли

16. Дөньяның асылын аңлау сере
Ислам сәнгатенең үзенчәлеге нидә

22. Фәлсәфәчеләр, реформаторлар, мәгърифәтчеләр
Дөньякүләм ислам фәне күгенең якты йолдызлары турында

30. Демография проблемалары
Әни булу нигә куркыта

игелекле эшләр

40. Һәрвакыт бер дулкында булу
Өченче меңьеллык хатын-кызыннан бәхетле яшәү серләре

46. Үзебезнекеләрне ташламыйбыз
Яр Чаллы кызлары «Тимер» сугышчыларына ничек ярдәм итә

56. Бер яшьлектә, бер картлыкта…
Гөлфизия Камалиева ничек «Ак Барс» талисманына әверелә

60. Гамьле әңгәмә
Рузия Мотыйгуллина Камал театрын ни өчен яратуы хакында

мәңгелек кыйммәтләр

72. Бөек Җиңүнең 80 еллыгына
Беренче татар балеты ничек язылган һәм дөньяга танылган

78. Онытылмас исемнәр
Татар яшьләр матбугатына кем нигез салган

82. Китап киштәсе
Илүсә Хуҗина нинди китаплар укый

84. Афиша
Кайда нәрсә карарга

Больше материалов на сайте: protatarstan.ru

Фото: USS Kearsarge crew

Акыллы гамәлләр



14.02

Рөстәм Миңнеханов, Татарстан Республикасы Рәисе, – Яр Чаллы шәһәр советы утырышында:

« – Телләр, бигрәк тә туган телеңне белү – изге эш. Һәр кеше белергә тиеш. Һөнәри дәрәҗәдә димибез, көнкүрештә сөйләшерлек телне. Әгәр син республикада яшисең икән, көнкүрештә кулланырлык кына булса да, татар телен белергә тырыш. Бу кемгә комачаулый?

Игелекле эшләр

13.02

Ирада Әюпова, Татарстан Республикасы мәдәният министры, – Җиддәдә, 2026 елга Казан ислам дөньясының мәдәни башкаласы статусын алган XIII Ислам дөньясы мәдәният министрлары конференциясендә:

« – Төбәгебезнең ислам мәдәниятен саклау буенча Россия үзәкләренең берсе булуы белән горурланабыз. Безнең җирләр – Евразиянең ислам рәсми дәүләт дине буларак кабул ителгән иң төньяк төбәге. Ислам дине моннан мең еллар элек Идел буе Болгарстанында кабул ителгән, һәм әлеге факт Әхмәт Ибн Фадланның борынгы кулъязмасы – «Рисалә» белән раслана.

Мәңгелек кыйммәтләр



06.02

Сергей Кузнецов, Мәскәү шәһәренең баш архитекторы, – «Казаныш» форумында:

« – Бездә (Казан белән) бердәм координаталар системасы, бер кыйммәтләр системасы. Зур һәм үсештәге шәһәрләрнең, аларның булдыклы җитәкчеләренең игътибары үзәгендәге мәсьәләләр бер үк нәрсәләр – кеше капиталы өчен көрәш, әйләнә-тирә мохит сыйфатын яхшырту тирәсендә әйләнә... Шулай ук Казанның заманча архитектура Мәккәсенә әйләнүен телим. Моның өчен бөтен мөмкинлекләр дә бар.

Фото: tatar-inform.ru, prav.tatarstan.ru

игелекле эшләр

акыллы гамәлләр

мәңгелек кыйммәтләр

Бу санда тәкъдим итәбез:

Казан **кайчан** ислам дөньясының мәдәни башкаласы булып саналачак

Ислам мәдәниятендә «сәнгать» төшенчәсе **нинди** мәгънәгә ия

Гасырлар хәзинәсе һәм буыннар зирәклеге **кайда** саклана

Дөньякүләм ислам фәне, фәлсәфәсе һәм мәгърифәтчелеге күгендә **кемнәр** якты йолдыз булып яна

ТОРМЫШ СЫЙФАТЫ БУЕНЧА ТОП 10 РФ ТӨБӘГЕ*

Рейтинг 10 билгеле бер юнәлештә тормыш сыйфатын яхшырту буенча төбәк һәм федераль чаралар комплексын – Илкүләм социаль инициативаларны гамәлгә ашыру кысаларында төзелә. Юнәлешләргә медицина хезмәте белән тәэмин итү, мәгариф һәм үсеш, торак һәм инфраструктура, куллану дәрәҗәсе һәм ялны оештыру, чисталык һәм экология, инклюзия һәм тигез мөмкинлекләр, куркынычсызлык, социаль яклау, дәүләт хезмәте һәм сервислар, мәшгульлек һәм үз эшеңне ача алу керә.

Фото: ru.wikipedia.org/ Alvesgaspar, kultura-to.ru, admnvrsk.ru, Vihljun, Gummy-beer, dostop.ru, Dmitry A. Mottl, Dmitriev Stanislav, Packtrif

ГРАЖДАННАР ТОРМЫШЫ ӨЧЕН СЫЙФАТЛЫ МОХИТ БУЛДЫРУ БУЕНЧА ТӨБӘК БАШКАРМА ХАКИМИЯТЕ ОРГАННАРЫНЫҢ ТЫРЫШЛЫГЫН БӘЯЛӘҮ РЕЙТИНГЫ

Рейтингта бәяләнә торган 10 юнәлеш **140** күрсәткечне үз эченә ала. Әлеге күрсәткечләр югары булганда, төбәкнең җәлеп итүчәнлегенең яхшыруы да күтәлә. Җәлеп итүчәнлек дигәндә, без торак пункттагы тормыштан канәгать калуны, бу урынны башкаларга да яшәү өчен тәкъдим итүне, шулай ук гаилә тормышын биредә коруга әзер булуны үлчи торган социаль индексны күз уңында тотабыз.

Рейтинг төбәк статистикасы мәгълүматларын, социологик сораштырулар нәтиҗәләрен һәм геоаналитика ысулы ярдәмендә туплана торган күрсәткечләрне үз эченә ала. Ул төбәктә тормыш алып бару мохите сыйфатына комплекслы карашны чагылдыра.

Рейтинг нәтиҗәләрен анализлау иң яхшы тәҗрибәгә ия төбәкләрне ачыкларга булыша. Әлеге тәҗрибә ил күләмендә таратыла.

* Стратегик инициативалар агентлыгы тарафыннан әзерләнде.

Фото: tatar-inform.ru

КАЗАН – 2026 ЕЛДА ИСЛАМ ДӨНЬЯСЫНЫҢ МӘДӘНИ БАШКАЛАСЫ

Февраль аенда Согуд Гарәбстанында узган конференциясендә Ислам хезмәттәшлеге илләренең мәдәният министрлары бертавыштан әнә шундый карар кабул итте. Аңлашыла ки, тик торганнан гына кабул ителмәде мондый карар. Күп гасырлык тарихы дәвамында Татарстан башкаласы дөньякүләм ислам мәдәнияте үсешенә үзенең тиңдәшсез өлешен кертте. 2026 елда Казанны ислам дөньясының мәдәни башкаласы итеп сайлаулары, диде Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов, «безнең мәгърифәтчеләребезнең, галимнәребезнең, мәдәният һәм сәнгать әһелләребезнең казанышларын тану, шулай ук Россиягә ислам дөньясы тарафыннан ышаныч күрсәтү билгесе ул». Фестивальләр, гастрольләр, форумнар, сәнгать осталары концертлары һәм күргәзмәләр... Мөгаен, боларның барысы да киләсе елда Казанда еш булыр. Ләкин иң элек, әйдәгез, безнең бөек мирасны тагын бер кат барлыйк әле.

ГАСЫРЛАР БУЕ ТУПЛАНГАН ХӘЗИНӘ

Евгения Чеснокова

...Учка сыярлык кына бакыр тартмада гарәпчә язылган китап ята. Бу – XVIII–XX гасырларда популяр булган миниатюр Коръән, андый футлярлар гадәттә гаилә ядкәренә әйләнгән, буыннан буынга тапшырылган. Изге текстны шундый кечкенә китапка кулдан язып сыйдыру, билгеле, искиткеч осталык таләп иткән. Әлеге китап һәм башка артефактлар белән Кол Шәриф мәчетендә урнашкан Ислам мәдәнияте музеенда танышырга мөмкин.

Фото: Александр Ефремов

Ислам мәдәнияте музее мөдире Илнур Низамиев.

Музейның төп залы үзәгендәге интерактив Коръән.



МЕҢ ЕЛЛЫК БАГЛАНЫШЛАР

2026 елда Казан һәм Багдад ислам дөньясының мәдәни башкалалары булачак – Ислам хезмәттәшлеге оешмасы илләренең мәдәният министрлары очрашуында шундый карар кабул ителде. Безнең төбәгебез белән Гыйрак башкаласы арасындагы мәдәни бәйләнешләрга инде 1100 елдан артык булуы хакында Ислам мәдәнияте музеенда сезгә һичшиксез сөйләп бирәчәкләр.

– Бу турыда без Иранда да, Россия музей һәм китапханәләре фондларында сакланган язма чыганаклардан да (шул исәптән, безнең экспонатларыбыздан) беләбез, – дип сөйли Ислам мәдәнияте музее мөдире Илнур Низамиев. – Искә төшерсәк, нәкъ менә Багдад илчелегенең 922 елда безнең төбәккә килүе хәзерге Россия территориясендә ислам таралуга яңа импульс биргән бит.

Менә шундый мең еллык багланышлар бу.

ТӘҢРЕЧЕЛЕКТӘН – ИСЛАМГА

...Дулкынга охшаган чәч каптыргычы, бүре сурәтләнгән зооморф йозак... Музейның экспозицияне башлаган витриналарының берсенә X гасырда хәзерге Биләр территориясендә яшәгән якташларыбызның көнкүреш һәм бизәнү әйберләре куелган. Биләр музей-тыюлыгы тәкъдим иткән әлеге экспонатлар Идел буеның исламгача тарихына карый. Илнур Низамиев әйтүенчә, ул вакытта хәзерге татарларның

борынгы бабалары табигатьтәге ниндидер өстен көчләргә табынган, бүре формасындагы йозак торакны яхшырак саклый, дип ышанган.

– Ислам безнең төбәккә бер көндә генә килеп җитмәгән бит, процесс дистәләрчә елга сузылган, – дип сөйли музей мөдире. – Әмма биредәге табынулар исламга бик якын булган – алар да бер Ходайга инанган. Үзәк Азия, Якын Көнчыгыш белән сәүдә элемтәләре исә мөселман динен ныгытуга булышкан.

Витринадагы бераз соңрак табылган артефактлар – гарәп дирһәмнәре, гарәп язулы бронза йозак – ул борынгы элемтәләрнең дәлилләре булып тора...

Фаянс касә фотосы игътибарны җәлеп итә. Низамиев әйтүенчә, бу бик уникаль табылдык, мондыйлар хәтта Иранда да сирәк очрый. Әйе, Биләр территориясендә табылган касә XI гасыр азагы – XII гасыр башында Иранда ясалган. Димәк, ул чакта татарлар белән фарсыларның мәдәни багланышлары бик нык булган... Белгечләр касәне кисәкләрдән, кыйпылчыклардан җыйган. Хәзер оригинал КФУның археология музеенда саклана.

Биләр территориясендә табылган X гасыр көнкүреш предметлары.

Идел буенда яшәүче халыкларның көнкүреш әйберләрендә традицион ислам бизәкләрен күреп була.





К.Насыйри китабы һәм кулъязмасы, XIX гасырның икенче яртысы.

МӘҢГЕЛЕК ҺӘМ ЧИКСЕЗЛЕК

Исламның татар мәдәниятенә йогынтысын музейда саклана торган XIX гасыр көнкүреш предметлары мисалында да күзәтеп була. Чигелгән сөлгеләр, калфаклар, изүләр, намазлыклар... Аларда чәчәк рәсемнәре, кабатлана торган геометрик бизәк – болар барысы да тере җан ияләрен сурәтләү тыелган ислам сәнгатенә хас, ә бизәкнең кабатлана торган ритмы мәңгелек һәм чиксез Аллаһы Тәгалә идеясен чагылдыра.

Янәшәдә генә төрки-мөселман дөньясына хас музыка уен коралы – өч кыллы думбра тора, еш кына аның аккомпанементында китап укыганнар.

ҮЗЕБЕЗНЕҢ ДА ВИНЧИ КАЗАНЫШЛАРЫ

Татар һәм бөтендөнья исламының үзара йогынтысы хакында сөйләгәндә, татар халкының күренекле мәгърифәтчеләрен атап китү бик мөһим. XVIII гасырдан алып XX гасыр башына кадәрге чорда яшәгән әлеге фидакарьләр ислам мәдәнияте һәм фәне өчен бик күп нәрсә эшли. Бүген музейда татарлар өчен искиткеч әһәмияткә ия шәхес – галим, әдип, мәгърифәтче Каюм Насыйрига багышланган вакытлыча экспозиция эшли. Ул дәреслекләр язган, календарьлар төзегән, мәктәпләр ачкан, беренче татар энциклопедиясен төзегән... Аны татарлар «үзебезнең да Винчи» дип йөрткән.

Күргәзмәдә Насыйри язган дәреслекләрне, календарьларының кулъязмаларын күрергә була. Календарьларында ул, елдагы һәр көн хакындагы стандарт мәгълүматтан (Кояш чыгу-бату, халык сынамышлары) тыш, ил тарихы, татар мәдәнияте, шул заман җәмгыятенең проблемалары турында да язган.

Экспозициягә Насыйриның тагын бер тиңдәшсез җәүһәре – Коръәннең сүзлек-конкордансы – мөселманнарның изге китабының беренче сүзлек белешмәсе куелган. Конкорданс – билгеле бер текстта кулланылган барлык сүзләрнең алфавит тәртибендә тупланмасы ул. Насыйри берничә ел буе Коръән буенча шундый сүзлек төзегән. Сүзлектә 50 меңгә якын сүз тупланган, аларның кайсы сүрәдән булуы күрсәтелгән. Илнур Низамиев әйтүенчә, бу ислам мәдәниятендә шундый тәүге хезмәт, һәм ул татар зыялыларының гомуммөселман гакыл хәзинәсенә үз өлешен кертүенә җете бер мисал булып тора.

ХАТЫН-КЫЗЛАР МӘСЬӘЛӘСЕ

Ислам мәдәнияте музее стендларының берсендә хатын-кыз фотосурәтләренең күплеге игътибарыбызны җәлеп итә.

– Хатын-кызлар темасы XX гасыр башында Казан мөселманнары өчен бик мөһим була, – дип аңлата Илнур Низамиев. – Биредә «Сөембикә» журналы басыла, мөселман хатын-кызлары өчен корылтайлар үткәрелә, кызлар мәктәпләре (шул исәптән авылларда да) ачыла. Авторы хатын-кыз булган китаплар саны арта.



«Исламда хатын-кызларның хокуклары» китабы, 1917 ел.

Японияда беренче гарәпчә басма Коръән 1934 елда нәшер ителгән.



Музей директоры безгә витринадагы китапларның берсенең тышлыгын күрсәтә. Телне белмәгәч, без анда нәрсә язылганны аңламыйбыз бит. Ә бу бик кызыклы документ икән: 1917 елда Уфада мөслимәләр корылтаенда укылган «Исламда хатын-кызларның хокуклары» дигән доклад тексты.

– «Хатын-кызлар мәсьәләсендә» дә без татар исламының бөтен мөселман дөньясына йогынтысы хакында сөйли алабыз, – ди Илнур Илдар улы. – Казанда педагогика курслары тәмамлаган кызлар кыргыз һәм казах далаларында укыта, хәтта хәзерге Кытайның төньягындагы территорияләргә, уйгурлар яшәгән җиргә кадәр барып җитә. Ул төбәкләрдә дә кызлар өчен мәктәпләр ачыла. Татар мөслимәләре менә шундый мәгърифәтчелек миссиясен дә башкара.

КАЗАН КОРЪӘНЕ ГАЛӘМЕ

1803 елда Казанда Коръәннең беренче басма варианты пәйда була, соңрак ул бөтен дөнья өчен диярлек үрнәккә әйләнә. Кол Шәриф мәчете галереясында Казан Коръәненә багышланган вакытлыча фотокүргәзмә эшли.

– Казанда Коръән басу тарихы – татар исламының бөтен мөселман дөньясына йогынтысына тагын бер мисал ул, – ди Илнур Низамиев. – Басма Коръән таралу изге китап сүзләрен җиһанның бөтен почмакларына җиткерү мөмкинлеген бирә.

Әйе, Коръәнне гасырлар буе кулдан күчереп язганнар. Аны бастыру омтылышлары 1803 елга кадәр дә булган, әлбәттә. Әмма Европада басылган Коръән текстларында хаталар күп очрый. Ә менә Казанда нәшер итү җайга салынгач, басма Коръән чыннан да бөтен дөньяга бик тиз тарала башлый.

– Казан Коръәннәре – тулы бер галәм ул! – ди Илнур Низамиев. – Алар хәзер дә гамәлдә булган бастыру стандартын формалаштырган, һәм ул Төркиядә, Мисырда, Согуд Гарәбстанында бүген дә Коръәнне бастыруда файдаланыла.

Ә сез беләсезме икән, 1934 елда татар җәмгыятьләре җыйган акчага Казан Коръәненең факсимилесы хәтта Токиода да чыга. Сүз уңаеннан, бу мөселманнарның оригинал телендәге изге китабының Япония тарихында бердәнбер басмасы. Ул тиражның бер данәсен «Казан Кремле» музей-тыюлыгы фондларыннан табып була. Биредә, музейда, бөтен дөньяда нәшер ителгән басма Коръән сурәтләре арасында Казан басмасының Токио репринты фотографиясе дә бар.

ТАШ СИМВОЛ

Музейдагы экскурсиябез тагын бер фотогалереяда тәгәлләнә – анда Казанның тарихи мәчетләре сурәтләрен күрергә мөмкин. Фотокүргәзмәдәге 13 мәчетнең 12 се хәзер дә эшли, әмма экспозиция өчен аларның революциягә кадәр төшерелгән сурәтләрен сайлаганнар: аларны борынгы кварталлар һәм моннан йөз елдан артыграк элек яшәгән кешеләр фонында күрсәтергә булганнар.

– Гомумән, татар мәчетләре архитектурасы да ислам мәдәниятенә йогынты ясаган, – ди Илнур Низамиев. – Бөтен Россиядә, Ерак Көнчыгышка кадәр, татар сәүдәгәрләре Казандагы кебек мәчетләр салдырган. Ә инде бу күргәзмәнең һәм музеебызның Кол Шәриф мәчетендә урнашуы исә исламның заманча тарихы белән бәйле. Чөнки Казанга килүчеләр һәм безнең экспозицияләребезне караучылар өчен нәкъ менә Кол Шәриф мәчете Идел буенда, Россиядә исламның торгызылуы символы булып тора. Күрүебезчә, әлеге символ бөтен дөнья мөселманнары өчен бик кадерле.

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

vk.com/protatarstann

t.me/protatarstan

ok.ru/tatarstan.zhurnal

Реклама 16+

БЕЗНЕҢ ТӨРКЕМНӘРГӘ РӘХИМ ИТЕГЕЗ!

ИСЛАМ ЭСТЕТИКАСЫ

Ольга Туманская

Ислам мәдәниятендә «сәнгать» төшенчәсенең үзенә бер мәгънәсе бар. Юк, бу рәссамның үзенең иҗади потенциалын күрсәтүе генә түгел, бу аның дөньяны танып-белүе дә. Анда осталык һәм иҗат, һөнәр һәм белем бар.

ТАНЫП БЕЛҮ ОСТАЛЫГЫ

– Икесе дә бер үк нәрсә түгелмени болар? – дип ихластан гаҗәпләнәм мин

– Шулай да, юк та. Менә... сөтле каһвәне күз алдына китерегез әле! – дип гади кешегә дә аңлаешлы образларда аңлата ислам сәнгате белән мөселман сәнгате арасындагы үзара бәйләнеш һәм аерманы **сәнгать фәннәре докторы, Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институтының баш фәнни хезмәткәре Гүзәл Вәлиева-Сөләйманова.** – Биредә нииндидер кушылу турында сөйләп булмый. Югары ислам (дини) сәнгате һәм синкретик мөселман сәнгате (дөньяви, әмма ислам эстетикасы кануннарында) бар. Кеше, мөселман, каһвә кебек – ул баштан ук дөньяда бар, һәм ул сөт – исламны кабул итә. Хәзер инде аларны аерып булмый.

Классик гарәп телендә рәссам һөнәрен аңлаткан сүз юк, дип сөйли Гүзәл Фуад кызы. Әмма «сәни» сүзе бар, ул «куллары белән эшләүче кеше, үз хезмәтендә һөнәр һәм иҗатны кулланучы кеше» дип тәрҗемә ителә. Мөселман рәссамы өчен сәнгать – сәләт түгел, бәлки тырышып үзләштерелергә тиешле белем ул. Менә шуңа күрә дә аларның күбесе аноним иҗат иткән, чөнки үзеңне танып белү алар аңлавында данга бәйле булмаган.

Ислам традициясе фаразлавынча, чынбарлыктан күчермә алып булмый, чөнки аны Аллаһы Тәгалә яраткан. Һәм аны Аллаһы Тәгалә яратканнан яхшырак итеп булмый, бары тик танып белергә, уйланырга һәм үз белемеңне нииндидер махсус символик тел – бизәк, орнамент, каллиграфия аша чагылдырырга була...

Фотолар Гүзәл Вәлиева-Сөләйманова архивыннан

БИЗӘК ТЕЛЕНДӘ

Бу гүзәлнең чәчен – калфак, муенын – муенса, кулын балдак бизи. Артында кояш чыгып килә. «Көзге каршындагы татар кызы» рәсеме күзне иркәли һәм, аклы-каралы гына булса да, нигәдер бик җете төсле тоела. Аның авторы – Строганов училищесында белем алган, татар хатын-кызлары арасында беренче профессиональ рәссам Хәдичә Акчурина.

Рәсем беренче тапкыр 1915 елда «Аң» журналында басыла һәм прогрессив татар тамашачыларын сокландырып кына калмый, консерватив дин әһелләренең тәнкыйтенә дә дучар була, чөнки мөселман сәнгатендә Аллаһны гына түгел, кешене дә сурәтләү күп гасырлар буена тыела. Пәйгамбәр (с.г.в.) нең сурәте шигыйләрнең миниатюраларында сирәк кенә очраштыргалый, ул аларда да һәрвакыт йөзен каплап һәм алтын нур белән сурәтләнә.

– Кешене һәм җан ияләрен сурәтләү Коръәндә турыдан-туры тыелмый, – дип аңлата Гүзәл Фуад кызы. – Әмма әлеге тыю Пәйгамбәребез (с.г.в.) нең әйткән сүзләре һәм кылган гамәлләре теркәлгән хәдисләрдән аңлашыла. Бу тыю мәҗүсилеккә, потларга табынуга каршы көрәш сыйфатында гаммәви дини аңга сеңдерелгән.

Исламда җан ияләрен сурәтләү Аллаһка охшарга тырышу буларак кабул ителгән. Әмма исламга кадәрге чор болгар сәнгатендә хайван һәм кош образлары шактый еш очрый. Аларның кайберләре бик озын гомерле булып чыга һәм татар бизәкләрендә безнең көннәргә кадәр килеп җитә. Мәсәлән, каз яисә үрдәк сурәтләре. Соңгысының болгар чигә асма бизәгенә күчүе дә мәгълүм. Бәхеткә, зәркән сәнгатенең әлеге җәүһәрләре Эрмитаж, Мәскәүдәге Тарих музее һәм ТР Милли музеендагы археология коллекцияләрендә сакланып калган. Бүген исә кош мотивларын без хәзерге татар авылларындагы йортларның тәрәзә йөзлекләрендә күрә алабыз. Әлеге образлар күп гасырлар дәвамында ничек сакланып калган соң?

– Чөнки алар миф һәм әкиятләр белән бәйле, – дип җавап бирә бу сорауга Гүзәл Вәлиева-Сөләйманова. – Дөнья яратылу турында риваятьне хәтерләсәгез, анда үрдәк дәрья төбенә чумып, томшыгында туфрак алып чыга, шул рәвешле коры җир барлыкка килә. Алай гына да түгел, мифлар кеше аңында генеалогия, димәк, нәсел тотемнары белән дә бәйле була. Һәркем үз тотемын белә, соңрак бу тамгаларда үз чагылышын таба.

Әмма вакыт үтү белән татарларда нәсел элгәрләрен хөрмәтләү культурасы юкка чыга. Ул күп очракта күчмә халык традицияләренә һәм нәсел-ыру җирләренә бәйле була, тик боларның барысын да шәһәр цивилизациясе кысрыклап чыгара, һәм исламны кабул итү бу очракта мөһим роль уйный, чөнки ул нәкъ менә калаларда гөрләп үсә бит. Әйе, нәкъ менә шәһәрләрдә югары ислам мәдәнияте формалаша – мәчетләрдә һәм мәдрәсәләрдә. Әкренләп, әлеге мәдәният йогынтысында, нәфис әдәбият телендә үзгәрешләр барлыкка килә – чынбарлыктагы образлар шартлысына алыштырыла, шул рәвешле бизәк сәнгатьтә төп сурәтләү чарасына әйләнә.

– Ул Идел болгарлары матди мәдәниятенең барлык төрендә диярлек кулланылачак, – дип сөйли Гүзәл Фуад кызы. – Һәм зооморф, үсемлекләр, геометрик һәм эпиграфик (хәрефле) мотивлардан гыйбарәт булачак. XVIII–XIX гасырларда сурәтләрнең схемалылыгы, үзен христианнарның икона язуларына каршы куеп, көчәячәк кенә.



«Көзге каршындагы татар кызы» рәсеме беренче тапкыр 1915 елда «Аң» журналында басыла. Аның авторы – Строганов училищесында белем алган, татар хатын-кызлары арасында беренче профессиональ рәссам Хәдичә Акчурина.



Кош мотивларын без хәзерге татар авылларындагы йортларның тәрәзә йөзлекләрендә күрә алабыз.



Үрдәк сурәте чагылыш тапкан болгар чигә асма бизәге.

«Аллаһ гүзәл һәм гүзәллекне ярата» шәмаиле. Авторы – Бакый Урманче.

«Кәгъбә» картинасы. Рәссам Вәкил Шәйхетдинов эше.

Манаков йорты (Казан ш., Мәскәү ур., 42) фасады бизәлешендә кулланылган милли татар бизәкләре.

Ихтимал, каллиграфияне исламга хас үзенчәлекле сәнгать төрләренең берсе дип атарга буладыр, дип сөйли безнең экспертыбыз. Аны рәссамга бирелгән үзенә бертөрле талант, дип бәялиләр. Изге Коръән аятьләрен, Аллаһ Тәгаләнең һәм Пәйгамбәребез (с.г.в.) нең, гадел хәлифәләрнең исемнәрен кулъязмаларда язалар, диварларга уялар, кабер ташлары, тукыма һәм келәмнәр, керамика һәм металл эшләнмәләр бизәкләренә кушып үрәләр...

Һәм, әлбәттә инде, шәмаилләр! Аларны хаклы рәвештә ислам сәнгатенең феномены дип атыйлар. Гадәттә Коръән аятьләре язылган панно майлы буяулар белән пыялага төшерелә, кәгазьгә языла, тукымага чигелә, литография ысулы белән бастырыла... Тексттан тыш, анда мәчет сурәтен дә очратырга була. Шуны билгеләп үтү зарур: нәкъ менә татарларда әлеге сәнгать беркайчан да юкка чыкмый. Дин әзәрлекләнгән совет чорында да шәмаил сәнгате авылларда сакланып кала. Аларда еш кына Коръән текстлары татар халык мәкаль һәм әйтемнәренә, Тукай шигырьләренә алыштырыла. Сирәк кенә рәсемле шәмаилләр дә очраштыргалый! Аларның барысын да үзлегеннән өйрәнгән осталар ясый. Ислам сәнгатенең әлеге төрен торгыза алган профессиональ шәмаил осталары исә Татарстанда узган гасырның 90 нчы елларында гына пәйда була.

АВАНГАРДТА

«Безгә үзебезнең тормышны сурәтләгән картиналар язарлык рәссамнар кирәк», – дип хафаланган Габдулла Тукай. Җәдидчелек – ислам мәгърифәтчелек модернизмы, мөселманнарның реформаторлык хәрәкәте дәвере җитә. Дөньяви Европа сәнгате гөрләп үсә башлый – аның скульптура, сынлы сәнгать, графика кебек төрләре пәйда була. Шулай ук газета һәм журналларда чынбарлыкны чагылдырган иллюстрацияләр басыла башлый. Бу урында Хәдичә Акчуринаның «Көзге каршындагы татар кызы» рәсемен кабат искә алыйк.

– Билгеле, болар барысы да әкренләп гамәлгә керә, – дип сөйли Гүзәл Вәлиева-Сөләйманова. – Баштарак әлеге эшләрдә реализм шактый шартлы була. Кайбер сурәтләрдә кешеләр, ниндидер сюжетлы күренешләр чамалана. Тәүге татар рәссамнары үз хезмәтләрендә Идел-Урал төбәге мөселманнарының тормышын милли элементлар кертеп чагылдырырга тырыша. Аларда – халык иҗаты традицияләре, шуңа хас төсләр гаммасы, әлеге әсәрләрне мөселман сәнгатенә кертерлек шартлы тел саклана.

Революциядән соң ислам мәдәнияте тыела. Шулай булса да, ул, су ташлар арасыннан юлын тапкан шикелле, бөтен тыюлар аша барыбер үтеп чыга ала һәм совет чоры сәнгатендә теге яки бу дәрәҗәдә чагылыш таба. Бу модернизм һәм югары татар сәнгате туу вакыты була, анда мөселман традицияләре ислам сәнгатенә хас образлылык һәм символизм, яссы композиция, төсләр, кайвакыт исә каллиграфия аша да гәүдәләндерелә. Без боларның барысын да 1920 нче еллардагы татар графикасында күрә алабыз.

Әлеге алымнар егерменче елларда Маяковский җитәкләгән яңа революцион иҗат берлеге – «Левый фронт искусств» (ЛЕФ) нигезенә салына. Авангард, конструктивизм – сәнгатьтәге татар рәссамнары үзләренең кабатланмас шәркый өслүбендә иҗат итә алган прогрессив юнәлешләр. Әлеге өслүб исә күп гасырлар буе ислам мәдәнияте йогынтысында формалаша. Һәм менә безнең каршыбызда ул вакытлар өчен новаторлык булган Бакый Урманче иҗаты, Шакир Мөхәммәтҗановның китап графикасы, Фаик Таһиров плакатлары...

Бүген ислам традицияләрен Казандагы Әлфия Ильясова, Рөстәм Шәмсутов кебек модернистларның һәм үз картиналарында ислам мифологиясе образларын актив файдаланучы башка күп рәссамнарның әсәрләрендә очратырга була.

МУЗЫКА ГАСЫРЛАРНЫ ТОТАШТЫРА

Борынгы тәнбур бик заманча да яңгырый ала икән. Һәрхәлдә, Алмаз Әсхәдуллин кулында ул әйтерсең лә җанлана, безнең заман белән урта гасырларны тоташтыра торган күпергә әйләнә. Алмаз – Идел буендагы борынгы музыкаль-инструменталь сәнгатьне торгызу ниятеннән оештырылган «Алпар» этно-төркеменнән. Тәнбурдан тыш, алар арсеналында башка төрки уен кораллары – думбра, курай, кубыз, дәф тә бар. Егетләр борынгы көйләрне заманча аранжировкалар белән бизи, һәм мәдәни мирасны болай үзгәртеп яңгырату бик мавыктыргыч килеп чыга.

– Идел буенда ислам кабул ителү төбәгебезгә күп яңалык, шул исәптән шәрык поэзиясен дә алып килә. Шигърият булган

«Җимеш өзүче Мәрьям» картинасы. Рәссам-модернист Әлфия Ильясова эше.

җирдә исә һичшиксез музыка да була, – дип минем ислам музыкасы мәдәнияте белән танышуымны дәвам иттерә Геннадий Макаров. Ул музыка белгече-фольклорчы, Казан консерваториясенең татар музыкасы һәм этномузыкология кафедрасы педагогы гына түгел, традицион уен коралларын ясаучы оста һәм аларда уйнаучы буларак та танылган шәхес.

Күп төрки халыклар өчен мәдәнияттә мода чыгаручы булып Бохара саналган. Яшьләр анда укырга киткән, аннары туган якларына кайтып әлеге белемне файдаланган. Урта гасырлар әдәбияты безнең өчен шул вакыттагы мәдәни тормыш энциклопедиясе булып тора – без аларны өйрәнеп ул чактагы шигырь язу системасы, көйләр ритмы һәм җирле музыка уен кораллары хакында белә алабыз. Әлбәттә инде, гармун яки фортепиано түгел, ә бәлки думбра, курай, дәф булган алар...

– Шигърият ритмнары аеруча нык булып чыккан һәм халыкта хәзергә кадәр сакланган, – дип сөйли Геннадий Макаров. – Инде 40 елдан артык авыллар буйлап экспедицияләрдә йөрим һәм әлеге әсәрләрне – касыйдә, газәл, робагый, мөнәҗәт, бәетләрне язып алам. Музыкаль-поэтик сәнгатьнең

Музыка белгече-фольклорчы Геннадий Макаров 1994 елда ясалган тәнбур музыка уен коралында уйный.

барлык бу жанрлары халык шигърияте һәм борынгы музыкаль традицияләр нигезендә ислам йогынтысында формалашкан.

Шунысы гаҗәп: совет чорында бөтенләй игътибар бирелмәгән нәрсәләр халыкта яңа идеология белән параллель рәвештә яши алган. Татар мәдәниятен өйрәнүчеләр мәгълүм сәбәпләр аркасында дини поэзия феноменына кагылмаска тырышкан. Шулай булса да, язып алган. Нәкъ менә шуңа күрә безнең әбекәйләребезнең җырлары күп институтларның тавыш архивларында сакланып калган.

Әлеге әсәрләргә нәрсә хас соң? Алар шәркый ритмнарда көйләп башкарыла һәм аларда татар этник җырларына хас мелизмнар юк. Башкаручыга билгеле бер метрик үлчәмне саклау мөһим. Текстлар нигезендә үгет-нәсихәтләр, пәйгамбәрләр тормышыннан сюжетлар ята. Шулай да, мөселман музыкасы эталоны юк, ди Геннадий Михайлович. Шунлыктан еш кына төрекләр, татар музыкасын тыңлаганда: «Бу бит кытай көеме?» – дип сорый.

Җәдидчелек пәйда булу җирле мөселманнар мәдәниятендә дә чагылыш тапкан. Суфилар Идел буенда тамыр җәйгән Урта Азия традицияләрен саклауны дәвам итсә, Европа яңалыкларына каршы булса, җәдидче реформаторлар «яңару» яклы булган. Татар мәдәниятенең яңа катламы туа. Музыканың сәхнә варианты пәйда була, дини кануннардан читләшү омтылышы сизелә. Мелизмнар белән җырлау өслүбе ныгый, бүген без моны «Кара урман» яки «Тәфтиләү» кебек җырларда ишетә алабыз. Скрипкалы, мандолиналы, гармоникалы яңа татар музыка сәнгате пәйда була – һәм бу инде бөтенләй башка

– Бүген күп кешедә әлеге шәрык поэзиясенә бәйле урта гасырлар мәдәниятен, аның ритм һәм көйләрен торгызу теләге бар, – дип сөйли Геннадий Макаров. – Фольклор экспедицияләр нәтиҗәләре һәм борынгы китаплар буенча мин думбра, тәнбур, шөлдерле барабан, дәфне ясарга өйрәндем. Моны бөтен кеше аңламый, билгеле. «Безгә нәрсәгә кирәк бу? – диләр. – Әйдә, үзебезчә, гармунда уйныйк!» Шулай да, бүген бу юнәлеш заманча этномәдәни хәрәкәттә зур урын алып тора.

Идел буе мөселманнарының борынгы сәнгате үрнәкләре белән Казандагы «Бәрәкәт» фольклор ансамбле (аның илһамчысы Геннадий Михайлович), Казан дәүләт мәдәният һәм сәнгать университетының «Җомга көн» ансамбле, һәм, әлбәттә инде, экспериментлар яратучы «Алпар» этнотөркеме концертларында хозурланып була.

«БЕЗГӘ РУХИ ЯКЫНРАК»

«Кирпеч фасадлар силуэтында Казан Кирмәненең ак таш диварлары образы гына түгел, бер үк вакытта суфичылык фәлсәфәсе дә, формалар төгәллегенә омтылган совет модернизмы эстетикасы да яшеренгән. Бу турыдан-туры өземтә китерү түгел, бәлки тикшеренүгә өндәү...»

Г. Камал исемендәге Татар дәүләт Академия театры яңа бинасының үз концепциясен Bespoke җитәкчелегендәге консорциумда катнашучылар шулай тасвирлый. Әмма архитектура конкурсында ул җиңмәде. Гәрчә, Казан мэры Илсур Метшин әйтүенчә, жюри вәкилләре нәкъ менә аның җиңүен көтсә дә: «Bespoke проекты безгә рухи якынрак...» – дигән алар. Җиңүне исә архитектор Кенго

– Безнең архитекторлар нигездә көнбатыш мәдәнияте йогынтысында иҗат итә, – дип бәяли Казанның хәзерге йөзен Гүзәл Вәлиева-Сөләйманова. – Әмма кайбер биналарда булса да милли бизәкләрне күрә алабыз әле. Бу үткән гасырның һәм бүгенге көннең татар мәчетләренә һәм дөньяви биналарына һәм хәтта рус хуҗалар заказы буенча төзелгән биналарга да (бигрәк тә эклектика өслүбендәге) кагыла. Мәсәлән, Манаков йорты (Мәскәү урамы, 42) фасады бизәлешенә. Кремль һәм Кави Нәҗми урамнары чатындагы (10/15) архитектурасы европача булган заманча йортның декорында да татар милли орнаменты файдаланылган.

Әлеге җәһәттән тагын М. Җәлил исемендәге Опера һәм балет театры бинасын күзәтү кызыклы. Бу Сталин чоры ампиры кемгәдер бөтенләй яңа яктан ачылырга мөмкин: моның өчен аның фасадларына – колонналары, кәрнизләре, тәрәзә формалары, сквердагы фонтанына бераз игътибарлырак күз ташлау да җитә. Барысында да «формасы буенча милли, эчтәлеге буенча социалистик» сәнгать шигаренә җавап бирә торган совет архитектурасы идеясе ярылып ята.

– Элек күп казанлыга үзендә урнашкан «Ноталар» кибете буенча таныш Пушкин урамындагы 58 нче йорт танылган архитектор Рәшид Мортазин проекты буенча салынган. Игътибар белән карасагыз, архитекторның фасадны бизәү өчен үрнәк итеп Болгардагы Җәмигъ мәчете колонналарын алуын күрерсез, – дип мөселман мәдәниятенең хәзерге заман архитектурасына йогынтысына мисаллар китерүен дәвам итә Гүзәл Вәлиева-Сөләйманова. – Әйе, инде узган гасыр уртасында ук рәссам-мигъмарлар үз проектларында татар мөселман архитектурасы мотивларын чагылдырырга омтылган.

Тагын да кызыклырак күренеш – әлеге тенденцияне өр-яңа хай-тек проектларда табу. Әйе, хәтта нәкъ менә Камал театрының конкурста җиңгән яңа бинасы концепциясендә дә. Булачак театрның интерьерларында һәм кече формаларында татар сәнгатенә хас төсләрне, орнамент стилистикасы элементларын күрә безнең экспертыбыз.

Сүз уңаеннан, мөселман архитектурасы образы гәүдәләндерелгән Bespoke җитәкчелегендәге консорциум проекты икенче урын алды. Анда архитектура формаларының суфичылык аскетизмына хас төгәллеге һәм кырыслыгы да, татар мәчетләрен төзегәндә бик еш файдаланыла торган, сафлыкны чагылдырган ак төс символикасына да акцент бар. Әмма бу, аңлавыбызча, инде бөтенләй башка тарих...

– Ислам сәнгатенә карата «эстетика» термины европача шәрехләнүендә кулланылмый, – дип сөйли миңа Гүзәл Фуад кызы. – Коръән дә, Сөннәт тә сәнгать формаларын ачмый. Шулай да, аларның икесеннән файдаланып, мөселманнарга үзләре өчен нәтиҗәләр ясау бер дә катлаулы түгел. Пәйгамбәребезнең (с.г.в.): «Аллаһ гүзәл һәм гүзәллекне ярата» хәдисен мөселман эстетикасының нигезе дип санап була, ул рәссамга иҗат итү өчен җитәрлек ирек бирә.

Журнал «Татарстан», № 05 май 2022

Г. Камал театрының яңа бинасы концепциясендә мөселман архитектурасы образы. Bespoke җитәкчелегендәге консорциумның әлеге эше конкурста икенче урынны алды.

ФӘЛСӘФӘЧЕЛӘР, РЕФОРМАТОРЛАР, МӘГЪРИФӘТЧЕЛӘР

Татар дин гыйлеме мәктәбе ислам дөньясында аерым урын алып тора. Курсави, Утыз Имәни, Мәрҗани, Бубый, Баруди, Фәхретдин... – үз заманнарының мәшһүр голәмәләрен бөтендөнья ислам фәне, фикер һәм фәлсәфә, мәгърифәт күгендә якты йолдызлар дип атарга була. Язмабызда аларның кайберләре турында сөйләрбез.

Фото: islam-portal.ru, tatar-islam.com

ГАБДЕННАСЫЙР КУРСАВИ

Үлем җәзасы янау, үз диненнән язган тамгасы алу, хаҗга барганда үлеп калу... Габденнасыйр Курсавиның тормыш юлы бер дә сикәлтәсез булмаган, ә аның яңарыш идеяләре замандашлары тарафыннан көчле каршылыкка очраган. Югыйсә нәкъ менә шул идеяләр аның исемен ислам дөньясында мәңгеләштерә дә бит.

Башта үзләрендәге мәдрәсәдә белем алу, аннары укуны Бохарада дәвам итү... – XVIII гасыр азагында үз язмышларын тулысынча дини эшчәнлеккә багышларга теләгән татарлар үтәргә тиешле юл шундый була. Ул чакта безнең якларда Урта Азия мәдрәсәләре белән чагыштырырлык югары типтагы бер генә уку йорты да булмый. Мәдрәсәдә мөдәррис, ягъни ректор булыр өчен дә Бохара «вузында» белем алу таләп ителә.

ЧЫГАНАКЛАРГА КАЙТУ ҺӘМ ФИКЕРЛӘРГӘ КУРЫКМАУ

Ләкин Бохарада Курсавины рәсми дини мәктәпнең абруе һәм «карьера» үсеше мөмкинлекләре генә кызыксындырган дип уйларга кирәкми. Монда гасырлар дәвамында интеллектуаль элита белемнәрен туплап тапшыручы суфыйчылык тарикатләре яшәгән. Бу орденнарның суфыйлары хәтта дәүләтнең каты диктаты атмосферасында да рухи азатлыкларын саклап кала алган. Габденнасыйр Курсави Бохарада үзенең белемен дәвам итү өчен зур йогынтыга ия Нәкышбәндийә тарикате шәехе Ниязкули әт-Төрекмәни мәдрәсәсен сайлый, күрәсең, аның фәнни карашлары шул уку йортында формалаша да.

Ислам кануннарын җентекләп өйрәнеп һәм Бохара дин белгечләренең исламның беренче чорлары традицияләреннән никадәр ерак китүләрен аңлап, Курсави үз юнәлешен билгели. Ул дин әһелләрен мөселман хокукының төп чыганаклары булган Коръән, сөннәт, иҗмә (җәмгыятьнең бердәм ризалыгы), кыяска (аналогия буенча фикер) кайтырга чакыра. Әгәр хокукый карарларны узганнарда табып булмый икән, аларны иҗтиһад итеп, ягъни мөстәкыйль эзләнеп кабул итәргә кирәк, дигән фикерне алга сөрә.

Үз идеяләрен Габденнасыйр хәзрәт туган ягында – Югары Курса авылында (бүген – Татарстанның Арча районы) ачкан мәдрәсәсендә тормышка ашыра башлый. Монда аның фикердәшләре, тарафдарлары пәйда була. Әмма галимнең яңа карашлары мәдрәсәгә генә сыймый, һәм ул аларны Бохарадагы дин әһелләре хөкеменә чыгарырга була.

ДӘЛИЛЛӘҮ УРЫНЫНА ТЫЮЛАР

Дөньяга акча белән хакимлек баш булган, ә муллалар, әйләнә-тирә дөньяны үзгәртү мөмкинлеген кире кагып, рәхимсез әмир хакимиятенең Аллаһ тарафыннан билгеләнгәнен исбатлау өчен көчләрен кызганмаган шәһәрдә Курсави идеяләре ничек кабул ителсен, ди? Исламның беренче чорларындагы иҗади рухка кире кайтырга кирәклегенә эчтән генә ышанган кешеләр дә моны кычкырып әйтергә батырчылык итми. Фәнни бәхәсләрдә Габденнасыйр Курсавиның революцион идеяләре урта гасырларда тоткарланып калган җәмгыятьнең нигезләрен какшатырга, хәтта ки шартлатырга мөмкин була.

Моңа хакимият ничек карыймы? Алдан ук күренеп тора: дәлилләр урынына – тыюлар. Әмир, җиде мөфти һәм җиде казый ярдәменә таянып, Курсавига каршы фәтва чыгара. Галимнең китаплары яндырыла, үзенә үлем җәзасы яный....

Курсави Бохарадан китәргә, кире туган ягына әйләнеп кайтырга мәҗбүр була. Ләкин тиздән Бохара хөкемдарларының шикаятьләре аркасында туган авылыннан да китәргә туры килә. Галим бер төркем шәкертләре белән хаҗга китә. Үз карашларын күбрәк кешегә җиткерергә тырыша. Һәм чит җирләрдә – Истанбулда үлеп китә.

ИДЕЯЛӘР ҮЛЕМСЕЗ

Курсавиның идеяләре замандашларының күпчелеге тарафыннан кабул ителми. Аның фикер эзлеклелеге, чыгыш ясау таланты дини бәхәсләргә әзер булмаган Казан руханиларын шөбһәгә салган, диләр. Ә галим үзе һәр мөселман Аллаһ сүзенең асылын мөстәкыйль аңлауга ирешкәч кенә, ислам кыйммәтләренең яшәячәгенә ышана. Бүгенге күзлектән караганда, Курсавиның Коръәнне мөстәкыйль аңлатуында, дин әһелләренең иске карашларыннан баш тартырга чакыруында бернинди дә начар нәрсә юк...

Дистә еллар уза, Курсавины татар дөньясында яңарыш хәрәкәтенә нигез салучы дип атый башлыйлар. «Габденнасыйр Курсави, – дип яза аның шәкерте Шиһабетдин Мәрҗани, – үзенең акылызиһене ярдәмендә Белем хәзинәсенең тылсымлы йозагын ачты, аннан фәннәрне алып, халык каршында кыйммәтле чәчәкләр үстереп, аларны гавамгә таратты».

ШИҺАБЕТДИН МӘРҖАНИ

1850 елның 30 марты. Беренче Казан мәчетенең имам-мөдәррисе итеп яшь дин белгече Шиһабетдин Мәрҗани билгеләнә... Ул монда гомеренең ахырына кадәр эшли, ә мәчет аның исемен йөртә башлый. Мәрҗани тарихка күренекле татар тарихчысы, фәлсәфәчесе, дин реформаторы һәм мәгърифәтчесе булып кереп кала.

Мәрҗанинең фәнни эшчәнлегенең иң уңышлы чоры XIX йөзнең 70-80 нче елларына туры килә. Нәкъ шушы елларда галимнең мөселман дөньясында аңа танылу китергән хезмәтләре дөнья күрә. 1870 елда Казанда «Нәзурател-хакк...» китабының дөнья күрүе Мәрҗани турында үз заманының дини яңарыш идеологларының берсе буларак сөйләргә мөмкинлек биргән мөһим вакыйга санала.

СПЕКУЛЯТИВ ТЕОЛОГИЯНЕ ТӘНКЫЙТЬЛӘҮ

Соңрак Шиһабетдин Мәрҗанинең башка дини-фәлсәфи хезмәтләре дә пәйда була. Иң танылганнары – «Китабел-хикмәт әл-бәлига әлҗәнния фи шәрхел-гакаид әл-хәнәфия». Мәрҗани калам – спекулятив теология мәсьәләләрен тәнкыйтьләүгә басым ясый, акида нигезләрен – ислам кануннарын шәрехли.

Бер үк вакытта Шиһабетдин Мәрҗани, педагогик эшчәнлек белән актив шөгыльләнеп, татар мәгърифәтчелек хәрәкәтендә дә үз урынын ала. Галим Казан Татар укытучылар мәктәбендә дин фәннәрен укытуга алынучы беренче татар рухани вәкиле була.

ГОМЕРЛЕК ЭШ

1900 елда, Мәрҗани үлгәннән соң, татар телендә аның «Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар» дигән китабы дөнья күрә. Әлеге хезмәте басылганнан соң, фән дөньясында аның турында туган халкы этногенезы проблемасына мөрәҗәгать итүче беренче татар тарихчысы буларак сөйли башлыйлар. Ләкин галимнең икенче бер – «Вафиятел-әсляф вә тәхият әл-әхляф» дигән кульъязма хезмәте тагын да зуррак дан китерә. Мәрҗанинең гомерлек эше булган әлеге титаник хезмәт, асылда, Россия ислам дөньясының танылган эшлеклеләре турында беренче энциклопедик сүзлек була.

«Вафиятел-әсляф вә тәхият әл-әхляф»не эшләгәндә, галим бик күп беренчел чыганакларны өйрәнә. Алар арасында борынгы риваятьләр, кабер ташларындагы язулар, археологик табылдыклар, гарәп, фарсы, төрки кульъязмалар бар. Үзенең структурасы буенча Мәрҗани хезмәтенең төп өлеше сүзлек рәвешендә төзелгән. Анда галимнәрнең, хакимнәрнең, башка күренекле шәхесләрнең биографияләре, аларның үлгән елларына карап, билгеле бер эзлеклелектә бирелгән.

МӨСЕЛМАН ДӨНЬЯСЫ ЭНЦИКЛОПЕДИЯСЕ

«Вафиятел-әсляф...»тә барлыгы алты меңнән артык биография теркәлгән: бу VII гасыр – Мөхәммәд пәйгамбәр вафаты елыннан башлап яшәгән галим, язучы, фәлсәфәче һәм иҗтимагый-сәяси эшлеклеләренең гомер юлы. Әлбәттә, ул элгәрләре җыйган фактларны бәян итү белән генә чикләнми: үз фикер сөрешенә таянып аларның эшчәнлеген шәрехләгәндә, күп кенә тарихи вакыйгаларга бәя дә бирә. Алай гына да түгел, галимнең хезмәтендә фәнни әйләнешкә беренче тапкыр кертелгән оригиналь материаллар шактый. Мондый материалларның географиясе киң – XVII–XIX гасырлар чорындагы Идел буе, Урал, Урта Азия, Кавказ, Кырым төбәкләре.

«Вафиятел-әсляф...» томнарында рухи мәдәниятнең төрле өлкәләренә, алгарышка зур өлеш керткән шәрык галимнәре, җәмәгать эшлеклеләре турында мәгълүмат тупланган. Еш кына бу – мөселман дөньясыннан читтә дә танылу алган шәхесләр.

Шунысы мөһим: тарихны Коръән тәфсире кебек традицион фәннәргә кертеп, бу дисциплина турында урта гасыр мөселман мәдәниятендә үк пәйда булган күзаллауларга таянып эшләсә дә, Мәрҗани әлеге фәнне яңа яктылыкта күрә. Мәрҗани фикеренчә, тарих фәне узган вакыйгаларны теркәп кенә бармый, бәлки, аларның сәбәпләрен өйрәнү белән дә шөгыльләнә. Галим тарихи күренешләрнең социаль аспектларын аерып күрсәтә һәм шуның белән татар халкы тарихын аңлатуда новатор булып тора.

«Вафиятел-әсляф вә тәхият әл-әхляф», – дип расрый тикшеренүчеләр, – мөселман халыклары мәдәниятләренең дәвамчанлыгы һәм үзара бәйләнешенең ачык мисалы һәм аларның тарихын өйрәнүдә сизелерлек этап». Шиһабетдин Мәрҗанине бүгенге көндә татар дөньясының Геродоты дип атаулары юкка түгел.

ГАБДУЛЛА БУБЫЙ

XIX гасырның 90 нчы еллары уртасы, Иж-Бубый мәдрәсәсе. Монда, ерак татар авылында, милләтнең алга китешен тәэмин итәрлек яңа мәгариф системасы төзергә уйлыйлар. Иж-Бубыйга үзгәрешләр кертү башлангычы мулла Габдулла Бубыйга карый. Аның бу эшләрне башкарып чыгуда ярдәмчесе һәм фикердәше – абыйсы Гобәйдулла.

Укыту методлары, мөгаллим һәм шәкертләр арасындагы мөнәсәбәтләр, укыту программалары... Революцион үзгәрешләр ап-ачык күренеп тора. Мәдрәсәдә хәзер татар, рус, гарәп, фарсы телләрен, математика, физика, химия фәннәрен өйрәнәләр... Дин фәннәрен дә шәкертләргә яңача өйрәтәләр – бу хәзер ниндидер тәгълиматларны кабатлау һәм ятлау гына түгел...

Ортодоксаль һәм иске ысуллар белән укытучы мәдрәсә мөгаллимнәре – имамнарның ачулары ничек кабаруын күз алдына китерергә мөмкин. Ләкин бертуганнарның тылы нык. «Әлеге сигез ел эчендә без мәрхүм этиебез абруе аркасында әзәрлекләүләргә һәм реформа дошманнары каргышларына дучар ителмәдек, – дип яза Габдулла Бубый үзенең истәлекләрендә. – Чөнки ул безнең якта булып, җәдидчелекнең һәм мәктәпләрне үзгәртеп коруның зарурлыгын исбатлап торды, бу темага кагылышлы бәхәсләрне ул алып барды, тирә-яктагы бөтен муллаларның остазы һәм белеме буенча аларның барысыннан да өстен булганга, аларга авыз ачарга да ирек бирмәде».

ГАСПРИНСКИЙ ИДЕЯЛӘРЕ ДӘВАМЧЫСЫ

Габдулла Бубыйның реформаторлык идеяләре буш урында пәйда булмый. Туган йортында белем культы хөкем сөрә, әти-әниләре – мәгърифәтчелек үрнәге, абыйсы Гобәйдулла фәлсәфә белән җитди мавыга. Монда фикер хөрлеген тыймыйлар. Габдулла Шиһабетдин Мәрҗани хезмәтләрен өйрәнә, җәдидчелек идеяләрен таратучы Ибраһим Гаспринскийның «Тәрҗеман» газетасын укый.

1895 елда Габдулланы указлы мулла итеп билгеләгәндә, ул инде Гаспралы идеяләре тарафдары була. Атасының фатихасын алып, шул елны Иж-Бубый мәдрәсәсендә үзгәртеп коруларны башлый. Берничә айдан соң, Истанбулда алдынгы «Мәктәбе мулькиен шахане» югары гимназиясендә укуын тәмамлап, абыйсы Гобәйдулла кайта. Ул да бу эшкә бик теләп кушыла.

Сеңлесе Мөхлисә, абыйларының хатыннары белән бергә, әлеге гаять зур проектны гамәлгә ашыруда актив катнашалар. Аларга бертуган Бубыйлар уйлап тапкан укыту методларын үзләштерергә, хатын-кызлар мәдрәсәсен реформалаштыруны үз кулларына алырга туры килә.

ХАКЫЙКАТЬ, ДИМӘК, ДӨРЕСЛЕК

Бу үзгәрешләрне, ниһаять, реформаторларның үзләрен һәм аларның идеяләрен халык ничек кабул итә соң? Менә шәкерте Җамал Вәлиди калдырган истәлек: «Ул башларында фикер уяна гына башлаган яшьләрне дини мәсьәләләрдәге кыюлыгы белән таң калдыра иде. Белмим, искелек яклы руханилар абруеның югалуына һәм кадими мәдрәсәләрнең җимерелүенә китерә торган моннан да көчлерәк тагын берәр әсәр булдымы икән? Иж-Бубыйга укырга дип килүчеләрнең күбесе, шул исәптән мин дә, «Хакыйкать»не укыган һәм әлеге фикерләрне авторның үз авызыннан ишетергә омтылган затлар идек».

«Хакыйкать» – Бубыйның иң танылган дини хезмәте. Коръән аятьләрен анализлап, галим, аерым алганда, «васыять язу, зәкят кебек үк, Аллаһ юлында, милләт файдасына эшләнергә тиеш»ле эш дигән нәтиҗәгә килә...

Бубый үзенең хезмәтләрендә фән, белем алу имансызлыкка китерми, киресенчә ислам үз тарафдарларын бөтен җирдә белем тупларга чакыра, дип аңлата. Ул үз укучыларын фән белән кискен дошманлыкка керүдән кисәтә, мәдрәсәдә география һәм башка табигый фәннәрне укытырга өнди.

ИЖ-БУБЫЙ МӘДРӘСӘСЕ – ЯҢАРЫШ ҮРНӘГЕ

Шиһабетдин Мәрҗани кебек үк, Бубый да исламны социаль гаделсезлекне кире кага, кешеләр арасындагы тигезлек һәм туганлык принципларына аеруча туры килә торган идеология дип саный. Табигый ки, яшьләр мәгърифәт учагына тартыла башлый! Сарапул өязе халык училищесы инспекторы, 1903 елда яңа ысуллы уку йорты белән танышкач, болай ди: «Гомуми тәртип буенча Иж-Бубыйдагы мәдрәсә шактый югарырак тора, шуңа күрә рус-татар мәктәбе укытучылары аны мөселман академиясе белән чагыштыра». Бу вакытта инде яшьләр ерак Иж-Бубый авылына Мәскәүдән һәм Уфадан, Ташкенттан һәм Казаннан, Семердән һәм Әстерханнан белем эстәргә агыла...

Тагын биш елдан соң биредә татар хатын-кызлары мәктәпләре өчен укытучылар әзерли һәм рәсми таныклыклар бирә башлыйлар. Габдулла Бубый: «Хатын-кызлар мәктәбе иң нык үзгәреш кичергәне булды һәм беренче булып мөгаллимәләр әзерли башлады».

Иж-Бубый мәдрәсәсе хәзер башка мәктәпләр өчен үрнәк була, өстәвенә, империянең Европа өлешендә генә түгел. Ә хатын-кызлар мәдрәсәсен җитәкләүче Мөхлисә Бубый мәгърифәтле ислам дөньясында абруйлы шәхескә әйләнә (1917 елда ул ислам дөньясында беренче казыя була – ред. иск.).

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ



* 2023 ел бәяләренә карата (бәяләү).

ТУЛАЕМ ТӨБӘК ПРОДУКТЫ

2024 ел йомгаклары буенча

19,5%
Эшкәртү производстволары

25,6%
Файдалы казылмалар табу

25,6%
Эшчәнлекнең башка төрләре



МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕКЛӘРНЕҢ ТР ИКЪТИСАДЫНА КЕРТКӘН ӨЛЕШЕ, %ЛАРДА

34,6
Казан ш.

14,4
Әлмәт районы

9,6
Түбән Кама районы

9,3
Яр Чаллы ш.

3,2
Алабуга районы

2,5
Лениногорск районы

26,4
башка муниципаль районнар (39)

АКАДЕМИК
ЖИЛОЙ КОМПЛЕКС

Казанның
тарихи үзәгендә

9 йорт
277 машина урыны
3,15 түшәмнең минималь биеклеге
3-7 кат
Террасалы **6** фатир

akademikdom.ru сайтында фатир сайлагыз

Үзәктә яшәү – уңайлы һәм абруйлы гына түгел, бу күңелнең аерым бер халәте

8 минут Кремль һәм Кремль яр буе

5 минут Кабан күле яр буе

3 минуты Горький паркы

7 минут «Урам» паркы һәм «Елмай» балалар паркы

7 минут «Арт-Үзәк» СҮ

10 минут Unischool Халыкара мәктәбе



Гармония – төп кагыйдә буларак

- Фитнес-зал ТК резидентлары өчен генә
- Уйлап ясалган балалар зоналары
- Бала арбалары һәм велосипедлар кую бүлмәсе
- Ял зонасы
- Консьерж һәм дизайнер бизәлеше
- Мини-кинотеатр

+7 (843) 590-83-83
Сату бүлеге: Казан ш., Әмәт магистрале, 18, 1 к
Эш сәгатьләре: дшм. – җм.: 9:00 – 18:00

РЕКЛАМА. Застройщик: ООО «Специализированный застройщик «АСД-2»». ИНН1686027870. Представленная информация носит исключительно ознакомительный характер, ни при каких обстоятельствах не является публичной офертой, определяемой положениями статьи 437 ГК РФ. Построенные объекты могут отличаться от представленных 3Э-визуализаций, изображений. Все представленные материалы, изображения являются ориентировочными, в них могут быть внесены любые изменения и дополнения. Срок завершения строительства IV кв. 2027 г. Проектная декларация №16-002062 от 25.12.2024 на сайте наш.дом.рф.



ӘНИ БУЛУ НИГӘ КУРКЫТА?

Руфия Фазылова

«Хатын-кызның бөтен матурлыгы, бөтен күрке – Ана булуда», – дип яза Такташыбыз. Тик бу кыйммәтләр хәзер үзгәрде, бүген киресенчә, баласыз хатын-кызлар рәхәтрәк яши кебек кабул ителә. Нәтиҗәсе бик аяныч: илдә туучыларның гомуми коэффициенты (бала табу яшендәге бер хатын-кызга туры килгән сабыйлар саны) соңгы 18 елда иң түбән чиккә җиткән. «Росстат» мәгълүматларына караганда, 2024 елда Россиядә 1 222 408 бала якты дөньяга аваз салган. Бу, 2023 ел белән чагыштырганда, 3,3 процентка кимрәк.

Ни өчен елдан-ел сабыйлар азрак туа? Алга таба нишләргә? Хатын-кызларның бала алып кайтырга теләмәве нәрсәгә бәйле? Шушы четерекле сорауларга җавап эзләргә булдык.

ТАТАРСТАНДА КҮП БАЛАЛЫ ГАИЛӘЛӘР АРТА

«Туу турындагы актлар һәм никахлар саны буенча Идел буе федераль округында Татарстан – беренче урында. 2024 елгы нәтиҗәләр шундый», – дип хәбәр итте ТР Министрлар Кабинеты ЗАГС идарәсенең йомгаклау коллегиясендә әлеге ведомство җитәкчесе Эльвира Әхмәтова. Шуңа да карамастан, Татарстанда узган ел белән чагыштырганда сабыйлар азрак туган: 3,3 процентка кимрәк. Ә гомумән караганда, республикада туучылар саны 2017 елдан бирле кимүгә бара.

2024 елда Татарстанда туу турында 35 500 таныклык тапшырылган. Җиһанга 18 500 малай һәм 17 мең кыз аваз салган. Шул исәптән 313 игезәк тә бар, ә бер бәхетле ана берьюлы өч бала тапкан.

– Тагын бер уңай тенденция – Татарстан гаиләләре дүртенче һәм аннан соңгы балаларын ешрак алып кайта башлады, – диде ЗАГС

Фотолар авторныкы, 7 нче шәһәр клиник хастаханәсенең матбугат хезмәтеннән алынды

идарәсе башлыгы Эльвира Әхмәтова. – Нәтиҗәдә, 2024 елда туучы сабыйларның 8,3 проценты нәкъ менә шундый очракларга туры килә. 2023 елда бу сан 7,7 процент булган. Иң кызыгы, бу күрсәткеч 2020 елдан бирле даими үсеп бара.

Республикада туган сабыйларның 39 проценты – беренче, 33 проценты – икенче, 19 проценты гаиләдә өченче бала икән. Республикада ана булуның активлык яше – 25–29, эти булуның – 30–34 яшь. Гаилә тормышының беренче елында һәр бишенче пар гына бала таба. Ни өчен яшь гаиләләр бала алып кайтырга ашыкмый соң? ТР ЗАГС идарәсе башлыгы Эльвира Әхмәтова болай дип фикер йөртә:

– Беренче чиратта моны яшь буынның гаилә коруга һәм балалар тудыруга карата мөнәсәбәте, кыйммәтләр үзгәрүе белән аңлатырга мөмкин. Бүген тормышның шундый моделе өстенлек итә: яшьләр башта һөнәри өлкәдә үсәргә, финанс ягыннан мөстәкыйльлеккә ирешергә һәм шуннан соң гына гаилә кору, балалар тудыру турында уйлый. Нәтиҗәдә, беренче һәм аннан соңгы балалар туу соңрак вакытка кичектерелә, ир-атларның һәм хатын-кызларның репродуктив сәламәтлеге кими. Ә бу исә ана кешенең дә, баланың да сәламәтлегенә куркыныч тудыра.

АКЧА БЕР БУКЧА БУЛМАСА...

Мәктәп яшендәге ике үсмер бала анасы буларак шуны әйтәм: бүген балалар үстерү бик чыгымлы. Аеруча шәһәр җирендә. Монда сүз ипи белән сөт алу турында гына бармый. Түләүле түгәрәкләр, киемсалым, төрле экскурсияләр... Әле яңа гына кызларыбыз Мәскәүдән кайтты, бию буенча конкурска бардылар. Ике кызга илле мең сумнан артык акча чыкты. Кемдер әйтергә мөмкин: соң биюгә нигә йөртәсез, дип. Өйдә генә утырсыннар! Тик замана әниләре мине хуплар дип уйлыйм: йөртәсе килә бит. Сәламәт, акыллы булсыннар, иптәшләреннән калышмасыннар, дисең. Әйе, безнең эти-әниләр дә, хәер, үзебез дә алай үсмәдек. Ә бүген заман, мөмкинлекләр – башка. Балаларга бер-берсеннән калган кием кидертеп үстермибез. Яшьләрнең күбесе моны аңлый, күрә, шуның өчен дә бала табарга бик ашыкмый. Төп сәбәп шунда, дип уйлыйм. Икътисад белгече Илдус Сафиуллин да минем белән килеште:

– Яшьләрнең иртәгәге көнгә ышанычы юк. Әйе, 1990 нчы еллар белән чагыштырганда, хәзер тормыш дәрәҗәсе яхшырды. Әмма икътисадый вазгыять тотрыксыз, гаиләнең кеременә ышанычы юк. Бүген 25–35 яшьлекләр акча эшләү, карьера, фатир сатып алу мәшәкатьләре белән мәшгуль. Бала табу исә икенче планга күчә. Табиблар килешер: 35 яшьтән соң сәламәтлек какшый башлый. Нәтиҗәдә, бер бәби алып кайталар. Ә бу демографик вазгыятьне коткара алмый. Бүген безнең илдә ипотека түләүнең уртача вакыты 25 елдан артык. Чирек гасыр буена шактый зур суммада бурыч түләүдән тыш, итәк тутырып бәби дә үстерергә тәвәккәллек кирәк. Яшьләрне бу бик куркыта.

Бәйсез демограф Алексей Ракшаның исә бу турыда үз фикере бар:

– Бу – 1990 нчы еллар кайтавазы. Билгеле булганча, узган гасыр азагында бала туу рекордлы күләмдә аз иде. Әлеге нисбәттән, 1999 елда антирекорд куелды. Хәзер исә шул елда туганнар 25-26 яшькә җитте. Бүген тәүге тапкыр әни булучыларның уртача яше 26 икәнен исәпкә алсаң, барысы да аңлашыла. Димәк, азсанлы буын бүген үзләре үк эти-әни яшендә. Табигый ки, бала саны күп була алмый.

2025 ЕЛДАН БАЛАЛЫ ГАИЛӘЛӘРГӘ ДӘҮЛӘТ ЯРДӘМЕ

Ана капиталы:
1 февральдән 7,3%ка индексацияләнде:
- 1 нче балага – 676 398 сум,
- 2 нче балага – 893 835 сум.

Ипотека:
- 7 яшькә кадәрле баласы булган гаилә – 6% белән яңа йорттан фатир яки йорт,
- 18 яшькә кадәрле 2 балалы гаилә 6% белән йорт алырга мөмкин.
- Өченче баласы туган гаиләләргә, ипотека алган очракта, 450 мең сумы кичерелә.

Авыл җирендә яшәгән хатын-кызга:
25 яшькә кадәр бала тапса, – 50 000 сум, икенче һәм аннан соңгы баласына 100 000 сум акча бирелә.

Күп балалы гаиләләр:
- ТХК түләүләренә 30% субсидия (социаль нормалар өчен генә),
- 6 яшькә кадәрге балаларга аена даруга 171 сум субсидия ала.
- Транспорт өчен 384 сум субсидия бирелә.

Аз керемле гаиләләргә социаль ярдәм:
- 3 яшькә кадәрге балаларга елына даруга 10 мең сум.
- Яңа туган балаларга кием комплекты.
- Күп балалы аз керемле гаиләләр балалар бакчасы өчен 100% күләмендә компенсация ала.

– Яңа туган сабыйларны күргәч, миндә иң башта горурлык хисе уяна, – ди Татьяна Шиһабетдинова.

«ХАТАЛАНЫРГА ХАКЫҢ ЮК...»

Иң яратмаган урыным – хастаханәләр. Монда килеп кергәч, бөтен кеше дә чирле төсле тоела башлый. Хәтта кешенең хәлен белергә барсаң да, авыр тойгылар белән кайтасың. Бала тудыру йортлары гына искәрмә булып тора. Казанның 7 нче шәһәр клиник хастаханәсе каршындагы перинаталь үзәккә баргач та, күңелне ниндидер бер ләззәтле тойгы биләп алды. Стенада – сабый портретлары, җитәкләшеп йөргән парлар... Ә аларның йөзләрен күрсәң – бәхеттән балкыйлар!

– Булачак әти-әниләр мәктәбенә килдек, – диде ирле-хатынлы Гариповлар. – Җәй башында көтеп алынган улыбыз туачак. Менә әти-әни булырга өйрәнәбез.

Перинаталь үзәктә «Булачак әти-әниләр мәктәбе» эшләп килә. Монда булачак ата-аналар белән психологлар, табиблар эшли. Бала тугач та, беренче көннәрендә үк аны ничек тәрбияләргә, йокы режимын булдырырга – барысын да аңлаталар.

– Соңгы елларда шуны күзәтәм: яшьләр бала табуга аңлы рәвештә карый, – диде Казанның 7 нче шәһәр клиник хастаханәсе каршындагы перинаталь үзәк җитәкчесе, 7 нче клиник хастаханәсе баш табибының акушерлык һәм гинекология буенча урынбасары Татьяна Шиһабетдинова. – Алар башта медицина тикшерүләре узалар. Гомумән, хәзер диспансеризация кысаларында репродуктив сәламәтлекне кайгырту юнәлеше бар, ул 2024 елда гамәлгә керде. Теләгән һәр хатын-кыз, ир-ат барып тикшерелә ала.

– Бу өлкәдә проблемалар зурмы? – дим.

– Ничек кенә! Татарстандагы парларның 15-17 проценты балага уза алмый интегә. Аның сәбәпләре төрле: организмда инфекцияләр булу, стресслар, экология... Шуның өчен репродуктив сәламәтлеккә бик игътибарлы булырга кирәк. Алайса бездә ничек: өйләнешәләр, башта фатир алабыз, карьера ясыйбыз, аннан соң бала алып кайтабыз, диләр. Акушер-гинекологларны бүген борчыган төп проблема – баланы соң табу. Әйе, без, табиблар, бала көткән һәр хатын-кызга шат, әмма 40-45, кайбер очракларда 50 яшьтән соң бездә бик күп хроник авырулар барлыкка килгән була. Ә бу йөклелек чорында да, туачак сабый өчен дә хәтәр булырга мөмкин.

Татьяна Николаевна үзе дә күп балалы әни. Хатын-кызның төп бурычы, беренче чиратта, ана булуда, дип уйлый. Сабый сау-сәламәт булып туып, дөньяга аваз сала икән, моннан да зур шатлык юк, дип саный.

– Өченче баламны кырык бер яшемдә таптым, – ди тәҗрибәле акушер. – Олылары икесе дә үсеп беткән иде инде. Нинди бәхетле

«ҮЗЕН ГЕНӘ ЯРАТКАН БУЫН ҮСЕП ҖИТТЕ»

ЕЛЕНА БОНДАРЕНКО, «Татарстан – Иҗтимагый фикер» фонды директоры урынбасары:

– Без гаилә кыйммәтләренең асылын югалттык, чөнки совет заманыннан бирле илдә идеология ягы аксый килде. Яшьләр исә дөньядагы әхлакый үзгәрешләрне үзенә сеңдерүче «губка»га әверелде. Тик күпчелек очракта бу начар үрнәкләр иде. Шуңа күрә бүген үзен генә яраткан буын үсеп җитте. Моңа өстәп, төрле фильмнар, музыкаль клиплар, текә бьюти-блогерлар аша безгә күрсәтелгән Көнбатыш мәдәнияте үрнәкләре үзең өчен генә яшәргә, эгоист булырга өйрәтте. Әле җитмәсә, үзеңне яратырга өйрәтүче психологлар да учакка ялкын өсти. Нәтиҗәдә, безнең халыкка хас булган гаилә кыйммәтләре – бер-береңне хөрмәт итеп яшәү, ир-атны гаилә башлыгы итеп күрү, хатын-кыз буларак, сабыр итә белү кебек сыйфатлар юкка чыкты. Ни кызганыч, Көнбатыш тарафыннан оештырылган бу идеологик сугышка ныклы каршылык күрсәтә алмадык. Шуңа күрә бүген 35 яшькә кадәрге буын өчен үз-үзеңне корбан итү, бала табу модада түгел, алар күбрәк үзләре өчен яшәргә тели. Һәркем ишле гаиләнең куркыныч түгел, ә киресенчә күңелле, матур икәнен аңласын өчен, иң беренче бала табу, балаларны үстерү өчен тиешле шартлар тудырырга һәм тотрыклылык булдырырга кирәк.

«ЯРДӘМ КИРӘК!»

ЧУЛПАН ГАРӘФИЕВА, психолог:

– Әлбәттә, бала туу гаиләнең тормышын социаль, матди, психологик яктан да бик нык үзгәртә. Мин моңа хәзер үз мисалымда янә бер кат инандым. Көтеп алынган улыбызга тиздән – ике ай. Төп үзгәреш хатын-кызда, ягъни әни кешедә була. Егерме дүрт сәгать дәвамында ул баласын карарга тиеш. Аңлашыла, хатын-кыз нык талчыга. Мондый вакытта яшь анага ярдәм бик кирәк. Шулай булмаган очракта, хатын-кызда бала туганнан соң очрый торган депрессия башланырга мөмкин. Кемдер депрессия юк ул, ди. Янәсе, элек җиде-сигез бала үстергәннәр, берәү дә төшенкелеккә бирелмәгән. Ләкин тәҗрибәмнән чыгып әйтәм, ул бар. Бала тапканнан соң, үз-үзләрен кулга ала алмаган яшь аналар белән еш очрашырга туры килә. Бу вакытта гаиләдә негатив барлыкка килә. Ана кеше баласының шат авазларын, көлүләрен күрми, ишетми башлый. Шуның өчен хатын-кызны ял иттерү, беренче вакытларда булса да ярдәм итү бик кирәк.

Абортлар мәсьәләсенә килгәндә, бу – бик авыр күренеш. Андый адымга барган хатын-кыз иртәме, соңмы, үзен гаепле сизә башлый. Хәтта еллар узганнан соң да күпләрдә үкенү хисе барлыкка килә. Шуның өчен бу адымга барганчы, гүзәл затларыбызга мең кат уйларга киңәш итәм. Берәр акыллы туганыгыз яки психолог белән киңәшләшегез, бәлки сез уйлаган сәбәпләр аборт ясатыр өчен чынлап та нигез түгелдер? Мондый вакытта хатын-кызга янәшәсендә ышаныч, терәк булу кирәк.

идем! Гомумән, яңа туган сабыйларны күргәч, миндә иң башта горурлык хисе уяна. Синең ярдәмең белән җиргә яңа кеше килә! Ул әлегә ярдәмгә мохтаҗ. Аның гомере өчен синең җаваплылыгың да эти-әнисенекеннән ким түгел. Шуңа күрә дә хаталанырга хакың юк!

Шушы күңелле ноктада Татьяна Николаевнаны бүлдерергә булдым. Күңелсез як – абортлар турында да сөйләшергә кирәк. Бүген һәр хатын-кызлар консультациясендә абортка кадәр кабул итү кабинетлары эшли. Йөклелекне өзәргә теләүче ханымнарны башта шунда җибәрәләр. Казан шәһәренең 7 нче клиник хастаханәсе каршындагы перинаталь үзәктә дә бар андый бүлмәләр.

7 нче клиник хастаханәсе каршындагы перинаталь үзәк.

– Узган елның башында Казанда Республика кризислы йөклелек үзәге ачылды, – дип дәвам итте Татьяна Шиһабетдинова. – Ул Казан медицина университеты клиникасы базасында эшли, Бутлеров урамы, 47 йорт адресы буенча урнашкан. Абортка килүчеләр белән башта хатын-кыз консультацияләрендәге белгечләр эшли. Әгәр инде йөклелекне сакларга күндерә алмасалар, аларны Республика кризислы йөклелек үзәгенә җибәрәләр. Әлбәттә, анда да хатын-кызларны бала табарга мәҗбүр итә алмыйлар, соңгы карарны булачак ана үзе кабул итә. Ләкин, аборт ясатканчы, аңа бер атна вакыт бирәләр. Шул вакыт эчендә ул барысын да уйлап, үзе өчен уңай якны сайларга тиеш.

Иң сөенечлесе: Республика кризислы йөклелек үзәгенә килеп әләккән хатын-кызларның 60 процентка якыны көмәнен калдыра икән. Мисал өчен, узган ел 1 меңгә якын сабыйның гомерен шулай саклап калганнар.

...Бала сөюдән дә олырак бәхет бармы икән?! Йокысыз төннәр, нык алҗу... Би-лләүдә яткан сабыеңны кулга алуга, болар барысы да юкка чыга. Аннан аның беренче елмаюын күреп сөенәсең, тәпи китүенә шөкер итәсең, беренче сүзләрен ишетәсең... Үлчәүгә салсаң, болар бөтен авырлыклардан да мең кат өстенрәк. 7 нче клиник хастаханәсе каршындагы перинаталь үзәктән кайткач, моңа янә бер кат инандым. Күкләр хатын-кызга шундый олы бүләк ясаган: без җиргә яңа кеше тудыра алабыз. Шушы бәһасез бәхетне һәр хатын-кызга күрергә, тоярга язсын. Ә авырлыклар... Алар уза, онытыла.

Бөек Җиңүгә 80 ел тулу уңаеннан, яңа рубрика башладык: «41 нче ел балалары». Бөек Ватан сугышы башланган чорда туган, тәпи киткән бу сабыйларның язмышы ничек булып беткән? Нинди могҗиза белән исән калганнар? Әнә шундый өлкәннәребезнең гыйбрәтле язмышларын барларга булдык.

МИЧ БАШЫ ДОГАЛАРЫ



– Без, биш баланы, ятимнәр йортына җибәрергә документлар әзерләп йөргән көннәрдә, әнинең бертуган гарип апасы авыл җирлеге идарәсенә барган. «Ни күрсәк тә бергә булырбыз, балаларны тәрбиягә үзем алам», – дигән. Әнә шулай итеп бер оя ятимне апа үзенә сыендырган...

Апас районы Олы Бакырчы авылында яшәүче Гайнетдинов Шәүкәт абый 1941 елда дөньяга килә. Әтисе сугышка киткәндә әле ул тумаган да була. Малайга алты ай дигәндә әнисе дә бакыйлыкка күчә. Әнә шулай дөм ятим үсә Шәүкәт абый.

ХӘБӘРСЕЗ ЮГАЛУ

Шәүкәт абыйның әтисе Баһаветдин авылда беренчеләрдән булып сугышка алына. Дүрт баласын кочаклап, Бибикамал тормыш иптәшен фронтка озата. Иң олы кызына да унбер генә яшь була. Анысы да монысы, тагын ике айдан бишенче баласы туарга тора. Ничек яшәп бетерерләр?

– Ул чакта әнинең күңелендә ниләр булганын аңлавы кыен түгел, – дип сүзен башлады Шәүкәт абый. – Тик ул бу аерылуны бик авыр кичергән – анысы хак. Шулай булмаса, әтине озаткач ук авырый башламас иде. Әти киткән вакытта ук: «Җә кайтам, җә юк. Күрешә алмасак, бәхил бул. Балалар белән үзеңә генә бик авыр була, шуңа үзәгем өзелә», – дигән. Әтинең фронттан бер-ике хаты килгән. Әни аңа минем турыда язып салган. «Улыбыз бар, 18 августта туды. Шәүкәт дип исем куштым», – дигән. Тик әнинең хәле көннән-көн авырайган, миңа 6 ай дигәндә үлеп тә киткән. Шулай булгач, әти назын да, әни назын да белмим. Әле ярый аптыебыз булган. Безгә ул бик яхшы тәрбия бирде.

«Аптый» дип Шәүкәт абый әнисенең бертуган апасы – Миңнехәят Зиннурованы әйтә. Сәламәтлеге белән проблемалар булу сәбәпле, кияүгә чыкмаган карт кыз була ул. Башта Миңнехәят апалары биш баланы үзенең өенә алып кайта. Ләкин балаларның үз йортлары яхшырак булганга, соңрак бергәләп шунда күченәләр.

– Апагыз авыру да булгач, ничек сезне үстерде? Нәрсә ашатты? – дим гаҗәпләнебрәк.

– Беренчедән, сугышка киткәндә әтинең запаслары күп калган. Ул әле бер-ике елга җиткән. Аннан соң инде аптый әтидән калган яхшы туннарны, савыт-сабаларны ризыкка алыштыра торган булган. Безгә бит Чувашиянең Яльчик базары якын, абый-апалар ул әйберләрне шунда алып барып саткан.

– Шәүкәт абый, ә әтиегезнең кайда вафат булганлыгы билгелеме?

– Билгеле түгел. Әни үлгәннән соң, хәбәрсез югалды, дигән хат килә. Без аны исеме буенча эзләтеп карадык, тик, кызганыч, очына чыга алмадык. Әллә исемен дөрес язмаганнар. 1941 елда исән булган әле, анысы

Фото: Лилиана Вәлитова

хак. 1942 нең кайсы аенда һәлак булганлыгын төгәл генә белмибез.

«АПТЫЙ ЭЗЛӘП КИЛДЕ»

Шәүкәт абый сугыш беткән көнне бик хәтерләми. Бу аңлашыла да, дүрт яше дә тулмаган бала. Алай да кешеләрнең капка төпләренә чыгып сөенгәннәрен, йөгерешеп йөргәннәрен чамалый. Аның каравы, әнисе урынына калган аптыеның сүзләрен, мич башында җылынып яткан якты кичләрне бик яхшы хәтерли ул:

– Аптыйның умачлы ашын ашыйбыз да җылы мич башына тезелешеп менеп утырабыз. Аның сәндерәсе дә бар иде. Тамак проблемасы гына түгел, ягарга утын да юк бит. Ә кышлар озын, суыклары үзәккә үтә. Аннан-моннан чыбык-чабык табыштырабыз. Әле ярый абый, апалар кул арасына керә торган булган. Мич башы зур булмаса да, бер-беребезгә «җылышып» ятабыз, бераз җылынышабыз. Ә аптый безгә китаплар укый, догалар өйрәтә. Динне бик яхшы белә иде ул. Бишебезгә дә күп догалар өйрәтте. Аннары бик матурлап җәннәт турында сөйли. Ә безнең барыбызның да җәннәтле буласы килә. Анда мин әнине, әтине очратырмын төсле... Хәтерлим, берсендә абыем сорап куйды: «Ә җәннәт дигән урында тамак туйганчы ашарбызмы икән?» Аптый, барыбызның да башыннан сыйпап, болай диде: «И, балалар, җәннәттә сез оҗмах җимешләрен ашарсыз. Андагы матурлык...»

Кечкенәдән барыбыз да белеп үстек: җәннәтле булу өчен күп яхшылык эшләргә кирәк. Аптыйның зирәклегенә, белеменә хәзер дә шаклар катып утырам. Югыйсә гади авыл апасы бит. Аннары, аның сабырлыгына да исем китә: авыру килеш биш баланы алып, беребезне дә какмый, сукмый үстерде. Аналар мәхәббәте белән яратты ул безне. Алланың рәхмәте, без дә аңа бер кыенлык китермәдек: ни кушса, шуны үтәдек. Аның сүзе закон иде.

Алай гына да түгел, ир уртасы булгач та, Шәүкәт абый аптыеның сүзеннән чыкмый. Менә шуңа бер мисал. 1962 елда ул күрше кызы Хаҗирәгә өйләнә. Олы Бакырчы мәктәбендә җиде ел бергә укыган сыйныфташлар булалар. Шәүкәт абый Хаҗирә апаның уңган, бик тырыш кыз икәнен күреп үсә. Шуның өчен дә 21 яшендә үк никах укыталар. «Хаҗирә янына күрше Балтай авылыннан бер егет килгәнен күреп алдым. Болай кыймыйрак йөрсәм, сыйныфташны алып китәләр икән, дип уйладым», – ди Шәүкәт абый. Баксаң, Хаҗирә апа да егеткә битараф булмаган. Әнә шулай тиз арада өйләнешеп тә куялар.

Мисал, дигән идем бит. Яшь гаилә Төмән якларына акча эшләргә китә. Гайнетдиновларның бу вакытта олы уллары туган була инде. Шәүкәт абый Төмән өлкәсендә тракторга эшкә урнаша. Аның инде механизатор тәҗрибәсе була. Олы Бакырчы җидееллык мәктәбен тәмамлагач та, ул, Биектау районының Усад һөнәр училищесына барып, механизаторлыкка укып чыга. Башта трактор ярдәмчесе булып эшли. Бер елдан соң тырыш егеткә яңа трактор бирәләр. Кыскасы, Төмәнгә киткәнче, шактый тәҗрибә туплаган була.

– Шулай басуда эшләп йөрим, трактор артыннан Хаҗирә йөгерә, – дип дәвам итте Шәүкәт абый. – Тракторны туктаттым. «Әйдә, кайтабыз, аптый килде», – ди Хаҗирә. Кайтсам, аптый утырып тора. «Сездән башка булмый, балалар», – ди. Шулай итеп, ул безнең белән калды. Төмән өлкәсендә ике елга якын яшәдек. Гел сазлык анда, зур-зур черкиләр. Аптый көн саен әйтә башлады: «Монда минем тәһарәтем дә дөрес түгел, черкиләр сырып ала. Үлгәч, сазлыкта ятасым килми. Зинһар, авылга кайтып китик», – ди. Әнә шулай туган якларга кире әйләнеп кайттык. Әниебез урынына булган аптыебыз 78 яшенә кадәр безнең белән яшәде. Соңгы көннәренә кадәр акылында, аягында йөрде. Гел догада булды.

АЛЛАҺКА ТАЯНУ

Шәүкәт абый белән Хаҗирә апа дүрт ир бала тәрбияләп үстергән. Аларга белем биреп, һәркайсын башлы-күзле иткәннәр. Бүген ир белән хатын икәү генә һәр көнгә сөенеп яши. Хаҗирә апа гомере буе балалар бакчасында эшләгән, сабыр, тәрбияле ханым. Язмышның туры китерүен кара – Хаҗирә апа да әтисе сугышка киткәннән соң туган бала, 1941 елгы. Җәмәгатеннән аермалы буларак, ул әнисе белән үскән.

– Без әтинең кайда күмелгәнен беләбез, – диде Хаҗирә апа. – Әтинең кечкенә генә сурәте дә бар иде, тик менә шуны таба алмадым. Әни берәр җиргә куйганмы, һич бел-

Шәүкәт хәзрәт Олы Бакырчы мәктәбендә дә чыгышлар ясый.

Шәүкәт абый белән Хаҗирә апа 63 ел тигез гомер кичерә.

мим. Ник шул сурәтне үзем белән алып китмәгәнмен, дип уйлыйм хәзер. Әни вафат инде, урын өсте калгач, Шәүкәт белән үзебезгә алып килдек. Бездә мәрхүм булды.

Иң мөһиме шуны әйтергә кирәк: Шәүкәт абый Гайнетдинов – Олы Бакырчының имамхатыйбы. Олысы-кечесе хөрмәт итә аны.

– Пенсиягә чыкканчы ук, мәчеткә йөри башлаган идем, – ди Шәүкәт абый. – 70 яшемдә укырга кердем, чөнки динне үзлегеңнән генә өйрәнеп бетереп булмый. Казандагы Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге мәдрәсәдә өч ел читтән торып укыдым. Бер елдан мине авылның имамы итеп сайладылар. Унөч ел инде халыкны дингә тартам. Аллага шөкер, районда безне үрнәк итеп куялар. Җомга намазына 40лап кеше җыела. Мәчеткә чакырып, кайберәүләрнең өенә өчәр, дүртәр тапкыр барам. Бер килгәч, йөреп китәләр, намазына да өйрәнәләр. Бик зур савап бит ул.

Күз тимәсен, Шәүкәт абый ел саен уразаны да тота. Мәчеткә көненә икешәр тапкыр барып кайта. 75 яшендә хаҗ сәфәрен дә кылган. ТР Диния нәзарәте иң яхшы эшләүче муллаларга бушка юллама бүләк иткән. Шәүкәт хәзрәт шул бәхетлеләр арасына эләккән.

– Аллаһы Тәгаләнең кодрәте чиксез: һич уйламаган җирдән хаҗны күрү насыйп итте. Аптый белән укыган догаларыбыз кабул булгандыр, дим. Бу бит әйтеп аңлата алмаслык олы бәхет.

Шәүкәт абыйның зиһене бик яхшы. Ә тырышлыгы турында әйтәсе дә юк. Үзе әйтүенчә, кечкенәдән шундый булган:

– Сугыштан этиләре исән кайткан малайларның велосипедлары бар иде. Ә минем булмады. Кая инде велосипед, аптыйның пенсиясе 12 сум иде. Аның каравы, тракторда эшләгән акчама авылда беренче булып мотоцикл алдым.

Алай гына да түгел, авылда беренчеләрдән булып җиңел машина ала Шәүкәт абый. Аның да тарихы кызык кына:

– Лесхоз җитәкчесе идем. Безнең колхозның рәисе килгән: «Әйдә, безгә бригадир кирәк. Кайт инде», – ди бу. Чиратсыз гына «Москвич» машинасы алырга булышсагыз, кайтам, дидем. Ул вакытта акчалы кеше дә машина ала алмый. Колхоз рәисе сүзендә торды: берничә айдан өр-яңа «Москвич» машинасы барып алдым. 1975 елда авылда җиңел машина берәүдә дә юк иде әле. Шулай итеп үзебезнең колхозда 16 ел бригадир булып эшләдем.

Бригадир вазыйфасыннан туеп китә Шәүкәт абый. Колхоз зур (Олы Бакырчы заманында Апас районының иң зур авылы була). Азрак тынычлап яшим әле, дип уйлый. Ләкин күп тә үтми, колхоз рәисе элеккеге бригадирны ферма мөдире булырга кыстый. «Ике генә айга сүзне тыңлап тор инде. Кеше тапкач, китәрсең...»

– Фермада эшләвем 14 елга сузылды, – ди Шәүкәт абый. – Сыер савучылар белән бик рәхәт эшләдек. Хатын-кызга җай табарга кирәк, кайчагында шаярткан буласың, кайчагында мактыйсың. Шунсыз булмый. Зурлап бәйрәмнәр, туган көннәр уздырдык.

Менә шундый язмыш. Күкләр аңа сынавын да, бәхетен дә өеп биргән. Ә Шәүкәт абый гомер буе шөкер итеп, Аллаһка сыенып яшәгән һәм яши. Ихластан сәламәтлек, Хаҗирә апа белән тигез тормыш, сөенечле озын гомер телибез Шәүкәт хәзрәткә.

P.S. – Балачактагы иң татлы ризык булып нәрсә истә калган? – дип сорап куйдым Шәүкәт абыйдан. Уйлап та тормый җавап бирде ул:

– Мәчтүрә яфрагына (сүз эт борчагы турында бара. – Ред.иск.) төрелгән җир җиләге. Без аны «якмыш» дип ашый идек. Сугыштан соңгы авыр еллар, татлы ризык та ашыйсы килә, ә ул юк. Ә шул «якмыш»ны ашап куясың да, авызлар ерылып китә... Әле тагын Бадамша чокыры янына төшеп, учак ягып, яңа арышны калайга салып, кыздырып ашый идек. Монысы инде күзгә таба була торган хөррият. Бригадир басудан арышны җыйганны күрсә, бетте баш, тизрәк чабасың. Абый-апалар артыннан калышмаска кирәк, югыйсә сине үзләре белән бүтән иярмиләр. Менә шулай үстек, кызым. Ә барыбер балачак бик сагындыра, мөмкинлек булса, бер генә көнгә кайтып килер идем шунда. Мич башына менеп утырып, аптый янында бер генә сәгать черем итеп алыр идем...

акыллы
гамәлләр
игелекле
эшләр
мәңгелек
кыйммәтләр

Бу санда тәкъдим итәбез:

Өченче меңьеллык хатын-кызы традицияләрне **ничек** саклый

Ни өчен Яр Чаллы кызлары үзебезнекеләрне ташламый

Гөлфизия апа **ничек** «Ак Барс» клубы талисманына әверелә

Ни өчен тамашачы Камал театрына яратып йөри





Фото: Александр Ефремов, проектта катнашучыларның шәхси архивыннан

«Татарстан» журналының махсус проекты

БАТЫР ЙӨРӘКЛЕ ГҮЗӘЛЛӘР

«Татарстан»ның бүген көн үзәгендә, әлбәттә, туташлар вә ханымнар. Чөнки урамда – март, яз. Ә язның – үз кануннары. Шуны да әйтергә кирәк: туташ һәм ханымнарыбыз гүзәл генә түгел, ә батыр да. Исеме мәктәп дәреслекләрендә урын алган атаклы бер шагыйрь әйткәнчә, «чабып барган атны туктата алу» турында гына түгел без... Бүген дә хатын-кыз батырлыгы, тәвәккәллеге таләп ителә торган өлкәләр аннан башка да җитәрлек.

Димәк, сез менә кемнәр белән танышачаксыз:

1. Тәтештә агрофирма һәм крестьян-фермер хуҗалыгы җитәкчесе **Рима Сафиуллова** ничек итеп Интернациональ хатын-кызлар берлеге вице-президенты булган.

2. Яр Чаллы волонтёрлары **Катя**, **Гуля** һәм **Аня** «Тимер» сугышчыларына ничек булыша.

3. **Ксения Ульянченко** ни өчен һөнәри юлы итеп ветеринарияне сайлаган.

4. Пенсионер ханым **Гөлфизия Камалиева** ничек итеп «Ак Барс» хоккей командасын җиңүләргә рухландыра.

редакция кухнясы

Фото: Ната Смирнова. РЕКЛАМА

РИМА САФИУЛЛОВАДАН – ТӘТЕШ КАЗЫ

Татьяна Вафина

Бүген «Татарстан»ның редакция кухнясында, саный башласаң, исем-дәрәҗәләре белән бүләкләре генә дә ярты журналны алып торырлык хатын-кыз тылсым тудыра. Аңа йөкләнгән бөтен иҗтимагый эшләрне дә исәпләп чыксаң, гомумән журнал битләре җитмәстер. Шуңа аны гап-гади итеп – Татарстан данын халыкара масштабта яклаган «Өченче меңьеллык хатын-кызы»* дип кенә тәкъдим итәбез. Бу – Рима Сафиуллова. Бүген бергәләп алар гаиләсенең иң яраткан бәйрәм сые – Тәтеш казын әзерләргә керешәбез!

Тәтеш казы дигәннән, ул Тәтешнеке булмаганыннан нәрсәсе белән аерыла соң, диярсез. Бу сорауга җавапны без инде каз, кызарып, тәмле исләрен аңкытып, мичтән табынга менеп утырганда җавап бирә алырбыз, шәт. Ә хәзер, әле әзерләү процессында, Рима Гомәровна безгә рецептның берничә серен чиште.

ЛИМОНДА ИКӘН БӨТЕН ХИКМӘТ

Тәтеш казын, һичшиксез, Тәтешнең үзендә үстерергә кирәк, ди, монысы төп шарт. Ә икенчесе – аңа, һәйбәтләп, эчен дә, тышын да лимон белән сылап, согын сеңдерү. Бигрәк тә – эченә.

– Менә шушындый лимон яртысын алам да казның тиресенә сылап чыгам, аннары лимон кисәген эчендә калдырам, – дип, «лимонлаштыру» процессы белән бүлешә Рима Гомәровна. Аннан дәвам итә: – Алга таба инде казның эченә туралган алма, кара җимеш, йөзем тутырабыз да, үзен духовкага озатабыз. Башта – 120 градус температура астында сәгать ярым-ике сәгатькә, ә аннары, градусны 160–180 градуска күтәреп, тагын сәгать-сәгать ярымга. Якынча өч сәгать вакыт эчендә менә диген, телне йотарлык каз әзерләнеп өлгерә: артык майлы да түгел, чөнки мае андый температурада кайнап сеңеп бетә, шул ук вакытта – йомшак, хуш исле дә.

Без казны бу рецепт буенча барлык гаилә бәйрәмнәренә хәстәрлибез. Аны мин генә түгел, ә ирем дә, улларым да әзерли белә.

КИРӘК БУЛАЧАК:

- Каз – 1 түшкә;
- Йөзем – бер уч;
- Лимон – 1 данә;
- Тоз – тәменчә;
- Кара җимеш, алма – каз эченә сыя торган күләмдә.

* «Өченче меңьеллык хатын-кызы» – 2023 елда Рима Сафиуллова «Өченче меңьеллык хатын-кызы» Халыкара премиясендә җиңүчеләр исемлегенә керде. Ул «Ел лидеры» номинациясендә иң яхшысы дип табылды.

ҮЗЕ – ДИРЕКТОР, ҮЗЕ – ВИЦЕ-ПРЕЗИДЕНТ

Рима Гомәровна – суперактив, бер дә тик тормас кеше. Бик яхшы эшли торган, Татарстандагы уңыш нәтиҗәләре буенча даими рәвештә лидерлар бишлегендәге ике предприятие – «Колос» агрофирмасын һәм «Сафиуллова Р.Г.» крестьян-фермер хуҗалыгын җитәкли. Хуҗалыклар белән идарә итүдән тыш, ул әле райондагы иҗтимагый оешмалар җитәкчесе булып та тора. Болар – «Ак калфак» белән «Татар гаиләсе». Шулай ук – Халыкара ислам бизнесы Хәйрия фонды әгъзасы, тагын әле ТР Хатын-кызлар интернациональ берлегенең вице-президенты да.

ИЛНЕҢ АЗЫК-ТӨЛЕК КУРКЫНЫЧСЫЗЛЫГЫ

– Ничек барысына да өлгерәсез?

– Вакытны дөрес итеп бүлә белергә кирәк, шул чакта һәр нәрсәгә өлгереп була ул, – дип, сере белән бүлешә Рима Гомәровна. – Хәзерге заманда торган саен күбрәк хатын-кыз бизнес алып бара, җитәкче урыннарны били, җәмәгать эшчәнлеге белән шөгыльләнә. Шуның белән беррәттән, менә дигән хуҗабикә, кайгыртучан ана булырга да өлгерәләр. Безгә хәзер шәхси һәм иҗтимагый эшчәнлектә мөмкин кадәр гармониягә ирешергә омтылырга кирәк, профессиональ карьера белән гаилә арасында да.

Авыл хуҗалыгында хатын-кызлар сүзе еш кына – иң мөһиме. Авыл хуҗалыгы – икътисадның зур бер өлеше генә түгел, илнең азык-төлек куркынычсызлыгын тәэмин итә торган стратегик тармак. Һәм бу, нәрсә генә әйтсәң дә, эшләр өчен бик кызыклы өлкә.

– Сез һәрчак авыл хуҗалыгында хезмәт куйдыгызмы?

– Юк. Хезмәт юлымны Чүпрәле районының Яңа Ишле авыл мәдәният йортында сәнгать җитәкчесе булып эшләүдән башладым. Аннары без Ульяновскида яшәдек. Тәтеш районының авыл хуҗалыгына моннан 26 ел элек килеп эләктем. Ул чакта иремә «Колос» авыл хуҗалыгы предприятиесен җитәкләргә тәкъдим ясадылар. Дөресен генә әйткәндә, мин артык шатланмадым, бигрәк тә күчеп китәсе булгач. Миңа ул чакта Ульяновскидагы көйләнгән тормышыбызны ташлап, ниндидер авылга кайтырга кирәк булды. Әмма ирем һәрвакыт авыл хуҗалыгы белән шөгыльләнергә, авылда яшәргә теләде. Һәм мин, ир белән хатын бергә булырга тиеш, дигән карарга килдем.

Тәтештә авыл хуҗалыгы предприятиесендә бухгалтер булып эшли башладым. Беренче этап җиңел булмады, әмма хәзер аны кичеп чыга алуыбызга бик шатланам. Барысын да ташлап, кире шәһәргә кайтып китәсе килгән көннәр дә булды.

Хуҗалыкта дизель ягулыгына, малларга ризыкка да акча юк. Техника иске – ул берөзлексез ватыла, юллар начар. Сыер савучылар, механизаторлар, терлекчеләр җитми...

Крестьян хезмәтен уңышлы итеп оештырып булуын ирем беренче тапкыр Германиядә күреп кайтты. Эшне дөрес, җитештерү чылбырында бернинди дә өзеклекләргә юл калдырмый торган итеп оештыру нәтиҗәсендә, бөтен әйләнә-тирәнең ничек төзек, уңайлы булуына шаккатып кайткан иде. Тәвәккәлләп карарга булдык, моның өчен, билгеле, бөтен нәрсә бизмәнгә куелды. Шул рәвешле үзебезнең авыл хуҗалыгы предприятиесен бөтенләй яңа дәрәҗәгә чыгардык.

Кредитлар алдык, Ульяновскидагы фатирыбызны залогка салдык. Барысын да югалту куркынычы бик зур иде, әмма, шөкер, башкарып чыга алдык. Бәлки, икебезнең дә, авылда үсеп, авырлыклардан курыкмый торган кешеләр булуыбыз да үз ролен уйнагандыр.

Заманча техника сатып алдык, җитештерүгә модернизация ясадык. Шул рәвешле, әкренләп, югары нәтиҗәләргә дә ирештек.

«РИМА» СОРТЛЫ БОДАЙ

– Орлык җитештерү өлкәсендә «Колос» агрофирмасы Мәскәүнең авыл хуҗалыгы фәнни-тикшеренү институты белән тыгыз элемтәдә торып эш итә, – дип сөйләде безгә Рима Гомәровна. – Бу инде үзенең бәһасез нәтиҗәләрен күрсәтте дә: бездә чыгарылган кайбер культуралар сертификация узды, орлыклары хәзер сатуга чыгарылды. Безнең сабан бодаеның сорты «Рима» дип атала,

ул миңа атап кушылды. Әлбәттә, бу минем өчен бик күңелле.

– Котлыйбыз сезне!

– «Рима» сортын гына да без узган сезонда гектарыннан 47,1 центнер җыеп алдык! Калган культуралар буенча да алдынгылыкны бирмибез!

Сыерлар да тулысынча балансланган азык белән туклана: комбиазык, түп, кукуруз. Боларның барысы да үз хуҗалыгыбызда җитештерәбез.

Атлар да асрыйбыз. Ат фермасында аларны тоту өчен бөтен уңайлы шартлар да тудырылган. Бүген безнең 118 баш атыбыз бар.

АВЫЛДА КАЛА ТОРГАН ЯШЬЛӘР

– Яшьләр авылда, бигрәк тә авыл хуҗалыгы тармагында калырга атлыгып тормый, дип саныйбыз. Эше авыр, хезмәт хаклары зур түгел, шәһәргә качарга гына торалар…

– Бездә алай түгел, – ди Рима ханым. – «Колос» предприятиесендә инде олпат, тәҗрибәле аграрийлар белән беррәттән, яшь белгечләр дә эшли. Авыл хуҗалыгы предприятиесе коллективында 67 кеше исәпләнә. Уртача хезмәт хакы – 70 607 сум. «Сафиуллова Р.Г.» КФХ нда хезмәт хакы – 60 921 сум тирәсе, 44 кеше хезмәт куя.

Теләге булган хезмәткәрләрне предприятие хисабына шифаханәләргә путёвка белән тәэмин итәбез, мохтаҗларга матди ярдәм күрсәтәбез, юбилейларны, башка мөһим вакыйгаларны күз уңыннан ычкындырмыйбыз.

Хезмәт җитештерүчәнлегенең күтәрелүе дә җитештерүнең рентабельлегенә йогынты ясый. Ел саен машина-трактор паркын яңартып торабыз. Узган елны өч яңа трактор, авыл хуҗалыгы тагылмалары, чүмәлә җыя торган җайланмалар сатып алдык, су манарасы урнаштырдык, сенаж траншеясы казыдык, янгын депосы эшләп китәргә әзер диярлек. Җылытыла торган остаханәне яңарттык, аңа капиталь ремонт ясадык.

Яшьләрнең туган авылларында калуы, һөнәри эшчәнлекләрен «Колос» агрофирмасында яисә «Сафиуллова Р.Г.» крестьян-фермер хуҗалыгында башлап җибәрүләре минем үзем өчен бик күңелле хәл.

БЕЗДӘ ХАЛЫК БУЛЫШЫРГА ЯРАТА

– Безнең авыл хуҗалыгы предприятиеләре эшчәнлегендә үтәлергә тиешле чыгымнар статьясына хәйриячелек тә керә. Кешеләргә булышырга кирәк, нинди формада да ярый. Без һәртөрле чараларны уздырганда ярдәм күрсәтәбез, ярминкәләрдә товарны арзанайтып сатабыз. Сугыш ветераннары белән тыл батырларына игътибар бирәбез, махсус хәрби операциядә катнашкан ир-егетләрнең гаиләләрен даими барлап, аларга булышып торабыз. Зыян күргән төбәкләрдәге халыкка ярдәм кулы сузабыз. «Колос» агрофирмасы белән «Сафиуллова Р.Г.» КФХ акчаларына МХО зонасына даими рәвештә техника җибәрелә: автомобильләр, квадрокоптерлар, махсус техника, азык-төлек һәм башка бик күп кирәк-яраклар.

2024 елда гына да алгы сызыкка 27 миллион сумлык гуманитар ярдәм озаттык.

ИЛКҮЛӘМ ПРОЕКТЛАР – ЗУР ЯРДӘМ

– Ә безнең үзебезгә Россия күләмендә гамәлгә ашырыла торган проектлар булыша. Федераль һәм республика дәүләт программалары – аграр тармакка зур ярдәм.

Әйтик, «Колос» агрофирмасында «Хезмәт җитештерүчәнлеге» илкүләм проекты гамәлдә. Хезмәткәрләр берничә төрле тренинг узды: сакчыл җитештерү; яхшырту проектлары нигезләре; картирлаштыру, автоном тәэмин итү һ. б.

«Колос» агрофирмасы терлекчеләре үз эшләрендә «Дайри Комп 305» көтү белән идарә итү программасын куллана, шулай ук – ДТМ 8000 малларны ашату белән идарә итү программасын да. Бу эшчеләрнең авыр хезмәтен бермә-бер җиңеләйтә, терлекчелек өлкәсендә югары нәтиҗәләргә ирешергә мөмкинлек бирә.

Терлекчелек корылмаларын төзекләндерүгә юнәлтелгән республика программасы буенча дүрт сыер абзары яңартылды, аларда яктылыкдиодлы прожекторлар урнаштырылды, фермаларга бетон плитәдән юллар җәелде. Цифрлаштыру елында исә авыл хуҗалыгы предприятиеләрендә 30 лап видеокамера урнаштырылды.

АГРОБИЗНЕС – УЛ МИНЕМ ГАИЛӘМ

– Россия агросәнәгать комплексының мактаулы хезмәткәре буларак сезгә тагын бер сорау: авыл хуҗалыгы белән шөгыльләнүче хатын-кыз нәрсәләр эшли белергә тиеш?

– Башлаган эшен азагына кадәр җиткерә белергә, үз дигәненә ирешергә, кечкенә генә эшләрдә дә олы максат күрергә, үзенә һәм башкаларга карата таләпчән булырга.

1 Сылыйбыз

2 Кисәбез

3 Тутырабыз

4 Пешерәбез

5 Турыйбыз

Моннан тыш, ул әле тагын битараф булмаска, кешегә карата игътибарлы, сизгер була белергә тиеш. Коллегаларыма акыллы киңәш биреп кенә калмыйм, аларны яхшы хезмәт хакы, социаль ташламалар һәм башкалар белән кызыксындырам. Эшем – минем икенче өем, ә коллективтагы кешеләр – икенче гаиләм. Өйдәгеләр, гаилә әгъзаларым белән чагыштырганда, кайчак алар белән күбрәк вакытымны уздырам кебек. Ярый әле, балалар инде үсеп җитте.

Җәмәгать эшләренә килгәндә, ул миңа ошый. Рәхәтлек, канәгатьлек хисе бирә. Яратып эшлим бу эшләрне.

ҖӘМӘГАТЬ ЭШЧӘНЛЕГЕ КАНӘГАТЬЛЕК КИТЕРГӘНДӘ...

– Мисал өчен, мин районыбыздагы «Ак калфак» иҗтимагый оешмасын җитәклим. Район филиалында без гаҗәеп җылы атмосфера тудырырга ирешә алдык, ул магнит кебек һәркемне үзенә тартып тора. Тәтешлеләр бөтен идеяләрне шунда ук эләктереп алырга әзер. Үзләре дә әллә ниләр эшләргә сәләтле, «Ак калфак»ка балалар белән яшьләрне дә җәлеп итәләр.

Бүлек эшчәнлеге инде күптән район кысаларыннан чыкты. Без Татарстанның Кыйбыч, Буа, Чүпрәле районнарындагы татар хатын-кызлары оешмалары белән эшлибез, Ульяновск өлкәсе Татар мәдәни үзәге белән элемтәдә торабыз.

«Иделкәй» һәм «Мирас» вокал коллективларыбыз республика һәм бөтенроссия дәрәҗәсендәге чараларда даими катнаша. Мин аларның җитәкчесе булып торам. Идел буе Болгарстанында ислам дине кабул ителүнең 1100 еллыгы уңаеннан Болгарда уздырылган чаралар циклында без «Илаһи моң» Рухи мирас әсәрләре фестивалендә катнаштык. Чувашиядә узган «Национальный хоровод» II Халык иҗаты төбәкара фестивалендә булып кайттык.

«Ак калфак»ның Тәтеш бүлекчәсе һәм Татар милли-мәдәни үзәге тәкъдим иткән «Тәтеш җәүһәрләре» Тәтеш районы командасы Казанда «Аулак өй – баттл» проектының ярымфиналында катнашты.

«Иделкәй», «Мирас» һәм «Шатлык» ансамбльләренә костюмнарны үзем махсус сатып алдым, тектердем. Хәзер районның үзешчән сәнгать коллективлары артистлары сәхнәдә күпкә күркәм күренә, шәһәрнекеләрдән калышмый.

Шулай да безнең оешма эшчәнлегенең төп максаты – татар телен һәм халкыбызның мәдәниятен, традицияләрен саклау. Милли мәдәният ул – халыкның хәтере, аны башкалардан аерып тора торган үзенчәлеге. Нәкъ менә шулар сакланса гына, без вакыт белән буыннар арасындагы бәйләнешләрне күрә, тоя алабыз, дәвамчанлык барлыкка килә.

Тамырларыңны белми, халкыңның традицияләрен сакламый торып, чын мәгънәсендә күркәм кеше тәрбияләп булмый. Ул да бит, нәрсәгә дә булса таянып, эти-әнисен, туган нигезен, илен яратырга тиеш, башка халыкларга карата да ихтирамлы булырга.

КАТАРГА БАРАМ!

– Сезгә Хатын-кызлар интернациональ берлегендә тору нәрсә бирә?

– Бу кече һәм урта бизнес белән шөгыльләнүче эшкуар хатын-кызларга ярдәм итәр өчен булдырылган төбәк иҗтимагый оешмасы. Төрле якларны үз эченә ала: хезмәттәшлекне дә, үсешне дә, бөтен дөньядагы синең кебек эшен алып баручы башка ханым вә туташлар белән элемтәләр, дуслык җепләрен дә. Менә, мәсәлән, апрель аенда без Россия ватандаш хатын-кызларның IV Евразия очрашуына Катарга барабыз. Ул Чит илдәге ватандашларыбыз эшләре буенча дәүләт комиссиясе химаясендә узачак. Чараның төп темасы – 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 80 еллыгы. Алдагы буыннарга күпмиллләтле Россия тарихын һәм рухи-әхлакый кыйммәтләрен дөрес итеп җиткерү турында фикер алышу, сөйләшү булыр, дип көтелә. 50 илдән 60 ватандашыбыз җыелачак анда. Мин пленар дискуссиядә катнашырга, чыгыш ясарга әзерләнәм.

ГАИЛӘ БӘХЕТЕ СЕРЛӘРЕ

Духовкадан саркылган башны әйләндергеч ис безнең казыбызның инде өлгереп җитүен хәбәр итә. Рима Гомәровна аны җәһәт кенә чыгара һәм турап та куя.

Сафиулловлар гаиләсенең бәйрәм табыны патшасы булган Тәтеш казын татыганнан соң, чак телне йотмыйбыз. Һәм инде «Татарстан» журналының традицион соравын да бирәбез, ниһаять:

– Рима Гомәровна, сез ирегез белән инде ничә дистә ел бергә – шатлыкта да, кайгыда да, шәһәрдә дә, авылда да, эштә дә, өйдә дә... Шәхси бәхет, гаилә иминлеге серегез нәрсәдә?

– Беренчедән, ирем әчми, бу – хәзерге заман өчен бик әһәмиятле, – ди Рима ханым. – Икенчедән, без икебез дә яраткан эш белән шөгыльләнәбез – авыл хуҗалыгы тармагында хезмәт куябыз. Без бу эшне бергә башладык, күтәрдек, тәвәккәлләдек, җиңеп чыктык... Кайчакта хәтта инде барып чыкмый бу, була торган нәрсә түгел, дигән чакларда да бирешмәдек... Без бер-беребезне аңлыйбыз. Бер-беребезгә һәм кешеләргә ярдәм итәргә яратабыз. Озын сүзнең кыскасы, без – бер дулкында.

Илнең авыл хуҗалыгы куркынычсызлыгын тәэмин итү.

Кунакчыл хуҗабикә.

Өченче меңьеллык хатын-кызы.

Үз халкының традицияләрен дәвам итүче.

Редакция Александр Сафроновка һәм аның «ТАТАВАТАР» проектына, «Милли хәситә» костюмернаясына, «Муллин йорты» оешмасына Казан сәүдәгәрләре костюмнарын биреп торганнары, шулай ук интерьерларында фотога төшү мөмкинлеген тудырганнары өчен рәхмәт белдерә.

«ТАТАВАТАР» проекты – Татарстан мирасында сезнең йөзегез. Татар аутентик костюмнарында кабатланмас фотосессияләр – бу объектив аша Үткәнгә кайтып сәяхәт итеп килү.

- Казан ханлыгы һәм сәүдәгәрләр чорының затлы костюмнары;
- Гаҗәеп локацияләр һәм Казанның төп истәлекле урыннары;
- Профессиональ фотографлар һәм аларның кадрда нәкъ менә сезнең үзенчәлекне чагылдыра алу осталыгы.

«ТАТАВАТАР» – фото гына түгел, ә Татарстан бизәкләреннән үрелгән үзе бер Тарих ул.

Тел. +7 999 1692825 vk.com/tatavatar t.me/tatavatar

«Муллин йорты» – төбәк дәрәҗәсендәге архитектура һәйкәле, ул үзендә төрле дәверләрдә яшәгән Казан татарларының шәһәр тормышын туплаган. Шәһәрнең мәдәни тормышы һәрвакыт гөрләп торган йорт бу. Татар мәдәниятен халыкка таныту юнәлешендәге төрле мәдәни проектларны бер түбә астында җыеп, аларга уртак бер кыйбла һәм юнәлеш биргән йорт.

Рима Гомәровна өстендә – XIX гасыр Казан татар сәүдәгәр хатыны костюмы. «Тәкыя бүрек» башлыгы – борынгы гравюралар буенча эшләнгән реконструкция. Традицион күлмәк, камзул, «яка чылбыры» күкрәк бизәвече.

ҮЗЕБЕЗНЕКЕЛӘРНЕ ТАШЛАМЫЙБЫЗ

Фото: Антон Катушонок

«Үзебезнекеләрне ташламыйбыз» – соңгы елларда гаять киң кулланыла торган әлеге гыйбарәне кемдер әйтә калса, шунда ук күз алдына алар килеп баса – Аня, Гүзәл һәм Катя. Кызлар – Яр Чаллы волонтёрлары, инде ике ел ярым алгы сызыктагы сугышчыларыбызга ярдәм итәләр. Аларның волонтёрлык отряды шулай ук атала да – «Своих не бросаем 16». 16 – безнең Татарстанның, ягъни төбәкнең номеры ул. Ә бу эш нәрсәдән башланган соң?

Николай Крушинин, Татьяна Вафина

АНЯ НИЧЕК ЯРДӘМ СОРАП КИЛГӘН...

– Барысы да... Анядан башланды, – дип искә ала волонтёрлыгының беренче көннәрен **Екатерина Шульга.** – Күз алдына китерегез: мин ул чакта администрациядә эшлим, кабинетыма бик каттә матурлык салоны тотучы ханым ярдәм сорап керде. «Мин сезгә ярдәм сорап килдем!» – дип мөрәҗәгать итте ул. Башта аптырабрак калдым. Мондый күз явын алырдай ханым нинди ярдәмгә мохтаҗ икән, дим.

Аня махсус хәрби операция өчен гуманитар ярдәм җыю белән шөгыльләнә булып чыга. Туп-туры үзенең матурлык салонында – Яр Чаллы уртасында. Сугыштагы ир-атларга ярдәм итәргә теләүчеләр посылкаларны аңа шушында – салонга китерә. Анда инде алма төшәр урын да калмый. Шуннан соң Аня социаль челтәрләрдә ярдәм сорап мөрәҗәгать итә. Сорап кына түгел, ә ялварып, чөнки салоны урнашкан йорт администрациясенең дә, анда яшәүчеләрнең дә ачулары килә башлый. Бөтен ишегалды тартмалар һәм каплар белән тулган. Халык нәрсәне кирәк дип таба, барысын да бирегә ташый, фанерага хәтле. Йортка машиналар якын килеп туктый алмый – тирә-як, әйтерсең, шин-аккумулятор-генераторлар склады. Ул үзе генә бу кадәр «байлык»ны кабул итеп, теркәп, аерып, берләштереп озатып җибәрергә өлгерә алмый...

КАТЯ НИЧЕК ВОЛОНТЁР БУЛЫП КИТӘ

– Әнә шул чакта Катерина килеп кушылды да инде, – дип искә ала **Анна Артемьева.** – Гуманитар ярдәмне кабул итү пунктларын ачу белән бик булышты – хәзер алар шәһәрдә тугызау. Таныш депутатына мөрәҗәгать итте – ул да сүзгә колак салды, хәзер дә командага ярдәм итеп тора. Бу аның складларының берсе. – Аня тартмалар-каплар-төргәкләр һәм башка МХО зонасында кирәкле әйберләр белән шыплап тулган як-ягын күрсәтә. – Склад һаман да – кулланылышта, без монда әйберләрне аерабыз да Түбән Камага илтәбез. Шуннан инде йөк «БАРС»ларга, «Тимер»гә, «Алга»га – безнең барлык исемле полкларга китә.

Йөкләрне илтеп тапшыру өчен кызлар үзләре махсус хәрби операция зонасына барып йөри: даими рәвештә, кварталга бер мәртәбә. Алар белән әле тагын бер матурлык салоны хуҗабикәсе Гүзәл-Гуля да эшли. Менә шундый матур гөлләмә.

– Безнең командада Фәннур абый да бар, – дип, өчесе берьюлы җавап бирә кызлар, һәм карашлары җылынарак төшә. – Ул – машина йөртүчебез. Шундый шәп абзый! Аның белән разведкага да барырга, утны-суны да кичәргә була! Ул, барыбызның яшен бергә кушсак та, олырактыр. Әмма Фәннур абыйны беркемгә дә алыштырмыйбыз!

ОНЫТЫЛА БАРГАН СЫЙФАТЛАР НИЧЕК КАБАТ УЯНА

Хәвефле сәфәргә кызлар өч айга бер кузгала, дидек.

Аня белән Гүзәлгә җиңелрәк, алар үзләренә үзләре хуҗа, дигәндәй. Ә менә Катеринаның законлы отпуск көннәрен тулысынча диярлек юлга чыгасы вакытка туры китерергә кирәк. Җитмәсә, улы да бәләкәй. Элек алар ялларын гел бергә уздыра торган булса, хәзер бала әнисенең отпуск көннәрендә әбисе белән калып тора.

– Алгы сызыкка бару куркыныч түгелме?

– Без бит куркак кызлар түгел! – дип җавап кайтара алар бертавыштан.

– Бер сугышчы безне «безбашенные» дип тә атады. Ә аннары мин үзем дә сезнең белән бер дулкында дип өстәде, – дип елмая Аня.

– Беләсезме, – дип аңлатырга керешә **Гүзәл Гафиятуллина.** – Анда алар барысы да бөтенләй икенче төрлегә, чын ир-атларга әйләнә. Тыныч тормышта кайчагында ипи белән сөт алырга кибеткә чыгарга да иренгән ирләр кинәт кенә чын-чынлап үзгәрә, җитдиләнә. Ир-атка хас булган, онытыла башлаган сыйфатлар уяна: йорт та салалар – җирне казып хәтта, мохтаҗларга булышалар һәм, әлбәттә, туган илне саклыйлар…

– Алар барысы да шундый шәп егетләр, – дип өсти Катя. – Бөтенләй икенче төрле. Үзләренчә безне әрләп тә алалар, янәсе, сез нәрсә, өегезне, гаиләгезне, балаларыгызны ташлап, монда – җәһәннәм тишегенә кадәр килдегез… Монда бит сугыш, әйберләр китерәм, дигәч тә, сак булырга кирәк, янәсе… Борчылалар безнең өчен, күренеп тора. Әмма көтеп тә алалар. Алар бит өйләрен, анда калган якыннарын бик сагына.

СОЛДАТЛАР НИЧЕК ТУГАНГА ӘВЕРЕЛӘ

– Волонтёр кызлар алгы сызыкка юкка гына йөрми, үзенә ир табар өчен бара, дип тә сөйлиләр…

– Кинәт кенә кабынган мәхәббәтне, әлбәттә, бернишләтеп тә булмый, – дип елмаеша кызлар, Аняга күз сирпеп. Ул күптән түгел генә хәрби операциядәге сугышчыга кияүгә чыккан. – Әмма волонтёрларның миссиясе башка, гуманитар ярдәм күрсәтү. Алгы сызыкка ешрак ирләр йөри, билгеле. Йә булмаса, ирләре, туганнары, уллары шунда булган хатын-кызлар…

– Мин үзем бу эшкә, мобилизация башланып, чәч кистерергә йөри торган күп кенә ир-егетләр китә башлагач керештем, – дип искә ала Гүзәл. – Баштарак иң кирәкле нәрсәләрне җыя башладым: бинтлар, дарулар, салфеткалар… Берничә тартма тупладым да, кем белән җибәреп була икән дип, эзләргә тотындым. Шулай итеп Аняга юлыктым. Без икебез дә бьюти-өлкәдән, бер-беребезне шунда ук танып алдык. Бергә эшли башладык. Фронтка йөкне инде сигез мәртәбә илтеп кайттык. Һәр өч ай саен барырга тырышабыз. Курку беренче кат юлга чыкканда гына булды, хәзер инде барысы да таныш. Исәрләр генә курыкмый, диләрме әле. Ләкин анда баргач, шулкадәр ышанычлы, ир-егетләр – таш кыя кебек. Анда үзеңне мондагыга караганда якланганрак итеп тоясың әле хәтта. Егетләрнең кыйммәтләре инде башка, алар чын-чынлап олпатланып киткән. Безнең килүебез дә алар өчен саф һавадай. Үземнең салоныма йөрүчеләрне дә очраттым. Алар миңа инде тугандай якын хәзер. Көтәләр, гел сорап торалар: тагын кайчан киләсез, диләр. Аларны истә тотуларын беләселәре килә, онытмауларын. Кайгыртуларын. Сугыш шартларында бу – бик мөһим. Без «Тимер» белән «Батыр»га йөрибез, башка кайбер полкларга да. Себердәнме егетләр, көньяктанмы – барысына да булышырга тырышабыз. Алар бит барысы да – безнеке. Инде туганнарыбыз диярлек.

АНДАГЫ ХАЛЫК БЕЗНЕҢ ЕГЕТЛӘРНЕ НИЧЕК КӨТӘ

Соңгы тапкыр кызлар алгы сызыкка Раштуа алдыннан, гыйнвар аенда барганнар.

– Медротага бардым, «Алга» батальонына. Урамда торам, кофе йоткалыйм, ә ир-егетләр безнең машинаны ремонтлый, – дип искә ала Гүзәл. – Шулчак яныма бер бабай килеп басты. 76 яшь миңа, ди. Рус икән. Чыгышы белән – Таулы Алтайдан. Хатыны да рус булган, Новосибирскидан.

Хәзер ул инде берьялгызы калган, аңа безнең егетләр ярдәм итә. Шуннан китте бу миңа сөйләп… – Гуля, Бахмут янындагы хатирәләренә әйләнеп кайткандай, уйга талып, берара эндәшми торды.

СВОИХ НЕ БРОСАЕМ 16

– Ул миңа тормышындагы иң бәхетле көн турында сөйләде. Шул ук көн аның иң зур кайгылысы да булган икән… – дип хатирәләргә бирелә Гүзәл. – Алар хатыны белән икәү яшәгәннәр, базга яшеренгәннәр. Чыгып китәргә җайлары булмаган, дошманнан ни генә күрмәгәннәр. Кача-поса гына, ашарга эзләнеп, бабакай кайчак баздан чыга торган булган… Кинәт, дип сөйләде ул безгә, капкага шакыдылар, солдатлар булып чыкты. «Курыкма, без – үзебезнекеләр!» – диләр болар миңа… «Үзебезнекеләрме-юкмы, белмим, кем сез?» – дип, сорау белән җавап биргән бабай. «Тагын кем дә булса бармы?» – дип сораганнар капка шакучылар. «Керегез, карагыз», – ди икән бабай.

Кергәннәр. Караса, формалары башка, ә егетләрнең берсе – кысыграк күзле, бурятка охшаган. Шевроны – русныкы. «Чынлап та безнекеләрме икән?» – дип, шикләнә калган бабаебыз. Хәтта елап та җибәргән. Хатынына әйтә икән: «Чык, әнисе! Безнең егетләр, ниһаять, килеп җиттеләр!» Хатыны да баздан чыккан, кулларын чайкап, елап җибәргән. Һәм, кичерешләрне күтәрә алмыйча, шунда ук егылып… үлеп киткән. Көтеп җиткергән дә үлгән.

Менә шундый анда тарихлар…

КУРКУСЫЗЛАР ӨЧЕН ИҢ КУРКЫНЫЧЫ НӘРСӘ

– Волонтёрлар эшендә иң куркынычы нәрсә?

– Физик яктан алганда, хәзер инде җиңелрәк, – дип искә ала Катя. – Барысы да җайга салынды,

эзгә төшеп утырды. Ярдәм кулы сузучылар да – җитәрлек. Баштагы айларда бик читен иде: тартмаларны үзебез ташыйбыз, машинага кертеп өябез… Тәгәрмәчләр, тимер-томырлар – барысын да үзебез ташыдык… Ә алар авыр, каһәр! Хәзер иң мөһиме – карап-барлап, җайга салып тору, чылбырның өзелмәвен тәэмин итү. Социаль челтәрләр аша акчаларның кучүен күзәтеп бару, сатып алу, кирәк-яракларны, заказларны туплау, складта йөкне кабул итеп алу, фурага төяү – моны без инде билгеле бер тәртип буенча башкарабыз. Чираттагы экспедициягә әзерлек бара, май бәйрәмнәрендә чыгарга торабыз. Анда минем дә буш көннәрем бар, Аня белән Гуляның да салонында заказлар көтелми.

– Курку белмәгәннәрнең эшендә иң хәвефлесе нәрсә?

– Дусларны югалту, – дип анык җавап бирә Катя. – Без инде күпләрне җуйдык. Бер килүеңдә кеше бар, икенче юлы килгәндә инде юк. Моңа күнегеп булмый. Ә егетләргә ничек авырдыр… Аларның күз алларында бара бит ул хәлләр…

ТОРМЫШ НИЧЕК КИТАПКА ӘВЕРЕЛӘ

Махсус хәрби операция зонасына кызлар беренче тапкыр 2023 елның апрелендә бара. Шунда алар легендар мотоциклчы-коткаручы Фаза белән очраша. Позывное Дербент булган взвод командиры волонтёрлар белән эшләүне аңа тапшыра – каршы алырга, барысын да күрсәтергә, сөйләргә, аңлатырга, ашатырга, кыскасы, туганнарыдай кайгыртырга.

Фазаны шунда ук үз итәләр. Тыйнак, артык күзгә бәрелеп тора торган түгел, әмма бер үк вакытта искиткеч актив, күтәренке рухлы. Кызларны атарга да өйрәтә. Шаярта-көлдерә, парашют белән ничек сикергәнен сөйли. Сугыш беткәннән соң, Минзәләгә барып, бергә сикерергә тәкъдим итә. «Сугыштан соң», дигәндә, күзләре моңсуланып китә…

Сугыш турындагы барлык сорауларга да болай гына җавап бирә: «Кызлар, сезгә бу нәрсәгә инде, йә… Сез бит кызлар! Әйдә, сезнең турыда сөйләшик. Балаларыгыз бармы сезнең?»



«Минем улым бар», – дип, шунда ук җавап бирергә ашыга Катерина. Ничек икән анда аның Семёны хәзер?

«Исеме ничек? – дип, җанланып китә Фаза да. – Кем белән калды? Нинди секцияләргә йөри?»

Алар әле Катяның улы Семён турында озак гәпләшәләр. Балаларының шуклыкларын искә алалар, көлешәләр… Андый «тыныч», «имин» сөйләшүләрне Фаза бик ярата. Гүяки үзе дә җылынып, эреп, йомшарып китә, рәхәтләнеп шаярта, төрттерә, киңәшләр бирә. Кызларның балаларын, кайткач, барысын да парашют белән сикерергә өйрәтәм, дип вәгъдә бирә – булганнарын да, булачакларын да. Шундый каһарман эниләрдән тусыннар да…

Инде гражданкада. Һичшиксез. Кайткач.

Туганнарга әверелеп бетеп аерылышалар.

Ә аннары – Бес – аның командиры – фотолар юллый: мотоциклда очып барган Фаза. Яза да: бүген, ди, Фаза сугыш кырыннан алты яралы егетне алып чыкты.

Шуннан бирле кызлар аның мотоцикллы тормышы һәм каһарманлыклары хакында барысын да белеп тора. Дербент, Просвет, Профессор, Бес һәм башка егетләр, ярдәмче алиһәләренә хәбәр салып, үз хәлләре турында сөйләп торалар. Кызлар исә, үз чиратында, Фазага мотоцикл өчен запчастьлар алып бара, берсендә хәтта – өр-яңа «Урал» да. Аны Фазага армия дусты сатып алып юллый.

Барысы да Фазаны «үлемсез» дип атый, аңа соклана. Чөнки Фаза шикелле миналар, дроннар һәм башка төр шартлаткычлар арасында бер тәгәрмәчтә яшен ташыдай йөри алучы башка берәү дә юк. Аңа җил иярми…

Ә аннары, 2024 елның җәендә, Фаза… һәлак була. «Урал»ы белән бергә. Минага эләгеп шартлый. Һәм аның җирдәге тормышына нокта куела.

Озакламый бу хакта китап дөнья күрәчәк. «Призрачный гонщик» дип аталачак ул.

Фото: Александр Ефремов, Ксения Ульянченко архивынан. РЕКЛАМА

КСЕНИЯ БРИЛЛИАНТ ҺӘМ КОРОЛЬНЕ САЙЛЫЙ

Дмитрий Сивков

Татарстан халкына бүген боланнарны күрү өчен Ерак Төньякка чыгып чабарга кирәкми. Моның өчен Татарстанның Мальцево авылында урнашкан «Дух Севера» этнопаркына бару да җитә.

МАТЕМАТИКАНЫ ВЕТЕРИНАРИЯГӘ АЛЫШТЫРУ

Төбәктә төньяк халыклары мәдәниятен алга сөрүче якташларыбызның хәлләрен белер өчен Алабуга төбәгенә дә чыгып китәргә туры килмәде бу юлы. Гаилә бизнесы вәкилләренең берсе – Ксения Ульянченко хәзерге вакытта үз вакытының күп өлешен Татарстан башкаласында үткәрә. Казан дәүләт ветеринария медицинасы академиясенең икенче курс студенты атнасына биш көнен укуга багышлый, ә ял көннәрендә, рәхәтләнеп ял итәр өчен, яраткан төньяк боланнары, якут лайкалары, хаски һәм маламутлар янына – туган авылына кайта. Әгәр дә инде карбураннарга уралып табигатьтә йөреп кайтасы килә икән, моны болан җигемендә түгел, этләр җигеп тә башкара ала. Шундый кызыклы шөгыльләре, башка тагын бик күп нәрсәләр турында Ксения «Татарстан» журналы редакциясенә кунакка килгәч сөйләде.

– Ксения, ни өчен ветеринария юнәлешен сайларга булдыгыз?

– Белсәгез иде, бу сорауны миңа күпме ишетергә туры килде: дусларымнан, танышларымнан һәм туганнарымнан! Ә күпмесенә аңлатырга! Ярый әле бу юлымны әнием тулысынча хуплады һәм шикләнергә урын калдырмады. Ә сигезенче сыйныфка кадәр мин үземне киләчәктә саннар дөньясында күрә идем. Әти-әнием «Дух Севера» этномәдәни паркын оештырырга керешкәч, максатларым үзгәрде.

Әйе, Ксения бала чакта Айболит булырга хыялланмый. Тирә-юнендә төньяк боланнары, төрле токымлы этләр пәйда булуын, аларның саны даими үсә баруын күргәч кенә, математика мәктәбендә укучы кыз өчен әйләнә-тирә мохит, дөнья бөтенләй үзгәрә дә куя.

Хайваннарның артуы аларның сәламәтлеген кайгырту таләбен дә куя – вакцина ясау, яраларны дәвалау. Бу якны карауны үз өстенә алырга туры килә кызга, әти-әнисе Юлия Викторовна белән Дмитрий Евгеньевич башка бизнес белән дә шөгыльләнә (Чаллыда шактый танылган «Пифагор» компаниясе түшәм тарттыру буенча эшли), шуңа күрә хайваннарны карарга вакытлары җитеп бетми. Тугызынчы сыйныф укучысына яңа шөгыль авырга туры килми, хәтта мавыктыргыч да тоела, өстәвенә янәшәдә яхшы остаз да була.

– Әлбәттә, безгә ветеринар хезмәтеннән дә файдаланырга туры килде, ансыз һич булмый. Шунысын әйтергә кирәк: безгә бәхет елмайды, янибызда чын профессионал гына түгел, шәхес буларак та кызыклы кеше пәйда булды. Илфат исемле ул. Ул миңа ветеринарияне бөтенләй башка, җәмгыятьтә, бигрәк тә авылдагы күзаллаудан аерылып торган яктан ачты. Янәсе, катлаулы, бигүк кызыклы булмаган һөнәр, күбрәк колхозда гына кирәк. Ә бит бу җитди операцияләр, диагноз кую, дәвалау кебек мавыктыргыч хезмәт тә икән.

Башта бу ниндидер хобби кебек иде, тик чыгарылыш сыйныфында мин үземне ветакадемия студенты итеп кенә күрдем. Мәскәүгә һәм Казанга кереп карадым. Башкалада да бюджетка үттем, әмма ахыр чиктә барыбер туган төбәгемдә укырга карар кылдым, – дип сөйләде редакциябез кунагы.

– Димәк, сез бәхетле кеше, хобби һәм һөнәрне туры китерә алгансыз. Мөгаен, группадашларыгыз арасында андыйлар аздыр.

– Шулай дип уйлыйм. Күпләр ветеринария белән мавыкса да, мөгаен, андый ук дәрәҗәдә түгелдер, чөнки бу мавыгу күбрәк теория өлкәсендә һәм миндәге кебек практика белән ныгытылмаган.

КАЮР БУЛЫП ТУМЫЙЛАР

– Шулайдыр, бигрәк тә республикада җигүле спорт белән шөгыльләнүчеләрнең берсе сез икәнен исәпкә алганда. Ничек каюр булып киттегез?

– Үзеннән-үзе шулай килеп чыкты. Бездә беренче дүрт хаски пәйда булгач, без алар буенча мәгълүматны өйрәнә башладык. Аларның җигелә торган этләр токымы икәне ачыкланды. Җигем өчен кирәк-яраклар сатып алырга булдык. Беренче нартлар, кем әйтмешли, сыйфатлы булмады – бик тиз, беренче егылуларда ук ватылдылар.

– Беренче вакытларда нартларны гына түгел, маңгайны да ватарга туры килдеме?

– Әйе, сүзнең туры мәгънәсендә дә. Чөнки республикада җигүле спорт төренә беркем дә өйрәтми. Шулай булгач, сынаулар, хаталар һәм егылулар аша үзлегемнән өйрәнергә туры килде. Беренче мәлләрдә мәтәлеп калган, агачка килеп төртелгән чаклар да булды, аннары гына тынычлап, рәхәтләнеп йөрисең, ярышларда катнаша аласың. Әйе, каюр булып тумыйлар, аңа өйрәнәләр.



Ксения якут лайкасы токымыннан булган Индиго белән бергә. Индиго җигемдә генә йөрми, төрле күргәзмәләрдә призлар да ала.

– Ә бу ярышлар кайда үткәрелә? Нинди уңышларга ирештегез?

– Мондый ярышлар, нигездә, Ижевскида уза. Анда җигүле спорт федерациясе бар. Спортның әлеге төрен үстерү белән ныклап шөгыльләнәләр. Ә уңышларга килгәндә, медальләргә барып җитә алмадым әле. Әмма ике ел элек беренче ярышларда ук финишка алты катнашучы арасыннан өченче булып килдем. Моны яхшы нәтиҗә дип саныйм. Быел, кызганыч, уку белән мәшгуль булу сәбәпле, ярышларда катнашырга вакыт җитмәде. Аның каравы, миннән 10 яшькә кечкенәрәк сеңелем Кира үсеп җитте. Күптән түгел генә балалар стартларында ул дүртенче урынны алды – беренче урын белән аерма нибары 5 секунд булды.

Һәм гомумән, безнең этнопаркта хәзер волонтерлар да бар, аларны мин нартлар белән идарә итәргә, этләр белән шөгыльләнергә өйрәттем. Күптән түгел алар 20 чакрымга узышта катнаштылар. Этләр ике көн эчендә 40 километр юл үтте. Бу шактый җитди сынау булды, һәм аны барысы да җиңеп чыкты.

– Ә гомумән нинди дистанцияләрдә катнашасыз?

– Спринт – биш километр һәм җигелгән алты эт. Мид – егерме чакрым һәм сигез эт.

– Кар өстеннән нарт тартып йөгергән геройларның исемнәре ничек?

– Бриллиант – җигемдә төп эт, Туйгун, Компот, Ангара, Стрелочка, Чук, Флинт, Хотуша, Стихия, Карамель, Коржик, Хаяша, Буря, Король, Индиго. Гомумән бездә 55 эт бар, 45е җигелә торган этләр токымыннан: маламутлар, якут лайкалары, хаскилар. Тагын 10 эш аты: рус кара терьеры, төрек кангалы һәм Бельгия овчаркалары.

– Ә кайсыларын күбрәк яратасыз?

– Бриллиант белән Корольне.

Кызларга лаек җавап.

ЕСЕНИН УРАМЫНДА БОЛАН КӨНЕ

– Ләкин «Дух Севера» этнопаркында башка «йолдызлар» да бар бит. Боланнар турында әйтүем.

– Әйе, мин этләр өчен җавап бирәм, боланнар – хезмәткәребез Светлана Дмитриевна карамагында. Аның атлар белән 30 еллык эш тәҗрибәсе бар, боланнарны бик тиз үз итте, аларны чанага ияләштерде, кулга килерлек ясады – хәзер аларның барысын да сыйпап карарга була. Бездә сигез төньяк боланы һәм ике тимгелле болан бар, бу затлы боланнар токымының иң матур вәкилләренең берсе. Менә май аенда артым көтәбез – дүрт болан баласы дөньяга килергә тиеш. Гомумән бездә сигез болан баласы туды, өчесен башка паркларга озаттык.

– Сүз уңаеннан, сез аларга нәрсә ашатасыз? Мөгаен, шул ук атлардан аермалы тукландыру үзенчәлеге бардыр.

– Әлбәттә, бар. Хайваннар бит үзләренең туган ареалында яшәми, шуңа күрә аларның микрофлорасын сакларга кирәк. Әлбәттә, болан мүге бирәбез. Елына сигез тоннага кадәр мүк китә, моннан тыш – бөртекле катнашмалар, кальций өчен балык-сөяк оны, кышын – печән, сезонында – үлән. Гөмбә яраталар, кайвакыт шул тәмлүшкә белән сыйлыйбыз.

– Ә сезгә килгән кунакларны нинди сый көтә?

– Бездә кафе буларак кулланыла торган юрта бар (сүз уңаеннан, анысына да мин җаваплы). Төньяк кухнясына кергән төрле ризыклар тәкъдим итәбез. Мәсәлән, чага чәе һәм ботка.

– Төньяк боткасы рецепты белән бүлешә аласызмы?

– Ул бик гади: казанга томалап пешерелгән болан ите тезәбез, өстенә карабодай салабыз, ярманы бер-ике сантиметрга капларлык итеп су өстибез, утка куябыз... һәм 20 минуттан ризык әзер була. Бернинди суган һәм кишер дә юк, чөнки алар тундрада үсми. Шулай да 21–23 февраль көннәрендә уздырыла торган Болан көнендә меню баерак була: уха, узвар һәм болан ите, саз җиләгеннән эшләнгән тәм-томнар һәм тундра чәе.

– Ул көннәрдә Есенин урамындагы резиденциягезгә ничә кеше килде, аларның күңелен ничек күрдегез?

– Меңләп кунак кабул иттек. Күңелсезләнергә юл калдырмадык. Тәм-томнардан тыш,

чын шаман барабан тамашасы күрсәтте, этнодискотека, Төньяк халыкларының традицион уеннарын һәм күңел ачуларын тәкъдим иттек. Әлбәттә инде, алар боланнар белән дә, этләр белән дә аралашырга, хаски-бананда шуганнан соң, чумдагы учак җылысын тоярга мөмкинлек алды.

ӘНИ ҮРНӘК БУЛЫП ТОРА

– Болан көне төньяк халыкларында бик популяр, шуннан үрнәк алдыгызмы?

– Күпмедер дәрәҗәдә әйе. Өстәвенә, узган ел без әни-әти белән бергә Салехардка Болан көненә бардык, Ямал-Ненец автоном округында, Поляр түгәрәктәге шәһәр ул. Безне моңа кызыксыну гына түгел, тәҗрибә туплау теләге дә этәрде. Нәрсәләрнедер хәтердә калдырдык. Шунсыз булмый. Чыннан да, төп халык өчен бу бәйрәм генә түгел, ә безнең Сабантуйга охшаш мөһим вакыйга. Мальцевода узган Болан көне дә тора-бара республика халкы өчен ниндидер җәлеп итү ноктасына әверелер, дип өметләнәбез.

– Сез бик максатчан һәм ныклы ихтыяр көченә ия кыз дигән тәэсир калдырасыз. Бу, мөгаен, әниегездәндер?

– Әйе! Әнием – минем өчен хатын-кыз эталоны. Чибәр, акыллы, гадел, нәрсә теләгәнен төгәл белүче, «Максатны күрәм – каршылык күрмим» принцибы буенча эш итүче, шул ук вакытта – яхшы күңелле кеше. Мохтаҗ булган һәркемгә ярдәм итәргә әзер. Әгәр шигъри сәләтем булса, әнием турында поэма язар идем.

– Сез мордва гаиләсеннән. Туган телегезне, халкыгыз традицияләрен беләсезме?

– Телне шәп беләм дип әйтә алмыйм. Бабай белән әби, ягъни әниемнең әти-әнисе, өйдә мордвача аралаша. Әни дә иркен сөйләшә. Мин аларны аңлыйм, берничә җөмлә әйтә алам. Әмма кайчан да булса мин, һичшиксез, туган телемне өйрәнәчәкмен һәм традицияләрне үзләштерәчәкмен. Моны мөһим дип саныйм. Өстәвенә, өйрәтер кешеләрем янәшәдә. Әни шулай ук халык мәдәнияте белән мавыга, аның күлмәкләре, бизәнү әйберләре бар...

– Ә сезне кем күбрәк тәрбияләде?

– Эш шунда ки, мин әле кечкенә чакта ук әти белән әни үз бизнесларын нульдән төзи башладылар, шулай булгач, мине тәрбияләү буенча төп мәшәкатьләр әбием Мария Петровна җилкәсенә төште. Ул вакытта аңа 45 яшь иде, ул миңа, мөгаен, кече кызы кебек карагандыр.

Шулай булгач, көндәлек тормышның асылын миңа әбием төшендерде. Ә инде соңрак, бу сүзнең тулы мәгънәсендә, тормышның нәрсәдән гыйбарәт булуын ачарга миңа әнием булышты. Моның өчен мин аңа бик рәхмәтле. Ул, һичшиксез, – гаиләбез галәменең һәм аның тирәсендәге барлык нәрсәнең үзәге. Миңа әнием кебек булырга омтылырга гына кала.

«Дух Севера» этнопаркы экипажы трассада.

Ксениянең әтисе – Дмитрий Ульянченко җигемне ярыш дистанциясенә җибәрергә әзер.

Ксениянең әнисе – Юлия Ульянченко Валера атлы болан белән. Этнопарк кунакларына боланнарга мүк ашатырга рөхсәт итәләр.

Фото: Александр Ефремов, Гөлфизия Камалиева архивыннан

«АК БАРС» ӘБИСЕ

Дмитрий Сивков

Казанда яшәүче Гөлфизия Камалиева алтмыш яшенә кадәр спорт дөньясыннан бик ерак була. Казаныбызда узган ярышларга да барып йөрми, телевизордан карарга да яратмый. Әмма барысын да бер очрак хәл итә.

Бервакыт Гөлфизиянең бертуганы яшүсмер кызы белән «Татнефть Арена»га хоккейга барып кайтуын үтенә. «Ак Барс»ның фанзонасына билетны бертуганының кызы укыган көллияттә студентларга бушлай бирәләр. Тик кыз әле балигъ булмаганга, аны трибунага олы кешесез кертмиләр.

– Киттем инде. Дөресен генә әйткәндә, барып йөрисем дә килмәгән иде. Хоккейны берничә мәртәбә телевизордан күргәнем бар: типсә тимер өзәрлек ирләр тимераякта бер алка артыннан йөгереп йөриләр, этешәләр-төртешәләр, сугышалар... – дип, елмаеп искә ала Гөлфизия Госмановна ун еллар элек булган вакыйганы.

Ә үзең барып караган уен бөтенләй башкача күренә, бөтенләй башка тәэсирләр калдыра икән бит.

Арена, андагы атмосфера, җаны-тәне белән үз командасын яклаган тамашачы – барысы да шаккатыра аны. Ул төнне Гөлфизия Госмановна озак йоклап китә алмый: уен мизгелләре бер-бер артлы искә төшеп, күз алдыннан китми...

Иртән инде ул икенче кеше булып уяна. Тиздән клуб фанатлары аны, яратып, әби дип йөртә башлаячак, телетрансляция операторлары да үз камераларын тырышып-тырышып аның үзенчәлекле түбәтәенә көйләргә омтылачак.

БӨТЕН МИЗГЕЛЛӘР ТЕРКӘЛЕП БАРА

Бу өр-яңа дөньяны, фанатлар әйтмешли, «Галя түти» үзенә хас үҗәтлек белән ача бара: үзебездә үткән бер матчны да калдырмаска тырыша, уенның бөтен кагыйдәләрен өйрәнә, уенчыларның исемнәрен ятлый, кем кайсы номер белән уйный, кем кайсы уенда үзен ничек күрсәтә. Хәтеренә ышанып бетмәгәнгә, статистика өчен калын дәфтәр башлый. Алары да бүген инде шактый. Әлеге «хәтер файлларына» күз салу кызык булыр иде.

– 2018 елны «Ак Барс»ка җиңү китергән Гагарин Кубогы финалында ЦСКА капкасына «алтын» голны кем кертте?

«Әби» «амбар кенәгәсенең» битләрен кыштырдатып ала да болай ди:

– Канадалы Роб Клинкхаммер, 49 номер.

Бөтен мизгелләр теркәлгән бит. Бу «вакыйлык» героинябызның холкында – типографиядәге хезмәттәшләре аны тикмәгә генә, мәзәкләп, «ОТК» дип йөртмәгән. Мондый кешеләр барысын да контрольдә тота. 2010 елда пенсиягә чыкканчы, Гөлфизия Камалиевага иң мөһим заказларны басмага китәр алдыннан карарга бирәләр, чөнки ышаналар. Әле бүген дә вакыт-вакыт, заказлар күп булганда, эшкә чакырып алалар.

Фанатка әйләнгәч, Гөлфизия Госмановнаның хоккей турындагы мәгълүматлары гына артмый. Элек ул, авылга кайтып килүне санамаганда, Казаннан кая да булса бик сирәк чыгып йөри. Отпуск вакытында берничә тапкыр Мәскәү һәм Ленинградта була, бер-ике мәртәбә Воронеждагы туганнарына кунакка бара. Ә бүген җанатар сыйфатында ул булган урыннарны билгеләп чыксак, карта Яңа ел чыршысына охшап калачак. Континенталь хоккей лигасына кергән командалар шәһәрләреннән Минскида, Хабаровскида һәм Новосибирскида гына булмаган. Ә болай барысын да йөреп чыккан – Владивостоктан Швейцария Давосына кадәр, анда үз вакытында «Ак Барс» белән «Салават Юлаев» арасындагы матчлар узган иде.

ТҮБӘТӘЙ ҺӘМ 116 НЧЫ НОМЕР

Гөлфирә Госмановна әйтүенчә, хоккей белән «чирләгәннән» бирле үзенә канатлар үскәндәй тоя. Яшәреп китүен дә сизә, бу җирем, теге җирем авырта дип, зарланулар онытыла. Ә сәламәтлек фанат өчен мөһим бит, бигрәк тә уеннар башка шәһәрләрдә булганда. Башта озын юлны узарга, аннары матчның буеннан-буена аякта басып торырга кирәк.

Өйдәге уеннарда исә фанзонада «Галя түти»гә «прогул» куялар. Ул боз мәйданчыгына бераз якынрак булган 17 нче секторга абонемент сатып ала. Ләкин фанатлар аның: «Алга, Ак Барс!» дигән тавышын яхшы ишетә.

Ә тышкы кыяфәтенә килгәндә, бүген «Ак Барс» «әбисе», мөгаен, клубның иң таныла торган җанатарыдыр, һәм аны хәтта клубның рәсми булмаган талисманы дип тә атарга буладыр.

«Ак Барс» түбәтәе өстеннән ак яулык япкан әби образы бик тиз истә кала башлый.

– Җанатар булуга ук диярлек шундый түбәтәй киясем килде, ләкин заказ бирергә урын таба алмадым. Шулай да Аллаһы Тәгалә мине ишетте. «Татнефть Арена»дагы уеннарның берсендә кызыклы түбәтәй кигән ир-атны

Гөлфизия Госмановна фан-клубтагы яшь дуслары арасында күчмә уенда.

күреп алдым. Түбәтәйне хатыны теккән икән. Ул миңа ярдәм итәргә ризалашты. Түбәтәемне нәкъ менә Түбән Камага «Нефтехимик» белән плей-офф уеннарының тәүге раундына барганда өлгерттеләр. 2020 елның марты иде. Биш ел инде, димәк, матурланып йөрим. Юбилей икән! – дип көлә әңгәмәдәшем.

Ә аның хоккей свитерындагы значокларын күрсәгез! КХЛга кергән барлык клублар значоклары бар анда. Өстәвенә, кечерәйтелгән Гагарин кубогы значоклары өчәү – яраткан командабызның җиңүләре санынча. Лига фанатларының кайсы гына мондый байлык белән мактана ала икән. Яшьләр кайчак: «Галя түти, кара көнгә сатарлык әйберләрең бар инде», – дип тә шаярткалыйлар.

Сүз уңаеннан, җанатар коллегалары да аның имиджын баеткан: 8 Мартка «АВIКА» дип язылган һәм автомобиль номерларында Татарстанны аңлаткан 116 номерлы челтәр (хоккей свитеры) бүләк иткәннәр. Хәзер бер генә матч та аның белән фотога төшмичә узмый икән.

– Кешеләр килеп-килеп фотога төшүне үтенәләр, мин беркайчан да баш тартмыйм. Түбән Камада арена бездәге кебек зур түгел. Кайчак селфи ясарга теләүчеләрдән «бөкеләр» хасил була, – дип көлә Гөлфизия Госмановна.

ӘФСЕН ҺӘМ КАДЕРЛЕ ҖИҢҮ

Ләкин ул барысыннан да канәгать дип әйтеп булмый. Мәсәлән, әби Казан җанатарлары үз командалары өчен тиешле дәрәҗәдә җан атмый, дип саный. Ул чагыштыра ала. Петербург, Омск яки Уфа трибуналары Казанныкына караганда күпкә көчлерәк гөрли, ди. Шуңа күрә матч алдыннан йөрергә, тамашачыларны активрак булырга өндәргә туры килә. Дөрес, бервакыт аны полиция туктатып: «Җитәр инде өндәп йөрергә!» – дигәч, ачыктан-ачык болай эшләүдән тукый. Ләкин барыбер үз миссиясен дәвам итә.

Тагын әле балаларның Кыш Бабайга үтенечләренә охшаганрак, бераз беркатлы һәм самими ритуалларын да күрсәтми генә башкара. Ләкин сөйләшкәндә яшерми: «Әфсенлим!» – ди. Кайвакыт килеп чыга да, күрәсең, АНДА бу ялваруларны ишетәләр.

– 4 февральдә Санкт-Петербургта безнекеләр СКАны 8:3 исәбе белән җиңде. Ә «Ак Барс» һөҗүмчесе Артем Галимов беренче периодта ук хет-трик авторы булды. Беренчесеннән үк аның ул көнне көндәшләр капкасына өч алка кертәсен аңладым! «Әйдә, Артем, син бүген хет-трик ясарга тиешсең», – дигәнрәк рухта укына башладым. «Нәрсә пышылдыйсың син анда?» – диештеләр янда утыручылар. «Зиһенне чуалтмагыз әле!» – дип кенә җибәрәм», – дип сөйли Гөлфизия Госмановна.

Моны төрлечә аңларга мөмкин, әмма «Ак Барс» әбисенең әфсене, аның фанатларча тугрылыгы белән бергә, яраткан командабызны яңа титулга якынайта шикелле.

70 яшьлек әби оныклары яшендәге фанатларны дәрте-дәрманы белән сокландыра.

Җанатарлар гына түгел, «Ак Барс» уенчылары да бик рәхәтләнеп аның белән фотога төшә.

Команданы 2018 елда Гагарин Кубогына китергән «Ак Барс» хоккей клубының баш тренеры Зиннәтулла Билалетдинов белән.

«Ак Барс»ның рәсми һәм рәсми булмаган символлары – Ирбис һәм 8 Мартка фанатлар бүләге – «АВІКА» сүзе һәм 116 номер язылган хоккей свитеры кигән Гөлфизия Камалиева.

Фото: Александр Ефремов

РУЗИЯ МОТЫЙГУЛЛИНА: «ТЕАТРГА КИЛЕП ЯЛ ИТӘМ»

Руфия Фазылова

Редакциябезгә кунакка чакыргач, ул сорап куйды: «Анда сезнең машина куярга урын бармы?» Баксаң, Татарстанның халык, Россиянең атказанган артисткасы Рузия Мотыйгуллина һаман рульдә йөри. Бу турыда белгәч, гаҗәпләнүдән бигрәк сөендек: Рузия апабыз картаймый, дидек. Инде үзен күреп сөйләшкәч, моңа тәмам инандык.

– Рузия апа, сез «Аленький цветочек» әкиятендәге Настенькаңы искә төшерәсез: дөньяда булмаган әйбер сорарсыз кебек. Сездә аерым бер нәзакәтлелек, тирәнлек бар. Кечкенәдән шундый идегезме?

– Шундый идем. Әти-әниемнең, абый-апаларымның иркә кызлары, сеңелләре мин. Кечкенә чагымнан ук җил дә тидерми үстерделәр. Нәрсә әйтсәм дә, әти-әнинең әрләгәне булмады. Әти, гомумән, йомшак, бала җанлы кеше иде. Ә менә әни – кырысрак, аңардан шүрләбрәк үстек.

Гәүдә төзелеше, сөйләшүләрем белән әнигә охшаганмын. Ул да шулай тыныч кына, җай белән генә җавап бирә иде. Ә менә бертуган апам Исламия әти ягына охшаган. Безнең әти бөтен кешене авызына каратып торды. Гаиләдә алты бала без һәм барыбыз да төрле.

Кечкенәдән үзлегемнән биергә өйрәндем, бәлки биюче булып туганмындыр. Әни миңа матур сәхнә костюмнары тегеп бирә иде. Ә менә Исламия апам җыр юнәлешеннән китте, җырларга бик яратты. Әти дә җырчы иде безнең. Минем, киресенчә, тавышым булса да, җырга исем китмәде. Югыйсә Эдита Пьеха, Мөслим Могамаевларны тыңлап үстем.

– Сәхнә юлын сайлавыгызда бертуган апагыз Исламия Мәхмүтованың өлеше зурмы?

– Зур, дип уйлыйм. Авылга килгән бер генә спектакльне дә калдырмый идем. Апа күчмә театрда эшли башлагач, театрга йөрүләр тагын да ешайды.

Мәктәпне тәмамлагач, биюче булырга хыял бар иде. Әмма ничектер имтиханнар тапшырырга соңга калынды. Исламия апа белән сөйләшә торгач, театр училищесын сайларга булдым. Ә аңа кадәр әле «Зәңгәр шәл» спектаклен карадым. Анда кызларның җырлаганнарын, биегәннәрен күреп, театрга гашыйк булдым. Миңа театр сәнгатьнең югары ноктасы булып тоелды.

Дөрес, театр юлын сайлавымны җизнәм Хәлил абый башта бик өнәп бетермәде. «И, сеңлем, сиңа нәрсәгә кирәк инде бу?» – диде. Алар бит күчмә театрда эшләп, күпме газап белән гастрольләрдә йөргән артистлар. Ул чагындагы күчмә театр артистларына һәйкәл куярлык! Анда чын мәгънәсендә фанатлар гына эшләде. Заманында мин дә алар белән азрак йөреп алдым, күрдем, шуңа да бу сүзләрне юкка гына әйтмим.

Җиде ел Исламия апаларда яшәдем. Хәтта Камал театрына эшкә урнашкач та, алар мине үзләре яныннан җибәрмәде. Югыйсә яшәргә торак та бирделәр. Хәлил абый мине үз сеңлесе кебек кабул итте, аны икенче әтием дип йөртәм. Ә Исламия апа икенче әнием урынына булды: иркәләп, кадерләп тоттылар. Әле аннан киткәч тә, җизни апага: «Бу тәмле ризыкны калдырыйк әле, Рузия кереп чыкмасмы», – дия торган булган.

Апам белән җизнәмне әле дә бик юксынам, бик иртә киттеләр. Хәлил абыйга – 73 яшь, Исламия апага 76 яшь иде. Тормышны бик яратып, бер-берсен ихтирам итеп яшәделәр. Аларның шулай тиз арада юкка чыгулары минем өчен олы бер фаҗига булды.

– Марсель Хәкимовичның шәкерте сез. Атаклы режиссердан нәрсәләргә өйрәндем дип саныйсыз?

– Беләсезме, мин бик кызыксынучан кеше. Тарихта эзләнергә, яңа җирләр, илләр күрергә яратам. Марсель абыйдан дөньяны өйрәндем, сәнгатьнең төбенә төшеп эшләргә өйрәндем, дип әйтә алам. Бүгенгә кадәр Марсель Хәкимович өйрәткән, сөйләгән дәресләр буенча эшлим. «Без – Марсель абый мәктәбеннән», – дип сөйләшәбез. Ул чын оратор, аны тыңлап туеп булмый иде. Ни кызганыч, бүген андый кешеләр калмады дияргә була.

Татарда, башка милләтләр белән чагыштырганда, темперамент, үҗәтлек көчлерәк. Марсель абый менә шуны истә тота иде. Театр училищесын тәмамлап, без дүрт кыз: мин, Алсу Гайнуллина, Зөлфирә Зарипова, Фирая Әкбәрова Камал театрына эшкә килдек. Без сәхнәдә эмоцияләрне күрсәтеп уйнарга өйрәнгән артистлар. Бүген дә шулай, чөнки Марсель абый шулай өйрәтте, канга сеңгән ул.

Әле бит безгә Марсель абыйның этисе Хәким абый белән аралашу бәхете дә тәтеде. Ул безне китаплар укырга өйрәтте, бик күп язучылар белән таныштырды. Театрның холлында бөтен артистлар җыелып и гәпләшәләр иде... Без, яшь артистлар, язучыларның мәзәкләрен, гыйбрәтле хәлләрен тыңлап, сәгатьләр буе утыра идек. Шундый кызык чаклар булган икән дип, һаман сагынып искә алам.

– «Өч аршын җир»дә Шәмсегаян, «Зөләйха» трагедиясендә Зөләйха, «Ханума»да Ханума... Иң истә калган рольләрегез дип кайсын әйтә аласыз?

– Алар барысы да автор тарафыннан әйбәт язылган пьесалар. Артист өчен һәр роле кадерле, шулай да күңел халәтенә аеруча якын рольләр була. Мәсәлән, «Өч аршын җир»дә йөрәгендә авыл рухын йөрткән Шәмсегаянны бик яратып уйнадым. Роль алганнан соң, син героең очрашкан вакыйгаларны яңадан өйрәнәсең, мөмкин кадәр тормышчан итеп уйнарга тырышасың.

Зөләйханы да бик яратып уйнадым. Безнең халыкның зур фаҗигасен чагылдыра торган образ. Ул теманы тирәннән өйрәндем. 90 нчы еллар башында әле Гаяз Исхакыйны куярга рөхсәт итмиләр иде. Празат абый Исәнбәт бу зур эшкә алынды. Дөресен генә әйткәндә, кайберәүләр шүрләбрәк тә калган иде, чөнки чынлап та борчылырга урын бар. Әмма ул спектакль гомерле булып чыкты, без аның белән гастрольләргә дә йөрдек, телевидениедән дә күрсәттеләр.

– Рузия апа, Камал театры гел үсештә кебек: репертуар төрле, тамашачыга сайлап алу мөмкинлеге зур. Шуның нәтиҗәсе буларак, залларыгыз һәрвакыт тулы була. Алай гына да түгел, рус тамашачысы да Камал театрына яратып йөри. Ә бит бүген халык интернетта гына утыра, газета-журналлар укымый, телевизор карамый, тел бетә, дип зарланабыз. Театрның мондый уңышы нәрсәдә дип уйлыйсыз?

– Мин һәрвакыт авылдан талантлы кешеләр чыга, дип әйтергә яратам. Авыл баласы хислерәк, тирәнрәк була сыман. Авыл гомергә татарны саклаган. Ни аяныч, бүген авыллар бетеп бара. Ә менә шәһәр балалары арасында телнең кыйммәтен белүче, аңлаучылар сирәгрәк. Ерак барасы түгел: үзебезнең оныкларның да татарчалары ипилек-тозлык кына, югыйсә икесенең дә теле татарча ачылды. Балалар бакчасына киттеләр дә ярты-йорты сөйләшә башладылар. Ә бит өйдә алар белән гел татарча аралашырга тырышабыз, татарча китаплар укырга мәҗбүр итәбез. Ни аяныч, алардан туган телләрен камил белүче балалар үсәр, дип уйламыйм. Бу бит безнең гаиләнең генә фаҗигасе түгел. Тел балалар бакчасында, мәктәптә дә сакланырга тиеш, шунсыз туган телне саклап булмый.

Сүз башы бит Шүрәле, дигәндәй. Марсель абый: «Менә бу спектакль – касса, монысы – артистлар, ә монысы театрның дәрәҗәсе өчен», – дип әйтә торган иде. Хәзер дә театрда бу баланс саклана. Камал театры – татар халкының йөзек кашы. Ул элек тә шулай булган, бүген дә шулай. Халыкның театрга яратып йөрүенең төп сәбәбе шулдыр, дип уйлыйм.

– Театрның яңа бинага күченүе сезнең өчен сөенечме, әллә киресенчә, көенечме?

– Беләсезме, яңа фатир алсаң да, яңа дача салсаң да, әлбәттә, ул – сөенеч. Ә ташлап киткән йорт, моңсу бер истәлек булып, барыбер синең күңелеңдә кала. Театрның мин хәтерләгән тарихында гына да бу өченче күченү инде. Хәзерге Тинчурин театры бинасыннан Татарстан урамына күченгәндә дә бик кызганыч булган иде. Мин анда унөч ел эшләдем. Ул бинада бит кайчандыр опера һәм балет театры да эшләгән. Бер көн – театр, бер көн балет куйганнар. Максим Горький урамындагы ул бинада Салих Сәйдәшев, Кәрим Тинчуриннар иҗат иткән. Аларның авазлары шул диварларга сеңгән. Аның бик борынгы баскычлары гына да ни тора! Татарстан урамына күченгәндә менә шулай дип моңсуландык. Инде хәзер янә үзәк өзелә. Бүгенге бинада мин «Зөләйха», «Өч аршын җир», «Ханума»ларны уйнадым. Әле зур рольләрем тагын күп. Ә нинди көчле артистлар белән эшләдем! Аларның инде күбесе ахирәткә күчте: Нәҗибә Ихса-

нова, Фирдәвес Әхтәмова, Наилә Гәрәева... Гүя һәркайсының шунда эзе калган.

Берсендә Шәүкәт абый Биктимеров «Ханума» спектакленең репетициясенә килгән. Роле зур түгел.

– И, яратам шушы «Ханума»ны, – ди.

– Ни өчен яратасыз? – дим Шәүкәт абыйга.

– Беренчедән, килəм дә ял итәм. Икенчедән, монда минем Ирек, тагын яраткан артистларым бар. Шулар белән театр холлында сөйләшеп утырып, бер айлык рухи азык алып кайтып китәм...

Иң кызыгы, Шәүкәт абый сөйләгән тойгы хәзер миндә дә бар. Рольләрем күп булмаса да, театрга килеп ял итеп китәм.

– Гаиләгез турында да сөйләшәсе килә, Рузия апа. Җәмәгатегез Ринат Закиров бөтен татар дөньясына билгеле шәхес. Аның белән ничек таныштыгыз, кавыштыгыз?

– Без танышканда Ринат комсомолда эшли иде. Актриса, дустым Фирдәвес Хәйруллина комсомол секретаре иде. Без аның белән комсомол идарәсенә бардык. Шунда Ринатны күреп алдым. Тик мин шактый горур кыз идем. (Гәрчә ул сыйфатны бик яхшы дип санамасам да, шуның аркасында үз гомеремдә роль сорап йөргәнем булмады.) Ринат беренче булып миңа үзе сүз катты. Коры гына берничә сүз алыштык. Шуннан ул мин уйнаган спектакльне карарга килде. Менә шунда аңа ныклап игътибар иттем: чибәр генә егет, аракы эчми, тәмәке тартмый. Ә болар минем өчен бик мөһим. Тагын әле мактанмый, саран түгел. Монысына инде аралаша башлагач инандым. Кыскасы, Ринат күңелемне игътибары, миңа карата булган хөрмәте белән яулады.

– Кызыгыз Чулпанны тәрбияләргә вакыт, игътибар җитте, дип санийсызмы? Бию сәнгатен сайлавында сезнең йогынты булдымы?

– Беренчедән шуны әйтим: күңелдә үкенеч яши - бер бала белән генә калдык. Дөрес, бу минем гаеп түгел, сәламәтлек белән шулай килеп чыкты. Яшь артистларга һәрвакыт: «Бер бала белән генә калмагыз», – дип әйтәм. Бала ул бөтен нәрсәгә караганда да зуррак, бәһасез хәзинә. Бу бәхетне бернәрсә белән дә алыштырып булмый. Әлбәттә, балалар тәүфыйклы, сау-сәламәт булсыннар.

Чулпанны тәрбияләргә вакыт җиттеме, дигәндә, ул яшьлек белән бик беленми икән бит. Ул безнең бик яхшы укыды. Мөстәкыйль булды, дәресләрен үзе карады.

Бию сәнгатен дә үзе сайлады. Гәрчә Марсель абый Сәлимҗанов театр юлыннан китсен, дип тә әйтеп карады. Чулпан Камал театрында дүрт-биш спектакльдә катнашты. Мәктәпне тәмамлаганда шактый ихлас сөйләшү булды: «Кызым, артист үзенең язмышын алдан белми: гомер буе массада да уйнап йөри аласың. Артистның кайвакыт икешәр ел эше булмый. Олыгая-олыгая бөтенләй азая. Син басынкы кыз түгел, сиңа гел хәрәкәттә булырга кирәк. Яхшылап уйла», – дидем. Әтисе белән киңәшләшкәннән соң, Чулпан КДУның юридик факультетына укырга керде. Ләкин диплом алып, азрак эшләп караганнан соң: «Әни, бу минем юл түгел», – диде. Шуннан ул Мәскәүгә, ГИТИСка керде. Анда исә канатланып йөри башлады. «Мин – сәнгать кешесе, биюне күбрәк яратам икән», – диде. Нәкъ шул елларда «Казан» бию ансамбле оешты. Ике җитәкче алмашынганнан соң, Чулпанны ансамбльнең җитәкчесе итеп куйдылар. Яшермим, кызыбыз белән бик горурланам.

– Рузия апа, һич кенә дә үз яшегезне биреп булмый. Әле һаман машина йөртәсез... Моның сере, сәбәбе нәрсәдә дип уйлыйсыз?

– Үземә карата шактый игътибарлы мин: ашауны контрольдә тотам, атнага бер-ике тапкыр бассейнда йөзәм. Машина йөртүгә килгәндә, утыз елдан артык рульдә инде. Җәяү йөрүгә караганда, машинада үземне рәхәтрәк сизәм.

– Сезгә шушы көннәрдә 75 яшь тулды. 70 яшьлегегезне үзегезгә генә хас булган затлылык белән, бик зурлап үткәрдегез. Быел андый кичә уздырырга ниятлисезме? Әзерлек эшләре барамы?

– Дөресен генә әйткәндә, туган көннәр уздырырга бик яратмыйм да. Быел Камал театрында юбилейлар шактый, бәлки, бергә җыелып, сәхнәдә уздырырбыз, дигән сүз булган иде. Әле бит театрда күчену мәшәкатьләре бара, насыйп булса, соңрак оештырырбыз.

– Уңышлар һәм саулык телибез сезгә, Рузия апа!

ВАСЫЯТЬНАМӘ.

АКЧА ҺӘМ ЯКЫННАРЫБЫЗНЫ ЯРАТУ ТУРЫНДА ГЫНАМЫ?

Алтмыш проценттан артык граждан васыятьнамә яза – статистика шул хакта сөйли. Әмма әлеге гамәлнең нәтиҗәсе варислар өчен һәрвакытта да күңелле булмаска мөмкин: кайчак якын кешеләренең үлеме туганнары өчен низагка һәм суд юлын таптауга әйләнә. Киләчәктә мондый хәлләргә урын калдырмас өчен, мирас бүлү турында ничек алдан ук кайгыртырга, нинди адымнар ясарга – бу турыда безгә гаилә һәм мирасны планлаштыру буенча киңәшче, гражданлык-хокукый бәхәсләр белән эшләүдә 16 еллык тәҗрибәгә ия танылган адвокат Юлия Кәбирова сөйләде.

НИКАХ КИЛЕШҮЕ ҺӘМ ВАСЫЯТЬНАМӘ

Гаилә һәм мирасны планлаштыру дигәндә, без үлем-китем очрагында варислар арасында милек бүлүне оештыру өчен ышаныч белдерүчеләр белән алып барыла торган чаралар комплексын күз уңында тотабыз.

Без барыбыз да кемнеңдер балалары, ата-анасы, никахта яисә гаиләсез булырга мөмкинбез, безнең якын туганнарыбыз бар. Гаилә-мирас планлаштыруын оештырганда, без беренче карашка күзгә бәрелеп тормаган, әмма соңрак, мирас булып калган мөлкәтне бүлгәндә, җитди каршылык тудырырга мөмкин булган күп кенә аспектларны истә тотабыз.

Әйдәгез, өйләнешкән ир белән хатын мисалын карыйк. Никахта сатып алынган милек баштан ук уртак санала һәм икесенә дә тигез өлештә бүленә.

Әгәр ир белән хатын мирасны планлаштыру турында уйлыйлар икән, иң элек никах килешүе (брачный договор) төзергә кирәк. Ул мөлкәтнең кайсы өлеше шәхси саналып, берсенеке генә булуын, ә кайсы өлеше уртак икәнлеген төгәл билгели. Сүз уңаеннан, аны өйләнешкәнче дә, аерылышканчыга кадәр, уртак тормышның теләсә кайсы чорында да имзаларга була.

Мин никах килешүен шактый зур активларга, күчемле һәм күчемсез милеккә ия парларга гына түгел, бизнес алып баручыларга да төзергә киңәш итәм. Килешүдә фактта бизнесны алып барган ир яисә хатынның андагы өлешенә шәхси хокукын теркәргә мөмкин: бу никахтагы вакытка да (мирас өчен мөһим), аерылышкан очракка да кагыла.

Әгәр бизнес партнерлык шартларында оештырылып (мәсәлән, берничә катнашучы ҖЧҖ төзегән), партнерның берсе аерылыша икән, аның никах килешүе булмаганда, әлеге кешенең элеккеге җәмәгате бу оешмада үзенә өлеш сорарга хокуклы. Ә бу инде компаниянең тотрыклы эшләвенә комачаулый – әгәр элекеге ир белән хатын уртак тел таба алмый икән, бу озакка сузылган корпоратив бәхәсләргә китерә.

Шуңа күрә никах килешүендә без мөлкәт бүлүне бизнеска зыян килмәслек итеп билгеләп куя алабыз: бу аерылышуларга гына түгел, үлем-китем очрагына да кагыла. Ягъни кеше үлә, ләкин аның никах килешүе бар икән, мирас составына кергән мөлкәт нәкъ менә әлеге килешүдә каралганча бүленә.

МИРАСНЫ ПЛАНЛАШТЫРУ НИ ӨЧЕН МӨҺИМ

Килешү дә, васыятьнамә дә булмаганда хәл катлаулырак. Ул чакта законда каралган варислар чакырыла. Беренче чираттагы варисларга үлгән кешенең җәмәгате, балалары һәм ата-анасы керә. Барысы да бик гади шикелле. Ләкин, мәсәлән, шундый хәлләр очрый: исән калган ир/хатын гына түгел, аларның беренче никахтагы парлары да булырга мөмкин. Монда инде алар да мираска өмет итә ала, ягъни үлгән кешедән калган мираста үз өлешен алырга хокуклы.

Күп кеше, ир белән хатын аерылышканнан соң өч ел эчендә генә уртак милеккә дәгъва кыла ала, дип уйлый. Бу ялгыш фикер. Аерылышалар, никах килешүе дә төзелмәгән, нотариуста уртак мөлкәтне бүлү турында нотариаль килешү дә юк, әмма уртак милек статусы аерылганнан соң да саклана.

Барысы да исән булганда яхшы. Ничектер җайларга мөмкинлек бар. Әгәр кеше үлеп китә, үзеннән соң йорт яисә бизнес калдыра икән, бу очракта аның элеккеге җәмәгате үз өлешен дәгъваларга хокуклы.

Беренче һәм икенче никахтан туган балалар булып, алар бер-берсе белән

Фото Юлия Кәбирова архивыннан алынды. РЕКЛАМА

аралашмаганда хәл тагын да катлаулырак. Яисә, мәсәлән, мирас калдыручының җәмәгате белән начар мөнәсәбәттә булган ата-аналар исән.

Бу вакытта милек төп-төгәл өлешләргә бүленә. Мисалга, биш варис һәм бер фатир бар. Мирас буларак алган бу фатир бишкә тигез өлешләп бүленә.

Мондый хәлләр варислар арасында аңлашылмаучанлыкка китерә, эш судлашуга кадәр барып җитә. Ә әлеге хәлгә ничектер йогынты ясарлык, бөтен туганнарны тынычландырырлык теге кеше үзе юк.

Бу туганнар мирас калдыручы исән булганда ук бер-берсе белән дус булмаганга шулай килеп чыга.

Гаилә-мирас планлаштыруына керешкәндә, без иң беренче мираска нәрсәләр керәсен ачыклыйбыз. Никах килешүе төзибез. Аннан соң без васыятьнамә язабыз, бу, мәсәлән, ир белән хатынның уртак васыятьнамәсе булырга мөмкин. Анда алар уртак балаларына яисә алдагы никахларында туган балаларга мирасны ни рәвешле бүлеп калдырачакларын билгелиләр. Ә кемдер гомумән тагын да заманчарак конструкцияне сайлый: бу вакытта сөйләшүләрдә варислар белән мирас калдыручы бергә утырып, күзгә-күз карап, мөлкәтнең ничек бүленәсен ачыклыйлар һәм имзаларын куялар.

Ләкин бу бик сирәк була, чөнки гадәттә мирас калдыручы барысын да үзе теләгәнчә, үзенчә бүлә.

Без бу документларны төзегәндә һәрвакыт шуны да күздә тотабыз: васыятьнамә кайчан да булса судта дәгъва белдерелмәслек яисә дөрес карар кабул ителерлек булырга тиеш.

ВИДЕОЯЗМА ҺӘМ ДӘЛИЛ

Бүген васыятьнамә төзегәндә, без заманча технологияләр дә кулланабыз, мәсәлән, видеоберкетмә ясау. Коллегамның эшендә шундый бер очрак булды: мирас калдыручы үзенең варисларына мөлкәтне ни өчен нәкъ менә шулай бүлүен аңлатып видеоязма ясата.

Һәм менә эш мирас бүлүгә килеп җиткәч, кызларының берсе, этисенең васыятьнамәсе белән килешмичә, судка мөрәҗәгать итәчәген белдерә. Нотариус аңа язманы куша һәм әлеге видео белән аның үзен генә калдыра. Нәтиҗәдә кызы: «Юк, мин этиемнең ихтыярына каршы бармыйм», – дигән фикергә килә.

Видеоязма шулай ук мирас калдыручының васятьнамәне төзегәндә сау-сәламәт, аек акылда, үз гамәлләренә җавап бирә алырлык хәлдә булуының дәлиле дә санала.

Әгәр васыять язылганда видеоязма алып барылмаса, риза булмаган варислар нәкъ менә мирас калдыручы кешенең үз акылында булуын суд аша кире кагарга тырышалар.

ӨЙЛӘНЕШМӘГӘН ПАРЛАР ӨЧЕН ВАСЫЯТЬНАМӘ

Без шундый тенденцияне күзәтәбез: теркәлмәгән никахта 15–25 еллап яшәгән, үзләрен гаилә дип санаган, балалар табып үстергән парлар саны арта бара, алар үзләрен бик бәхетле саный. Ләкин никахлары рәсми теркәлмәгән ир белән хатынның берәрсенең үлеме очрагында, әгәр васыятьнамә төзелмәгән икән, исән калганы варис булып санала алмый.Хәтта фактта өйләнешкән парлар арасында да низаглы мизгелләр шактый. Күптән түгел генә миңа бер ханым мөрәҗәгать итте. Ул 18 ел ир белән яшәгән, ләкин рәсми рәвештә өйләнешмәгән булганнар. Аларның ике уртак уллары туган. Ханым исеменә – бер бүлмәле, ә ире исеменә өч бүлмәле фатир язылган. Соңгысын алар ипотекага алганнар һәм бурычны бергә түләгәннәр. Тора-бара үзара мөнәсәбәтләр начараеп киткән. Хатын, балаларын алып, ире яхшы якка үзгәрер, барысы да элеккечә булыр дигән өмет белән бер бүлмәле фатирга күченә. Чыннан да, ир бераздан алар янына килә, үзендә депрессия башлануына, эшендә дә хәлләрнең катлаулануына һәм гомумән барысы да бик начар булуына зарлана.

Хатын аңа бер багучының телефон номерын бирә, янәсе, барып кара, бәлки, ул ярдәм итәр.

Вакыт уза. Һәм бервакыт ханым иренең теге багучы хатын белән аларның өч бүлмәле фатирында яшәвен, бераздан гомумән торакны сатарга куюын ишетә. Хатынның бу фатир өчен түләвен раслый алмыйбыз – акча күчерү турында бернинди дә документ юк, чөнки барысы да акчалата бирелгән. Мондый хәлләрдә без юридик яктан ярдәм итә алмыйбыз.

Шуңа күрә рәсми булмаган никахта эшләп тапкан уртак малны өлешкә бүлеп милек итеп теркәү бик мөһим.

ВАСЫЯТЬНАМӘ БУЛГАНДА ТЫНЫЧРАК

Мирас калдыручы үз гомере дәвамында васыятен берничә мәртәбә үзгәртергә хокуклы. Һәм һәр яңасы автомат рәвештә аннан алдагысын алыштыра. Мирас калдыручы һәм нотариустан кала, беркем дә бу турыда белми – «мирас сере» сакланырга тиеш.

Шул ук вакытта, әгәр парлар баштан ук уртак васыятьнамә төзи икән, аны үзгәртү башкачарак була.

Әгәр нинди дә бер сәбәп аркасында, ир яисә хатын нотариуска килеп: «Мин кире уйладым, башкача ясыйсым килә», – дип әйтә икән, нотариус бу турыда аның җәмәгатенә дә хәбәр итәргә тиеш. Шуңа күрә ир белән хатынның уртак васыяте күбрәк гарантиягә ия.

Васыятьнамә – бик җитди документ, анда төрле чорлар исәпкә алына, бу гел, тиешсез вакытта да үзгәртүләр кертелеп тормасын өчен уңайлы. Аерым алганда, әгәр васыятьнамә язылганнан соң, мирас калдыручы тарафыннан яңа активлар, күчмә һәм күчемсез милек сатып алына икән, варисларның берсе – җыелган акчаларны һәм инвестицияләрне, икенчесе күчемсез милекне алачагын шунда ук күрсәтергә була.

Миңа мирас өчен көрәштә чын дошманга әйләнгән бик күп кешеләрне күрергә туры килә. Әлбәттә, адвокат буларак минем бурыч якларның позициясен законга туры китереп җайлау, максималь рәвештә объектив бәяләп, җәмәгать килешүенә китереп җиткерү.

Ләкин, кызганычка, судларда без төрле варислар белән очрашабыз. Кемгәдер якынының үлеме чыннан да зур кайгы, ә икенчесе инде бу вакытта мираска калган фатирга нинди обой ябыштыру турында уйлый. Әлеге ямьсез низагларны, тартышларны булдырмас, гомумән андый хәлләргә урын калдырмас өчен, васыятьнамә төзергә, мирасны бүлү турында алдан уйларга, моңа җитди карарга киңәш итәм.

Тиешле документларны алдан ук әзерләп кую милеккә дәгъва кылучыларның мөнәсәбәтләрендә ачыклыкны тәэмин итә. Бу исә гаиләдә тынычлыкны сакларга, якын кешеләрегез күңелендә тирән яралар калдырмаска булыша.

«НЕОЛИТ ДИЗАЙН» ТОРМЫШНЫ БИЗИ

Уңайлы яшел территорияләр булдыру бүген гади эстетика гына да түгел инде. Асылда, бу безнең шәһәрләрдә экологияне саклауга һәм тормыш сыйфатын яхшыртуга юнәлтелгән мәҗбүри адым булып тора. «Яшел сәнгать» принциплары һәм серләре турында ТР ландшафт дизайны базарындагы төп компанияләрнең берсе – «Неолит Дизайн» ландшафт дизайны студиясе директоры Ләйсән Шлайфер сөйли.

ЛАНДШАФТ ДИЗАЙНЫ – ФӘН ҺӘМ СӘНГАТЬ

Ландшафт дизайны – бер үк вакытта сәнгать тә, ә инде парк, бакча, ишегалды кебек ачык территорияләрне яки башка табигый ландшафтларны проектлаштырырга һәм оештырырга туры килгәндә исә фән дә. Шул ук вакытта болар барысы да бик нәфис, күзне сөендерерлек булырга тиеш.

Ландшафт дизайны безнең тормышка һаман активрак үтеп керә бара, әмма ул күпләр өчен барыбер «ябык китап» булып кала бирә. Интерьер дизайны клиентларга күпкә аңлаешлырак. Кагыйдә буларак, үз йортын яки фатирын бизәгәндә һәр икенче гаилә дизайнерларга мөрәҗәгать итә. Еш кына алар үз интерьерларының планировкасын алдан ук күзаллый. Ә менә ландшафт дизайны белән эш башкачарак. Ул катлаулырак процесс буларак кабул ителә, чөнки клиентлар үсемлекләрне ничек дөрес сайлау һәм бер-берсенә яраклаштыру, чатыр яки теплицаны кайда урнаштыру, сукмакларны ничек салу хакында бөтенләй белмәскә мөмкин.

Моны бик гади эшкә санаучылар да күп, янәсе, чәчәк утыртасың да, бакча яшеллеккә күмелә. Чынлыкта исә матур һәм «озын гомерле» бакча булдыру өчен селекция үсемлекләре һәм аларның ярашуы, климат шартлары һәм аларны дөрес кайгырту кебек бик күп факторларны исәпкә алу мөһим.

Бакча үстергәндә, ландшафт дизайны буенча белем һәм әле тагын тәҗрибәгә ия булу шарт. Ә бу һәркемнең дә хәленнән килми. Шунлыктан без, профессионаллар, үсемлекләрне дөрес сайлау һәм утыртуда, яшеллек мәйданын дөрес бизәүдә булышып кына калмыйбыз, бәлки әле клиентларыбызның ихтыяҗларын канәгатьләндерерлек чишелеш юллары да тәкъдим итәбез.

БЕЗНЕҢ ПРОЕКТЛАР

17 еллык эшчәнлек дәверендә без 300 дән артык хосусый һәм шәһәркүләм проектны гамәлгә ашырдык, тотрыклы абруй яулый алдык. Оешмалар безгә хәзер колачлы проектларны тормышка ашыруыбызны үтенеп мөрәҗәгать итә, бу безнең эшне тагын да кызыклырак һәм иҗадиракка әйләндерә.

Иң күркәм хезмәтләребезнең берсе, мәсәлән, Әлмәттәге кампус. Проектны, Европа мәктәпләрендә алган белем һәм тәҗрибәләренә таянып, Мәскәү дизайнерлары эшләде. Бу очракта экономияләү бурычы юк иде – без ис-

Фото «Неолит дизайн» студиясеннән алынды, Александр Ефремов. РЕКЛАМА

киткеч матур һәм эстетикалы проектны бик теләп тормышка ашырдык.

Мөһим социаль-сәяси вакыйгага – БРИКС саммитына әзерлек кысаларында «Пирамида» территориясен яшелләндерү дә кызыклы булды. Тагын бер проект – Универсиада авылы. Компания әлеге урынны яшелләндерү белән ике тапкыр шөгыльләнде – бу безгә финанс ягыннан да, эшнең сыйфаты ягыннан да ышаныч белдерүгә дәлил булып тора.

«Неолит Дизайн» шулай ук оешмалар өчен ишегалларын һәм җәмәгать биналарын яшелләндерүгә бәйле проектлар да ясый, бу безгә төрле өлкәләрдә тәҗрибә туплау мөмкинлеген бирә.

ҺӘРКЕМ ИХТЫЯҖЫН КҮЗДӘ ТОТЫП...

Проектка керешкәндә, без күп параметрларны исәптә тотабыз, чөнки ландшафт дизайны күп өлкәләрне белүне таләп итә: ботаниканы, экологияне, архитектураны, сәнгатьне. Мәсәлән, без балалар бакчаларында берничә проектны тормышка ашырдык, анда үсемлекләрнең балаларга зыян китерми торганын сайладык, үсеш һәм уку өчен мәйданнар булдыруны, эстетика ягыннан зоналарга бүленешне исәпкә алдык. Аерып әйткәндә, балаларда аллергия килеп чыкмасын һәм умарта кортлары чагу ихтималы булмасын өчен, җимеш агачлары утыртмадык. Балалар бакчаларындагы проектларның мөһим өлеше – табигатьне күзәтү мөмкинлеге бирерлек һәм сабыйларның үсешенә булышырлык тактиль такталар һәм башка элементлар кертү. Кызыклы һәм файдалы мәйданчык булдырганда, зоналарга бүлү өчен киртә-коймалар урынына куаклар утыртабыз. Бу мәйданны бүлү генә түгел, аны балалар өчен уңайлырак һәм кызыклырак итү мөмкинлеген дә бирә. Утыртып калдырганнан соң, алга таба карап тотуга чыгымнарны киметү, балалар бакчасы җитәкчелеге һәм тәрбиячеләрнең эшен җиңеләйтү максатыннан, җентекләп кайгыртуны һәм еш кисүне таләп итми торган үсемлекләрне сайлау да мөһим.

ЭЧКЕ ЯКНЫ ЯШЕЛЛӘНДЕРҮ

Эчке якны яшелләндерү – безнең өчен яңа һәм кызыклы юнәлеш. Биналар эчен яшелләндерү һаваның сыйфатын яхшырта, рәхәт мохит тудыра һәм кешеләрнең психоэмоциональ халәтенә уңай тәэсир итә. Бу бигрәк тә офис һәм рестораннар кебек коммерция биналарында мөһим. Әлеге җәһәттән үсемлекләрнең ябык бинада үсү үзенчәлекләрен белү зарур, бу яшелләндерү технологияләрен тагын да катлауландыра. Казанда эчке якны яшелләндерү илнең башка төбәкләре белән чагыштырганда әллә ни киң таралмаган әле, шунлыктан безгә зур мөмкинлекләр ачыла. Без инде берничә клиника һәм ресторан эчен яшелләндердек. Кайбер очракта яшелләндерү технологияләрен үзебез проектлаштырдык, кайсыларында әзер проектлар белән эшләдек. Һәрхәлдә, без яшелләндерүнең дизайнерга креативлык күрсәтү, мәйданны уникаль һәм «сулый торган» итү мөмкинлеге бирүен сиздек.

МӘНФӘГАТЬЛӘР БЕРДӘМЛЕГЕ

Тупланган тәҗрибәбез зур булганга, безнең компаниядә заказчылар белән низаглар килеп чыкмый. Клиентлар дизайнерларыбызның һөнәрмәндлеген күрә, безнең белем һәм күнекмәләргә ышана. Без клиентлар белән һәрвакытта да уртак тел таба алабыз. Моның өчен эш башланган чакта ук бөтен кирәкле мәгълүматны ачыклыйбыз. Аннары клиентларга берничә вариант тәкъдим итәбез, ул үзенә ошаганын сайлап ала. Әгәр дизайнер белән клиент нәрсәдәдер үзара килешми икән, компания үз идеяләрен аңлатырга тырыша һәм альтернатива тәкъдим итә. Кайвакыт хосусый клиентлар үз бакчасына ниндидер экзотик үсемлекләр утыртмакчы була. Безнең бурыч – аларга экзотик үсемлекләрнең кышкы шартларга түзә алмавын аңлатып бирү һәм безнең климат шартларына җайлашкан, кайгыртуы җиңел булган үсемлекләр утыртырга күндерү.

НИ ӨЧЕН БЕЗНЕ САЙЛЫЙЛАР?

Без һәрвакытта да клиентлар белән элемтәдә торабыз һәм аларның ландшафт дизайны базарындагы күп компания арасында ни өчен безне сайлауларын яхшы беләбез.

Барлык икътисади кыенлыкларга карамастан, без инде 17 ел буе тотрыклы эшлибез. Бу вакыт эчендә без хосусый клиентлар өчен дә, шәһәр объектлары өчен дә төрле проектлар әзерләүдә зур тәҗрибә тупладык.

«Неолит Дизайн» ландшафт дизайны буенча хезмәтләрнең тулы циклын тәкъдим итә – проектлаудан алып гамәлгә кертүгә һәм үсемлекләрне карап тотуга кадәр. Ягъни без клиентлар белән аларның теләкләрен тыңлаудан башлап барысы да әзер булганчы барлык этапларда да бергә эшлибез. Тагын бер мөһим момент – без үз эшебезгә 2 ел гарантия бирәбез. Бу ландшафтның барлык элементлары һәм үсемлекләрнең кимендә шул вакыт эчендә бик яхшы сакланачагын аңлата. Клиентлар белә: аларның инвестицияләре бушка китмәячәк, эш нәтиҗәсе исә сыйфат стандартларына тәңгәл киләчәк.

Компания проектны тиз арада эшләү соралган очракта да заказчылар теләгенә каршы килми, бу тиз нәтиҗәләр күрергә теләгән клиентлар өчен аеруча мөһим.

Безнең хезмәтләр өчен түләү уртача базар бәяләре чамасында, шунлыктан клиентларны куркытмый. Компания дизайнерлары исә һөнәрмәндлек һәм креативлыкның югары дәрәҗәсенә ия, һәм бу аларга тиңдәшсез, мавыктыргыч проектлар төзү мөмкинлеген бирә.

Адрес: Җиңү проспекты, 18а, 1 нче офис.
Сайт: neolitkazan.ru
Телефон: +7 (987) 297-06-16

НАТАЛИЯ ОВЕЧКИНА: НӘТИҖӘЛЕ ИДАРӘ ИТҮГӘ КИТЕРГӘН ЮЛ

Зур оешманың эшен тамырдан үзгәртү өчен өч ел әллә ни күп вакыт түгел. Әмма Наталия Овечкина мисалы шундый кыска вакыт эчендә дә уңышка ирешеп булуны раслый ала. 2022 елда «Татнефть-Забота» структур бүлекчәсенә җитәкче итеп куелгач, ул аның үсешенә яңа юнәлеш бирә, финанс тотрыклылыгын тәэмин итә, күрсәтелә торган хезмәтләрнең сыйфатын яхшырта һәм инновацияләргә юл ача.

Наталия беренче эш көненнән үк үз алдына куелган амбицияле бурычны дөрес аңлый: ул «Татнефть-Забота» бүлекчәсен бик югары сыйфатлы оешмага әйләндерергә тиеш була. Бу социаль объектлар челтәрен киңәйтүне генә аңлатмый, бәлки алар эшенең нәтиҗәлелеген арттыру, ресурслардан файдалануны оптимальләштерү һәм заманча идарә ысулларын кертүне дә күздә тота.

Команда каршында катлаулы бурычлар тора. Әмма хәзер инде тырышып эшләүнең нәтиҗәләрен күреп була. «Татнефть-Забота» бүлекчәсендәге объектлар саны шактый арткан. Бүген аның составында «Татнефть» ГАҖ социаль активының 120 объекты исәпләнә: шифаханәләр, балаларны савыктыру лагерьлары, шәһәр читендәге ял базалары, спорт һәм мәдәният учреждениеләре, кунакханәләр, сервис хезмәтләре һ.б.

Бүлекчәнең сыйфатлы үсешендә Наталия Овечкинаның стратегияле эше һәм инвестицияләр җәлеп итү сәләте аеруча мөһим роль уйный. Төп факторлардан берсе – инвестицион проектлар саны арту. Бу акчадан файдалануның нәтиҗәлелеген арттыру мөмкинлеген бирә. Һәм 2024 елда инвестицияләрнең гомуми күләме 2022 елга караганда дүрт тапкырга арта.

Тормышка ашырылган проектлар сизелерлек нәтиҗә бирә, бүлекчәдәге акча берничә йөз миллион сумга арта. Бу Наталия Овечкина җитәкчелегендәге команданың һөнәрмәндлеге күрсәткече булып тора һәм нәтиҗәле идарәнең хәтта социаль секторда да тотрыклы финанс моделен булдыра алуын дәлилли.

Бүлекчә үсешендә инновацион якын килү мөһим роль уйный. Бүген хезмәткәрләр сыйфатны яхшырту процессларында актив катнаша, нәтиҗәлелекне арттыру буенча үз инициативаларын тәкъдим итә. Элегрәк мондый идеяләр бик сирәк туа торган булса, хәзер исә өзлексез үсеш культурасы «Татнефть-Забота» бүлекчәсе эшенең файдалы бер өлешенә әверелә.

Яхшы уйланылган стратегия бүлекчәдәге барлык объектларның финанс тотрыклылыгын тәэмин итүгә юнәлтелгән. Көндәшлеккә сәләтне арттыру, маркетинг инициативаларын кертү, өстәмә хезмәтләр спектрын киңәйтү, шулай ук активлар белән рациональ идарә итү өстенлекле юнәлешләрдән санала. Күрсәтелә торган хезмәтләрнең сыйфатына һәм клиентларны канәгатьләндерүгә аеруча игътибар бирелә.

Соңгы еллардагы мөһим инициативалардан кайберләре – «Ромашкино» шифаханә-профилакториенда минераль су тутыру цехын модернизацияләү, «Новая Земля» иммерсив парк-отелен булдыру, «Ивушка» глэмпингы һ.б. проектлар уңайлы мохит тудыруга гына түгел, Татарстанның көньяк-көнчыгышындагы территорияләрне үстерүгә дә булышырга тиеш.

Дәүләт ярдәме мөмкинлекләреннән оста файдалану турында да аерып әйтергә кирәк. Финанслауны дөрес планлаштырып, Наталия Овечкина бүлекчәне үстерүгә субсидия һәм грантларны актив җәлеп итә. Мәсәлән, 2023 елда «Новая Земля» парк-отеле проектына 70 миллион сумлык дәүләт субсидиясе алына, бу чыгымнарны шактый киметү һәм рентабельлекне арттыру мөмкинлеген бирә.

2024 елда Наталия Овечкина абруйлы «Ел җитәкчесе-2024» республика конкурсында «Югары социаль җаваплылык өчен» номинациясендә җиңү яулый.

Әлеге конкурста җиңү «Татнефть-Забота» бүлекчәсенең дөрес юлдан баруын дәлилли һәм кешеләр турында корпоратив кайгыртуның мөһимлеген аермачык күрсәтә. Хезмәткәрләрнең тормышын сыйфатлырак, ә компанияне куәтлерәк итү буенча эш киләчәктә тагын да яхшыртылачак һәм тулаем төбәк үсешенә дә булышачак.

Фото: Наталия Овечкина архивыннан. РЕКЛАМА

ЯҢА ОФЫКЛАРГА ЮЛ ЯРЫП...

Җитәкче вазыйфасындагы хатын-кызга ир-атларга караганда күбрәк тырышырга туры килә – уңышка ирешү өчен, аңа үз эшенең чын остасы булудан тыш, бик зур үҗәтлек белән фидакарьлек күрсәтергә дә кирәк. «Татарстан Республикасы техник инвентарьлаштыру һәм кадастр эшләре бюросы» АҖ генераль директоры Лена Хәмзинага әнә шул сыйфатларның барысы да мулдан бирелгән.

Рәүзил Хаҗиев,
«Татэнерго» АҖ генераль директоры

Әгәр 1986 елда Казан финанс-икътисад институтын «Сәнәгатьне планлаштыру» белгечлеге буенча яңа гына тәмамлаган икътисадчы кызга аның кайчан да булса ТР премьер-министрының эшкуарлык буенча ярдәмчесенә әйләнәсен, аннары исә республиканың Техник инвентарьлаштыру бюросын (ТИБ) җитәкләячәген фаразласалар, ул моны шаярту дип кабул итәр иде.

Хәер, карьерасының шуннан соңгы этаплары яхшы икътисадчының теләсә кайсы тармакта да уңышка ирешә алуын дәлилләде: Лена Хәмзина төрле елларда «Татснабсбыт» идарәсендә хезмәт буенча инженер, Казан финанс-икътисад институтында кече фәнни хезмәткәр, «Казан ШТС» ААҖндә икътисадчы, ТР Элемтә министрлыгында икътисад һәм финанс бүлеге мөдире, Казан почтамты җитәкчесе, ТР элемтә министры урынбасары булып эшли. Ә инде Рөстәм Миңнеханов республика Техник инвентарьлаштыру бюросын җитәкләргә тәкъдим иткәч, куркып калмый, ризалаша. Әлеге инвентарьлаштыру документларында ул баштарак күп нәрсәне аңламый, әмма максатчанлыгы, хезмәт сөючәнлеге аңа тиз арада эшнең асылына төшенергә ярдәм итә. Билгеле, бу җиңел булмый.

Өстәвенә, Лена Хәмзина ул чакта әле «Техник инвентарьлаштыру бюросы» РДУП дип аталган оешманы катлаулы чорда җитәкләүгә керешә: дәүләт ТИБ монополиядән мәхрүм ителеп, күпләгән кадастр инженерлары үз хезмәтләрен тәкъдим итә башлый. Әмма оешма базарның шактый өлешен үзенә калдыра ала: моның өчен эре клиентларга игътибарын арттыра, структураны камилләштерү һәм белгечләрнең квалификациясен даими күтәрү хисабына югары сыйфатны саклауга ирешә.

Базарны яхшы белү, җитәкченең эшлеклелеге һәм коллективны максатка ирешүгә рухландыруы нәтиҗәсендә «ТР ТИБ» АҖ яңа юнәлешләрне актив үстерә, яңа технологияләр кертә, бу аны кырыклап структур бүлекчә урнашкан республикада гына көндәшлеккә сәләтле итеп калдырмый, бөтен илгә дә таныта – генераль директор яңа офыкларга юл яра, бүген предприятиене инде РФнең 20 субъектында беләләр.

Бу эшләрнең барысын да җитәкче команда белән бергә күтәрә – 230 югары квалификацияле хезмәткәр турында сүз бара. Алар икътисадның төрле объектларындагы (шул исәптән энергетика, газ һәм нефть сәнәгате, автомобиль һәм тимер юл транспорты тармакларында) теләсә нинди колачлы, катлаулы проект һәм бурычларга алынырга әзер. Лена Илдар кызында хатын-кыз зирәклеге, интуиция, идарәче таланты, иҗади потенциал, аналитик фикерләү осталыгы, эшлеклелек, тормыш сөючәнлек, сөйкемлелек кебек сыйфатлар искиткеч гармонияле яраша. Аның тагын бер күркәм сыйфаты – кешеләрне тыңлый һәм фикерләренә колак сала белү сәләте. Шул ук вакытта, соңгы сүзне ул барыбер үзе әйтә, җаваплылыкны үзенә алырга курыкмый, башлаган эшен һәрвакытта да ахырына җиткерә.

– Хөрмәтле Лена Илдаровна!

Теләсә кайсы команда үзенең әйдаманы тирәсендә оеша, һәм бу кеше югары классны һөнәрмәнд, коллективын гел алга алып баручы көчле идарәче сыйфатларына ия була. Сез җитәкчеләрнең нәкъ менә шушы төренә керәсез.

Сезнең тормышта хәйриячелекнең үзгә бер урын алып торуы да мәгълүм. Гаҗәеп игелекле булуыгыз, кешеләргә ярдәм итәм дип типкән йөрәгегез, кеше язмышларына битараф булмавыгыз, мәрхәмәтлегегез нәтиҗәсендә сез мохтаҗларга актив ярдәм итәсез – бу һәртөрле мактауга лаек.

«Татэнерго» АҖ коллективы исеменнән сезне юбилеегыз белән тәбрик итәм! Бетмәс-төкәнмәс энергия, барлык планнарыгызның уңышлы тормышка ашуын телим! Сәламәтлек һәм хәерле озын гомер сезгә!

Фото «Татэнерго» АҖнән алынды, https://bti.tatarstan.ru

ЯКОВ ГЕЛЛЕРНЫҢ ӨЧ КАГЫЙДӘСЕ

«ТР Дәүләт заказы агентлыгы» генераль директоры кабинеты ишегендәге тактада ук аның эшенең төп максаты язып куелган: «Кече бизнеска ярдәм итү».

Рәүзил Хаҗиев,
«Татэнерго» АҖ
генераль директоры

1. КӨТМӘСКӘ

Бүген Татарстанның дәүләт сатып алулары тармагында Россиядәге үз электрон федераль сәүдә мәйданчыгына ия бердәнбер төбәк булуында Яков Геллерның роле зур. 2004 елның сентябрендә аның тәкъдиме буенча әле ул чакта республика премьер-министры булган Рөстәм Миңнеханов үзенең карарын имзалый. Анда бары тик ачык электрон сәүдә технологиясе буенча сатып алырга рөхсәт ителгән продукция исемлеген генә урнаштыру таләп ителә. Һәм бу тармактагы вазгыятьне кискен үзгәртә. Дәүләт оешмалары өчен сатып алуларда экономиянең 20 проценттан арткан чаклары да була.

Биш елдан соң Россия хөкүмәтенең өч федераль мәйданчык турында карары чыга, алар арасында Татарстанныкы да була. Хәзер андыйлар барлыгы сигез данә, әмма ZakazRF, башкалардан аермалы буларак, банкларныкы түгел, ә төбәкнеке.

2. ДӘШМИ КАЛМАСКА

Илдәге беренче чын сәүдә «редукцион» дип атала. Гражданлык кодексында зуррак бәягә сату аукцион буларак кабул ителгән, ә монда – киресенчә кирәк. Эше бар, ә термины – юк, дигән сүз.

Хәер, Геллер эштә дә, терминологиядә дә яңалыклар кертүгә ияләшкән кеше. Бервакыт, «Бердәм Россия» конференциясендә чыгыш ясаганда, ул Дмитрий Медведевка «импортны алыштыру» төшенчәсенең хурлыклы яңгыравын әйтә. Әгәр бәйсезлеккә омтылабыз икән, фикерләүне дә үзгәртү зарурлыгын аңлата. Көтелгән үзгәрешләр импортны алыштыру гына түгел ләбаса, әгәр Россиядә моңа кирәкле бөтен нәрсә – җиһазлар, акыллы белгечләр, оста куллар бар икән, без бар нәрсәне үзебез җитештерә һәм экспортка да чыгара алабыз бит. Ул чакта Медведев аның бу фикере белән килешә һәм «технологик суверенитет» терминын тәкъдим итә.

3. РЕСПУБЛИКАНЫ КАЙГЫРТЫП ЯШӘРГӘ

Геллерның тагын бер табышын – Республика маркетинг үзәген (РМҮ) кече бизнесның экосистемасы дип йөртәләр. Түләүсез вебинарларда укыту нәтиҗәсендә, меңнәрчә кече эшкуар РМҮ ресурсларында йөзләрчә миллиард сумлык керем ала. Капиталның икенчел әйләнеше башлана.

«Акча республикада калырга тиеш» – бу «ТР Дәүләт заказы агентлыгы» генераль директорының төп максатларыннан берсе. РМҮнең бурычы – җирле сәүдәгәрләр продукциясен ачык базарда көндәшлеккә сәләтле итү, аларны «инвестицион куыш»ларны тутырырга өйрәтү. Һәм бу нәтиҗә дә бирә. Мәсәлән, элек «Татспиртпром» этикеткаларын Уралдан кайтартканнар, хәзер исә аларны Түбән Камадагы типография бастыра. Һәм мондый мисаллар шактый.

Һәр кабинетның ишегенә анда утыручы кеше турындагы мәгълүмат языла. Яков Геллер фикеренчә, язмада җитәкче алып бара торган эшчәнлекнең ахыргы максаты күрсәтелергә тиеш. Аның ишегенә «Кече бизнеска ярдәм итү» дип язылган. Һәм ул аны алыштырырга җыенмый.

– Хөрмәтле Яков Вениаминович!

Яр Чаллы шәһәре торак идарәсендә бергә эшләгән чакларны мин һәрвакыт аеруча бер җылылык белән искә алам. Алдынгы тәҗрибә эзләп ил буйлап йөрүләребезне, аны үз территориябездә кертүне... Бу һәрвакытта да шома гына үтми, бәхәсләшкән чаклар да еш була иде, әмма алар уртак эшкә файда гына китерде һәм беренче исәп-хисап үзәкләре ачу кебек новаторлык проектларын гамәлгә ашырырга мөмкинлек бирде.

Сезнең фикерегезчә, кеше ике телдә сөйләшә: берсе – «Бу ярамый, чөнки...», икенчесе исә – «Бу барып чыксын өчен, менә моны, аннары менә тагын моны эшләргә кирәк...» Сез икенче телдә сөйләшәсез: ике нокта куясыз да, эш барып чыксын өчен нишләргә кирәклеген конкрет санап китәсез. Бу җәһәттән барлык җитәкчеләр өчен дә үрнәк булып торасыз.

«Татэнерго» коллективы исеменнән Сезне юбилеегыз белән ихластан тәбрик итәм! Сезгә шәхси тормышыгызда да, бөтен Татарстан файдасына да яңадан-яңа идеяләрегезне тормышка ашырырга җитәрлек сәламәтлек һәм көч-куәт телим!

Фото «Татэнерго» АҖнән алынды, tatar-inform.ru

мәңгелек кыйммәтләр /

игелекле эшләр

акыллы гамәлләр

Бу санда тәкъдим итәбез:

Беренче татар балеты **ничек** язылган

Татар яшьләр матбугатына **кем** нигез салган

Илүсә Хуҗинаның китап киштәсендә **нәрсәләр** бар

ҮЛЕМНӘН СОҢ – ҮЛЕМСЕЗЛЕККӘ

Луиза Янсуар

Яруллиннар – татар музыка сәнгатендәге иң мәшһүр династияләрдән. Аларның һәркайсын үз чорының символы дип атарга була. Гомере яшьли фаҗигале өзелгән, әмма исеме татар музыкасы тарихына мәңгегә кереп калган Фәрит Яруллинның атаклы «Шүрәле» балеты премьерасына 12 мартта 80 ел тула. Ул беренче милли балетны туган халкына 27 яшендә бүләк итә.

2025 ВАТАННЫ САКЛАУЧЫЛАР ЕЛЫ
80 ҖИҢҮ!

ЧЫТЫРМАННАР АША ЮЛ САЛЫП...

Габдулла Тукай поэмасына һәм татар фольклорына нигезләнеп иҗат ителгән «Шүрәле» – 3 актлы балет. Либретто авторлары – Әхмәт Фәйзи һәм Леонид Якобсон, композиторы – Фәрит Яруллин.

1940 елның 30 августында бер елдан соң Мәскәүдә татар әдәбияты һәм сәнгате декадасы уздырылачагы турындагы указга кул куела. Мондый масштаблы вакыйга өчен һичшиксез милли балет кирәклеге турында сүз күтәрелә. Татар милли опера театры 1939 елның 17 июнендә ачылган була, декадага әзерлек эшенә белгечләрне җәлеп итәләр. Декада өчен җаваплы төп балетмейстер итеп Пётр Гусев сайлана, ул исә, үз чиратында, беренче татар балетының либреттосын эшләргә Леонид Якобсонны җәлеп итә.

Бәхеткә, театр портфелендә инде әзер либретто белән балет партитурасы ята булып чыга. Аларны 1940 елда театрга язучы Әхмәт Фәйзи белән яшь композитор Фәрит Яруллин китерә. Декада өчен җаваплы төп балетмейстер Петр Гусев балетның музыкасын шунда ук югары бәяли, ә менә либреттоны, персонажлар артык күп булып, әсәр җәелеп киткәнгә, яңадан эшләп чыгарга кирәк дип таба. Либреттоның икенче вариантын Леонид Якобсон эшли.

1941 елның 3 июлендә Казанда милли балетның генераль репетициясе уза. Татар опера һәм балет театры труппасы «Остров танца» труппасы биючеләре һәм С.М. Киров исемендәге Ленинград опера һәм балет театры солистлары белән көчәйтелә. Сөембикә партиясен – Найма Балтачеева, Гали-батырны – Габдрахман Кумысников, Шүрәлене Габделбари Әхтәмов башкара.

Тулы канлы премьера турында да, Мәскәү декадасы хакында да сүз дә була алмый – илгә сугыш афәте килә. Татар опера һәм балет театры «Шүрәле»гә 1945 елда гына әйләнеп кайта. Бу вакытта композитор Фәрит Яруллин инде хәбәрсез югалган санала, яңа либреттоны Гай Таһиров эшләп чыга, куючы балетмейстерлар – Гай Таһиров белән Леонид Жуков була, дирижёр пультында – Ильяс Әүхәдиев.

Сугыштан соңгы елларда Ленинград опера һәм балет театры заказы буенча композиторлар Валентин Власов һәм Владимир Фере

Ленинград опера һәм балет театры – Мариин театры куелышындагы «Али-батыр» балеты. Али-Батыр ролендә – Борис Брегвадзе.

Фотолар: «Җыен» фонды чыгарган җыентыктан, Милли китапханә архивларыннан алынды

балетның яңа оркестровкасын ясый: техник эшкәртүләрдән тыш, музыкага да өстәмәләр кертелә, ул хәзер героик чалымнар белән баетыла. Балет хәзер инде «Али-батыр» исемен ала, нәкъ шушы исемдә ул Сталин премиясенә ия була. 1958 елда исә, үлеменнән соң, үлемсез балеты өчен Фәрит Яруллинга Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе бирелә.

«25562»

«Үлеменнән соң» диелсә дә, асылда, Фәрит Яруллинның язмышы әле сугыш тәмамлангач, дистә еллар буена анык билгеле булмый. Хәбәрсез югалган исәпләнә. Хатыны Галина Сачек белән кызы Наилә, аның хакында белергә теләп, бик күп инстанцияләргә мөрәҗәгать итә. Фәрит Яруллинның аларга язган соңгы хаты 1943 елның 31 июле белән тамгаланган:

Сөеклеләрем!

8,15 июльдә язган хатларың килеп җитте. Ярый әле теге хәбәргә ышанмагансың. Андый-мондый хәл була калса, мин бит сиңа теге дөньядан да хәбәр итәчәкмен. Хәзерге көндә, шундый мәхшәр вакытында, госпитальдә-фәләндә ята торган чак түгел. Сводкаларга карап, минем кай җирдәрәк икәнемне чамалыйсың булыр. Әлегә без ут эченнән чыккан идек, шулай да безнең егетләр дошманны ныгытып дөмбәслиләр. Төрле хәлләр булуы ихтимал... Сугыш бит... Ләкин рухи яктан без көннән-көн ныгый барабыз. Кыенлыклар булыр әле: ерткыч, үзенең холкын куып, һаман каршылык күрсәтмәкче, эттән яралган нәрсә. Тик инде безнең кеше һәммә ерткычтан да көчлерәк. Әлегә дусларыма хат язарга вакыт тимәгәнлектән, син инде аларга минем сәламнәремне тапшыр.

Кәгазь бетә, адресны язам:
Полевая почта, 25562 Г.
Кайчагында ачулы булса да,
сезне һәрвакыт яратучы Әтиегез.

Әнисенең әтисенә һәм аның исеменә тугрылыгын күреп үскән Наилә Фәрит Яруллинны эзләүдән туктамый. Татарстан Композиторлар берлеге дә кушыла. Бу елларда инде аны җитәкләү эше Мирсәет Яруллинга күчкән була: төрле җирләргә хатлар языла, ветераннарга мөрәҗәгать итәләр, фронтта аның белән бергә иңгә-иң куеп көрәшкән кешеләрнең хатирәләренә өметләнәләр. Эзләү эшен 19 нчы танк корпусының ветераннар советы рәисе, отставкадагы подполковник М.Н. Тихненко җитәкли. Нәтиҗәдә, Смоленск һәм Витебск өлкәләрен азат итү сугышларында катнашучылар, 82 нче дивизия 250 нче полкның 1942-1943 елларда һәлак булган офицерлары исемлегендә Фәрит Яруллинны табып алалар. Анда болай дип язылган була: «Укчы взвод командиры Яруллин Фәрит Заһидулла улы 1943 елның 17 октябрендә һәлак булды. Белоруссия ССРның Витебск өлкәсе Дубровно районы Яңа Тухиня авылы зиратында күмелгән».

Фәрит Яруллин, 1941 ел.



Сулдан уңга: Фәрит Яруллин һәм Заһид Хәбибуллин. 1930 нчы еллар.

Күмелгән урынны белгәч, инде барлык архивларны торгызып, тагын мондый мәгълүмат табыла: 1943 елның 17 октябре алдыннан Орша шәһәренә зур һөҗүм башлау турында фәрман алына. Фәрит Яруллин үзенең сугышчылары белән Яңа Тухиня авылының көньягына, дөресрәге, зират буена килеп урнаша. Артиллерист Н.Цейтлин: «Ул көнне дошман авиациясе 82 нче дивизия урнашкан районга бомба ударларын шулкадәр көчәйтте ки, су һәм балчык фонтаны арасында күпләрнең исән калуы икеле иде», – дип яза.

Яруллиннар – татар музыкасында иң мәшһүр династияләрдән. Тулы бер гасыр дәвамында бу гаиләнең күренекле вәкилләре татар сәнгатенең алгы сафында атлый. Әгәр дә без XX гасыр татар музыкасы тарихына күз ташласак, Яруллиннарның һәркайсын үз чорының символы дип атарга мөмкин.

Вадим Дулат-Алеев, Н.Г. Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясе ректоры, музыка белгече

ӨЧ ДӘВЕР. ӨЧ ШӘХЕС. ӨЧ ЯЗМЫШ

Заһидулла Яруллин – XX гасыр башындагы иң беренче татар профессиональ музыкантларыннан. Мамадыш өязенең Кече Сөн авылында туган егет бик иртә ятим кала, күп тормыш авырлыклары кичерә, аңа музыка училищесында да, консерваториядә дә уку насыйп булмый. Әмма музыка аның гомерлек һөнәренә әверелә.

Әйтергә кирәк, XX гасыр башы өчен музыкант һөнәрен сайлау – әле татар мохите өчен яңалык, шактый кыю адым. Татар композиторлары да, татар концертлары, музыкаль сәнгате дә юк. Әмма милли-мәдәни күтәрелеш барыбер үзенекен итә, акрынлап музыкага җитди карый башлыйлар, татар театры да нигезеннән музыкаль башлангыч белән туа. 1908 елда Идел буе шәһәрләрен гизеп кайткан Заһидулла Яруллин милли сәхнәгә күтәрелә – беренче татар пианисты сыйфатында чыгыш ясый башлый, тәүге татар музыка әсәрләренең авторы буларак таныла.

Ул Казанда XX йөз башы яңа сәнгатенә нигез салучылар белән тыгыз аралашып, фикер алышып яши. «Болгар» номерларында Тукай белән еш очраша. Аңа чын танылуны да бөек шагыйрьнең вафатыннан соң язылган «Тукай маршы» китерә.

Тукай Заһидулла Яруллинның фортепианодагы импровизацияләрен тыңларга ярата торган була. «Болгар» номерларында яшәгәндә, ул кичләрен пианист Яруллин уйнаган моңнарны тыңлар өчен еш кына ресторанга төшеп, кара төнгә кадәр утыра. «Әллүки», «Тәфтиләү», «Ашказар»ны уйнавын үтенә, аларны онытылып тыңлый.

Заһидулла Яруллин скрипкада, мандолинада, курайда, гармунда да өздереп уйный. Беренче милли ансамбль оештыра.

Бала чактан ук Заһидулла улы **Фәрит Яруллинны** музыка дөньясына алып керә, аның музыка училищесында белем алуын, чын профессиональ музыкант булып җитешүен тели. Казан музыка училищесында егет берьюлы ике белгечлек буенча укый – виолончель һәм фортепианоны үзләштерә. 1933 елда, Татарстанның перспективалы яшь музыкантлары исәбендә, Мәскәүгә укырга җибәрелә. Анда композиция буенча да дәресләр ала башлый.

Сулдан уңга: Нәҗип Җиһанов, Генрих Литинский (алда), Фәрит Яруллин, Әхмәт Фәйзи.

«Шүрәле» балетыннан кадрлар.

Укуын тәмамлаганда, яшь композитор гаҗәеп нәтиҗәләр күрсәтә: виолончель һәм фортепиано өчен Соната, Кыллы квартет һәм Симфония иҗат итә. Аңа киң катлам тыңлаучыларга юнәлтелгән жанрлар – җырлар, романслар, инструменталь миниатюралар бик җиңел бирелә. Фәрит Яруллинның скрипка һәм фортепиано өчен «Таң җыры», «Бию көе», фортепиано өчен «Бишек җыры», халык тарафыннан бик яратып кабул ителә. Ул, оригиналь җырлар белән беррәттән, татар халык җырларын – «Кара урман», «Сибай», «Сандугач»ларны эшкәртеп, халыкка яңадан бүләк итә, киң катлам тыңлаучылар арасында хөрмәт казана.

Казанга әйләнеп кайткач, Фәрит Яруллин бөтен көчен һәм сәләтен «Шүрәле» балетын иҗат итүгә юнәлтә. Балетны төгәлләүгә, Фәрит Яруллин шунда ук «Зөлхәбирә» операсын иҗат итүгә керешә. Бөек Ватан сугышы башлануга ук, яшь композитор армия сафларына алына. Аның кебек зур киләчәге күренеп торган талантны, әлбәттә, ил эчендә, тылда да саклап калырга мөмкин булыр иде, ләкин Фәритне фронттан алып калыр өчен җитди адымнар ясаучы булмый.

Фронтка китәр алдыннан Фәрит Яруллин Муса Җәлил сүзләренә «Соңгы көрәшкә» дигән җырын яза. Алар икесе дә яу кырыннан әйләнеп кайтмый.

Фәрит Яруллин – кабатланмас шәхес. Шундый кыска вакыт эчендә композиторлык таланты шулчаклы нык ачылып өлгергән очраклар бөтендөнья музыка культурасында да гаять сирәк очрый.

Чулпан Бәхтиярова,
музыка белгече, сәнгать фәннәре кандидаты

Мирсәет Яруллин – данлыклы династиянең тагын бер вәкиле. Аның да беренче остазы – әтисе. Олы абыйсы кебек үк, Мирсәетнең музыкага сәләте кечкенәдән күренә – 9 яшендә ул җыр яза. Заһидулла Яруллинның уртанчы улы Альфред бала чагында ук авырып үлеп китә. Заһидулла үзе балалары арасыннан «музыкага иң сизгере, табигый сулышлы, талантлысы Альфред иде» дия торган була.

Мирсәет Яруллин музыкага бөтен гомерен багышлый. Ул, Казан дәүләт консерваториясен тәмамлап, Татарстанда иң актив һәм күп яза торган композиторларның берсенә әйләнә. Музыканың барлык жанрларында да иҗат итә, беренче татар ораториясен яза. Мирсәет Яруллин милли музыка сәнгате үсешенә композитор буларак кына түгел, ә педагог, музыканы танытучы һәм пропагандалаучы рәвешендә дә зур өлеш кертә.

1977-1989 елларда ул Татарстан Композиторлар берлеге рәисе, Казан дәүләт консерваториясенең татар музыка сәнгате факультетының беренче деканы, профессор була.

«ШҮРӘЛЕ» БАЛЕТЫНЫҢ ЯЗМЫШЫ

Балетның дөньякүләм премьерасы, инде әйткәнебезчә, 1945 елның 12 мартында Казанда, Татар дәүләт опера һәм балет театрында уза. «Али-Батыр» исеме белән икенче редакция премьерасы 1950 елның 28 маенда Ленинградның С.М. Киров исемендәге опера һәм балет театрында була.

Ленинград премьерасыннан соң, балет дөнья бию сәхнәсендә танылa. Ул Советлар Союзының һәр шәһәрендә диярлек уйнала: Алма-Ата, Вильнюс, Горький, Киев, Львов, Новосибирск, Одесса, Рига, Саратов, Тарту, Ташкент, Улан-Удэ, Ульяновск, Уфа, Чиләбе... Һәркайсында да бик җылы кабул ителә, триумфаль төстә алга атлый. Европага алып чыккач та, аны көчле алкышларга күмеп каршы алалар.

2002 елда «Шүрәле» Ренат Ибәтуллин тарафыннан Мексикада күрсәтелә. Татар дәүләт опера һәм балет театрының балет репертуарындагы энҗесе булып балкый.

1971 елда Ленинградта «Шүрәле»не кабат сәхнәгә менгерәләр. 1980 елда ул «Урман әкияте» исеме белән совет экраннарына чыга, татар сәнгатенә зур соклану һәм ихтирам уята.

2009 елда Мариин театры, Леонид Якобсон куелышына Валерий Гергиевның музыкаль җитәкчелегендә «капиталь реконструкция» ясап, Татарстан Республикасы ярдәме белән аны кабат тамашачыга тәкъдим итә.

Фәрит Яруллин иҗат иткән беренче татар балеты бүген дә татар профессиональ музыкасының визит карточкасы булып санала.

Аның турында күпсанлы рецензияләр, мәкаләләр, театраль күзәтүләр, фәнни-тикшеренү эшләре бар.

БОЛГАРИЯ, ГДР, ПОЛЬША, РУМЫНИЯ, ЧЕХОСЛОВАКИЯ, МЕКСИКА – «ШҮРӘЛЕ» БАЛЕТЫ ЗУР УҢЫШ БЕЛӘН БУ ИЛЛӘРДӘ ДӘ КҮРСӘТЕЛӘ.

«ШҮРӘЛЕ» БАЛЕТЫ КАЙЛАРДА КУЕЛГАН ҺӘМ КҮРСӘТЕЛГӘН...

Роднулька моя!

Письмо твое от 10 получил. Ты пишешь, что театр на ремонте. Когда же начнется тогда сезон? Думают ли в театре когда-либо поставить «Шурале»? Исполнялись ли когда-либо на концерте отдельные сцены или номера за время моего отсутствия в Казани? Якобсон показывал «Шурале» Большому театру и спектакль был принят, наши умудрились сказать, что балет мы не дадим, пока не будет декады. Я готов был выругаться за это самой витиеватой солдафонской бранью.

Вообще, с самого начала моей творческой деятельности всегда Казань вставляла спицы в мою колесницу. Как бы я не старался думать об этом, но ничего не могу сделать с собою...

Обнимаю, целую. Фарид.

Фәрит Яруллинның хатыны – балерина Галина Сачек-Яруллина.

«АЗ СҮЗЛЕ, ТЫЙНАК ИДЕ...»

Торак йортта торыр урыным Фәрит Яруллин белән бер бүлмәдә булып чыга. Бер ел үткәч кенә, Фәритнең атасы «Тукай маршы»н иҗат иткән Заһидулла Яруллин икәнен беләбез. Фәрит шапырынырга, мактанырга бер дә яратмый иде. Аз сүзле, тыйнак, һәрбер әйткәнен уйлап, ышандырырлык дәлилләр китереп җавап бирүчән...

Ашханәдә дежур торган көннәр безнең икебез өчен дә бәйрәм була иде. Чөнки кабыклы бәрәңге яки тары боткасы белән ул көннәрдә тамагыбызны туйдырып рәхәтләнә торган идек.

Бервакыт безне, студентларны, Казанның санпропускниклы мунчасына алып бардылар. Шунда өстебездәге барлык кием-салымнарыбызны салып тапшырып, юынырга кереп киттек. Аннан чыккач, Фәрит яныма килде дә:

– Мөбарәк, монда кара әле, пальтомны нишләткәннәр? – ди. Ни күрим, дустымның пальтосында, кесәсе тирәләрендә, йодрык сыярлык зур-зур тишекләр.

Фәрит кесәләрендә икмәк каты-котылары йөртә торган булган икән. Санпропускник камерасында мыжлап күселәр яшәгән. Икмәк барлыгын сизеп, ашап бетергәннәр, кесәләрен дә кимереп чыкканнар. Фәрит төне буе күселәрне сүгә-сүгә пальто ямады.

Татарстанның атказанган артисты Мөбарәк Батталов истәлекләрен журналист Локман Бадыйкшин язып алган.

«ШҮРӘЛЕ АБЫЙ»

1940 елгы Казан. Татар совет республикасы оешуының 20 еллыгына багышланган демонстрация. Миңа, Днепропетровскидагы театрдан яңа гына Татар опера һәм балет театрына чакырып алынган солисткага, бу шәһәрдә барысы да яңа. Колоннада эш буенча яңа иптәшләрем белән барам, «ура» кычкырган тавышлар, җырлар, шаярулар, көлешүләр...

Аның ничек янәшәмдә пәйда булганын сизми дә калдым. «Әйдәгез, танышыйк, – диде ул. – Минем исемем Фәрит». Җиңелчә, сизелер-сизелмәс кенә акцент, әллә ни озын булмаган уртача буй, артка тарап куелган, дулкынланып торган куе чәчләр, соры күзләрендә – ихлас елмаю.

Республика тормышында бик зур вакыйга – Мәскәүдә татар совет сәнгате декадасына әзерлек бара. Яңа гына комсомол яшеннән чыккан Нәҗип Җиһанов «Алтынчәч» операсын тәмамлап килә, Җәүдәт Фәйзи – «Башмагым»ны, ә «минем Фәритем» (озакламый мин аны шулай атый башладым), «Шүрәле»не эшләп-төзәтеп, театрдан кайтып та керми...

Нәҗип Җиһановның кызы Светлана, Фәрит аларга кергәндә: «Шүрәле абый! Әтием, Шүрәле абый килде!» – дип, муенына асылына торган иде.

Фәрит үзенең балеты турында берөзлексез сөйли һәм уйлый. Хәтта фронтта да аны бу уйлар ташламады, ул «иң йомшак килеп чыккан» икенче актны төзәтү турында хатларында язды...

Галина Сачек-Яруллина истәлекләреннән.

«МИН КИТМӘСӘМ, КЕМ БАРА?»

Фәрит безнең театрдан ерак тормый иде. М. Горький урамы, 11 нче йорт ишегалдында беренче катта. Мин шул ук урамда – 17 нче йортта. Күршеләрчә аларга кергәнем бар. Ул да безгә хатыны Галина белән кергәләгән иде. Очрашуларның берсендә фортепианомы яки виолончель өченме, ачык хәтеремдә калмаган, инструменталь әсәр язуын сөйләде. Пианинода уйнап, шул яңа әсәрнең темалары белән таныштырды...

Бөек Ватан сугышы башлана. Июльнең беренче көннәре булса кирәк, өемә саубуллашырга Фәрит Яруллин килә.

– Сез – талант иясе. Сезнең талант – ул ил, халык байлыгы. Бүген сезнең кулыгызда бронь булмау – бу бер аңлашылмаучанлык кына. Хәзер үзем военкоматка барам, сөйләшәм, – дим.

Фәрит сабыр гына, әмма катгый җавап кайтара:

– Мин китмәсәм, кем бара? Ил алдында барыбыз да бер җавапта.

1943 елда көтмәгәндә театр адресына Фәрит Яруллиннан хат алдым.

«Хөрмәтле, кадерле иптәш Ильская!

...Сезнең белән танышканда, мин беренче татар балеты «Шүрәле»не тәмамлап кына бетергән идем. Ә хәзер, ике ел узганнан соң, минем тормышым тамырыннан ук нык үзгәрде. Мин сугышның кырыс мәктәбен үттем...»

Фәрит минем күңелемдә батырларча һәлак булган улым Фуат белән бергә саклана. Улымны өзелеп сагынган кебек, Фәритне дә өзелеп сагынам.

Фатыйма Ильская истәлекләреннән.

МӨХӘММӘТ ПАРСИН: ЯЗМЫШНЫҢ УРАУ ЮЛЛАРЫ

Айдар Шәйхин

Аның исеме матбугат һәм театр тарихын өйрәнүчеләргә яхшы таныш. Ул бүген дә басылып килә торган газеталарда эшләгән, татар театры тарихын тасвирлаган, татарларда комсомол хәрәкәтен оештырган һәм... үзе тарихта урынсыз кала язган.

ИНКЫЙЛАБ АЧКАН ИСЕМ

Мөхәммәт Зариф улы Парсин 1899 елның 9 мартында Казан губернасы Казан өязенең Олыяз авылында туа. Хәзерге вакытта аның туган авылы Биектау районына карый. Казанга якын җирлектә туып-үскән егет әүвәл үз авылында белем алса, соңыннан губерна үзәгенә килә. Аның укытучылар курсын тәмамлавы, ә аннары Казан арты өязләрендә «халык укытучысы» булып эшләве билгеле.

Февраль һәм Октябрь инкыйлаблары дәвере – Мөхәммәтнең дә ир-егет булып җитешкән, дөньяда үз эзен калдырырга омтылышы зур булган еллар. Ул һәр җирдә актив, инициативалар белән яна, нидер эшләргә, гел хәрәкәттә булырга тырыша. Шуңа да ул штаттан тыш инструктор булып та йөри. Комсомол хәрәкәте барлыкка килүгә үк аңа килеп кушыла һәм үзе төрле урыннарда комсомол ячейкаларын оештыра. Бу елларда аның язмышы Казан арты, аерым алганда, хәзерге Әтнә төбәге белән бәйле.

Татарстанда яшьләрнең коммунистик берлеге тарихында Парсинның үз урыны бар. 1920 елның сентябрендә ул Татарстан комсомолының беренче конференциясендә өлкә комитетына сайлана. Шул ук көннәрдә, ТАССР делегаты буларак, Көнчыгыш халыклары комсомоллары секцияләре һәм оешмаларының беренче Россия конференциясендә (Мәскәүдә) катнаша һәм анда рәислек итә. Егетнең абруе яшь республикада гына түгел, ә тулы бер илдә дә танылa. Ә 1922–1924 елларда ул Россия комсомолы Үзәк комитетының татар-башкорт яшьләре бюросы президиумы әгъзасы булып тора.

Хәтерләсәгез, үз заманында Муса Җәлил дә Мәскәүдә комсомол үзәк комитетының татар-башкорт секциясендә әгъза булган. Ул елларда СССР башкаласында татарча газета-журналлар да чыга, нәшрият та эшли, мәктәпләр, клублар һәм драма берләшмәләре дә ачыла, сәяси яктан «дөрес» оешмалар да гөрләп тора. 1922 елның язында Парсин Мәскәүгә чакыртып алына, үзәк татар комсомол газетасы булган «Яшь эшче»гә редактор итеп билгеләнә. Бу елларда ул Мәскәү дәүләт журналистика институтында укый. Партия органы булган «Эшче» газетасының редактор урынбасары булып эшли.

ЯШЬЛӘР МАТБУГАТЫНА НИГЕЗ САЛУЧЫ

Мөхәммәт Парсинның матбугат һәм комсомол эшенә Мәскәүгә чакырылуы, әлбәттә, очраклы булмый. 1919 елда ул «Эш» һәм «Кызыл Армия» газеталары белән хезмәттәшлеген башлый. Мәскәүгә киткәнче, Казанда комсомолның татарча матбугатын оештыруда катнаша. 1920 елның 22 гыйнварында Казанда чыга башлаган «Кызыл яшьләр» газетасында исә актив язучы гына түгел, аның икенче баш мөхәррире дә була. Парсиннар нигезләгән газетаны бүген без «Татарстан яшьләре» исеме белән беләбез.

Фото: ТР Милли музей фондларыннан

Парсин татар яшьләр матбугатының тәүге үрнәкләренең берсе – «Кызыл Шәрекъ яшьләре» журналын оештыручы. Аның беренче мөхәррире дә. Дөрес, бу журнал озак эшләргә өлгерми, 1920 нче еллар азагына әкренләп сүнә. Алга таба журналның исеме «Октябрь яшьләре», «Авыл яшьләре», ә 1930 елдан «Колхоз яшьләре» дип үзгәртелә. 1933 елда «Атака» журналы белән берләштерелә (хәзер – «Казан утлары»).

Әлеге журнал үз вакыты өчен актуаль була. Аның битләрендә татар яшьләре, аларның проблемалары һәм перспективалары турында мәкаләләр чыга, төрки яшьләр съездларына, форумнарына һәм конгрессларына аерым игътибар бирелә, барлык материаллар Маркс-Ленин теориясен пропагандалый. Журнал битләрендә Муса Җәлил, Гадел Кутуй, Фатих Сәйфи, Гыйлемдар Баембәтов, Вәли Шәфигуллин, Сәлах Атнагулов, Галимҗан Ибраһимовларның язмалары һәм мәкаләләре чыга. Әмма иң беренче санның беренче бите Парсинның «Безнең юлбашчыбыз – Интернационал юлы» мәкаләсеннән башлана.

1924 елның азагында Мөхәммәт Казанга кайта. Аңа 25 яшь, барысы да алда сыман. Ул янә матбугат эшенә чума. «Кызыл Татарстан» газетасы хәбәрчесе булып йөри, «Крестьян газеты», «Эшче» газетасына, «Кызыл Шәрекъ», «Чаян» журналларына сәнәгать һәм авыл хуҗалыгы үсеше турында яза. Татар авыл һәм урман хуҗалыгы хезмәтчәннәре һөнәри берләшмәсе органы буларак чыга башлаган «Ялчы» газетасында да хезмәт итә (1927–1932 елларда чыга). «Ялчы»ның махсус проектлары – авыл хезмәтчәннәре өчен календарьлар чыгару, Сталин нотыкларын татарчага тәрҗемә итеп бастыру, тематик җыентыклар нәшер итү кебек эшләрдә дә катнаша.

ТЕАТРДАН – ӘДӘБИЯТКА

Мөхәммәт Парсинның татар театрына багышланган мәкаләләре, спектакльләргә рецензияләре, шулай ук татар әдәбияты һәм сәнгате үсеше хакында язмалары байтак. 1940 нчы елларга кадәр ул татар театры үсешен игътибар белән күзәтеп бара. Бу очраклы түгел, 1917-1918 елларда ул үзе дә беренче татар театр труппасы – «Сәйяр» белән хезмәттәшлек итә. Казан артында мәгариф, мәдәният һәм комсомол эшләре белән янып йөргәндә, хәзерге Әтнә театрының да нигез ташларын салдырып калдыра. Әтнә һәм Алат волостьларында мәктәпләр инспекторы булып эшләгән чагында, ә төгәлрәк әйткәндә, 1918 елның декабрендә, Парсин, авыл яшьләрен җыеп, спектакль куярга була. Сәхнәгә куяр өчен «Бәхет кошы» дигән пьеса сайлана.

«Авылдагы иң зур мәктәпне сайлап алып, шуның бер читенә сәхнә урыны ясаттык. Чыпталарны буяштыргалап, декорацияләр эшләдек, төрле кешеләрдән чаршаулар, бутафория әйберләре җыйдык», – дип искә ала ул әлеге вакыйга турында.

Спектакль уйнала, аңа хәтта матбугат чаралары да игътибар итә. 1919 елның февралендә «Эш» газетасында спектакльгә карата тәнкыйть мәкаләсе басыла. Тора-бара бер уеннан башланган театр хәрәкәте Әтнәдә көчәеп ала. 300–400 кеше сыярлык «Ленин клубы» оештырыла, декорация һәм бутафория цехлары булдырыла.

Сәхнә тормышын эчтән дә белгәнгә, мәдәни күзәтүче буларак, ул утрак тормышка күчкән Әтнә татар театрының премьераларын карап бара. Алар өчен борчылып, ут йотып яши. 1925 елда «Безнең юл» журналында чыккан мәкаләсендә, театрның чираттагы сезонына йомгак ясап, болай ди: «Татар театры акрынлык белән булса да үсә, ләкин аңа бик күп күтәреләсе бар әле. Ул бүгенге көнне, бер яктан, материальный җитешсезлек белән авырса, икенчедән мәгънәви яктан сырхаулы. Менә бу эчке һәм тышкы яктагы чирләрне бетерү юлында Гыйльми үзәк, главполитпросвет, наркомпросның художество бүлеге һәм театр администрациясе шикелле оешмаларның җиң сызганып, бергәләшеп эш күрүләре кирәк».

1925 ҺӘМ 1926 ЕЛЛАРДА, КАЗАНДА ТАТАР ТЕАТРЫНА 20 ЕЛ ТУЛГАНДА, ПАРСИН ТУПЛАГАН ИКЕ КИТАП ДӨНЬЯ КҮРӘ. БЕРСЕ «ТЕАТР МӘҖМУГАСЫ: ТАТАР ТЕАТРЫНЫҢ 20 ЕЛЛЫК БӘЙРӘМЕ» ДИП АТАЛА, ИКЕНЧЕСЕ «ТАТАР ТЕАТРЫ. 1906–1926». БУ ИКЕ КИТАП БҮГЕН ДӘ ТАТАР СӘХНӘСЕ ТАРИХЫН ӨЙРӘНҮЧЕЛӘР ӨЧЕН КЫЙММӘТЛЕ ЧЫГАНАК БУЛЫП ТОРА.

Театр тарихына багышланган язмаларында ул, татар мәдәнияте тарихын өч чорга бүлеп, төрле иҗтимагый формацияләрдәге икътисадый халәтнең мәдәнияткә турыдан-туры йогынтысына игътибар итә. Әлбәттә, марксизм-ленинизм теориясеннән чыгып эш итә. Театрның «туган көне» дип кайсы датаны билгеләү мәсьәләсен дә җентекләп өйрәнә. 1906 елга кадәр үк төрле шәһәрләрдә татарлар татарча куйган спектакльләрне барлый. «1906 елның 22 декабре» дигән бүгенге сакраль датага бик игътибар бирмичә, Уфада 1906 елның 16 апрелендә куелган «Өч хатын белән яшәү»

Клуб. 1948 ел.

«Ураза бәйрәмендә» китабы.

спектакле һәм Казанда шул ук елның 5 маенда уйналган спектакльләр турында уйлана.

Татар театрында 1920 нче елларда еш куелган спектакльләрнең берсе дә Мөхәммәт Парсин исеме белән бәйле. Ул «Ураза бәйрәмендә» исемле ике пәрдәле пьеса яза. «Дингә каршы көрәш» чорында мондый әсәрләр бик актуаль була.

Журналист һәм тәнкыйтьче буларак Парсинны яхшы искә алган яшь язучылар да күп булган. Ул төзегән һәм мөхәррире булган җыентыкларда 30 нчы елларда исемнәре яңгырый башлаган яшь әдипләрнең беренче әсәрләре басыла. Мәсәлән, Гали Хуҗиев, Хабра Рахманнарның шигырь-пьесалары 1930 елда «Ударниклар килә» җыентыгында дөнья күрә. Бу да төрле эшләрдә лидер булган Мөхәммәтнең тынгысызлыгы нәтиҗәсе.

Парсинның үзенең барлыгы 14 китабы басылып чыга.

СЫНАУЛАР ВАКЫТЫ

1933 елда Парсинның сәламәтлеге начарлана. Күзе начар күрә башлавы аркасында, ул журналист эшен ташларга мәҗбүр була. Икенче төркем инвалидлык алганнан соң, Казанда төрле артельләрдә һәм «Кызыл Татария» нәшриятында реклама һәм игъланнар өчен җаваплы кеше булып эшли.

Парсиннар заманы турында сөйләгәндә, әлбәттә, репрессияләрне телгә алмыйча булмый. Шәхесләрнең күбесе йә репрессияләнгән, йә «халык дошманнары»на каршы көрәшнең һичьюгы матбугатта барган «фронты»нда катнашкан. Парсинга ике лагерьда да булырга туры килә. 1920 нче еллар ахыры һәм 1930 нчы еллар башында, ул «солтангалиевчылар»ны һәм «җидегәнчеләр»не тәнкыйть итә.

Парсин бастырган китаплар арасында «Комсомол и султангалеевщина» кебек хезмәт тә бар. Аңлашыла ки, ул еллардагы совет язучыларының күбесе «солтангалиевчылык»ны фаш итүгә үз өлешен кертмичә калмаган. Әгәр дә Солтангалиевны һәм аның «ялчылары»н тәнкыйть итмисең икән, димәк син… син аларның берсе түгелме?

1990 нчы елларда Парсинны репрессия тегермәненә су коючылар исемлегенә кертүчеләр дә булды. Әйе, һичшиксез, «җидегәнчелек» эше барган дәвердә ул тәнкыйть-фаш итүләр белән мавыга. Әмма озакламый аның үзенә дә корбан булыр көннәр җитә…

Парсин – Галимҗан Ибраһимов тирәсендә тупланган яшьләрнең берсе. Бу төркемдә Кави Нәҗми, Гомәр Гали, Гомәр Толымбайлар да, Кутуй-Такташлар да бар. 1937 елгы сорау алуларда Парсинның да исеме яңгырамый калмагандыр. Чын авторитетка ия Ибраһимов Парсинны үз укучысы итеп күрә. 1925 елда, Галимҗан Ибраһимов Казандагы Гыйльми үзәктә җитәкчелек иткәндә, Мөхәммәт Парсин бу оешманың татар редакция коллегиясенә кертелә. Күпсанлы утырышларның беркетмәләрендә аның фамилиясе еш очрый. Мәсәлән, 1925 елның 27 февралендә Ибраһимовның Ризаэтдин мөфти Фәхретдин белән очрашуында Парсин да катнаша. Әйтергә кирәк, бу рәсми булмаган очрашу Академүзәк рәисенең үз фатирында үтә.

Сәяси золым тегермәне бар көченә җилгәргәндә язылган әләк хатларында, ялган тулы НКВД делоларында һәм матбугатта чыккан куркыныч мәкаләләрдә Ибраһимовны зәгыйфь рухлы яшь коммунистларны үзе тирәсенә җыеп, «бозып», тайгак юлдан йөртүдә гаеплиләр. Бакый Урманче да бер язмасында: «Галимҗан Ибраһимов яшьләргә йогынты ясарга бик тырышты, Мөхәммәд Парсин аның тәрбиясендә үсте», – дип аерым әйтеп үтә. Галимҗан Ибраһимов һәм аның шәкертләре өчен кара көннәр 1936 ел ахырында башлана.

1941 елның 6 октябрендә, советка каршы милли оешмалар эшчәнлегендә катнашы бар дип, Мөхәммәт Парсин кулга алына. 1942 елда 5 елга Красноярск краеның Сухобизимск районына сөргенгә җибәрелә. 1946 елның 13 октябрендә иреккә чыгарыла.

«КАРА ТАП БЕЛӘН ГОМЕР БУЕ ЙӨРЕП БУЛМЫЙДЫР БИТ...»

Казанга кайткач, Мөхәммәт Парсин күпмедер вакыт «Татхудожник» кооперативының рәсем продукциясен сату буенча вәкиле булып эшли. 1948 елда инде ул Республика татар күчмә театры администраторы булып урнаша. Татарстан дәүләт архивында Парсин исеменә язып бирелгән маршрут кәгазьләре бар. Күчмә театр һәрвакыт хәрәкәттә. Парсин, администратор буларак, труппа белән бергә. Мәсәлән, 1948 елның 20 маенда күчмә театр, 11 кешелек бригада булып, Тәкәнеш районы авылларында йөри. Хәлбуки, даими сәфәрләрдән торган эш Парсинның сәламәтлеге өчен бер дә яхшы сынау булмый. 1949 елда ул Яшел Үзән шәһәрендә яши башлый.

Матбугат әһелләре белән бергә. Парсин беренче рәттә, сулдан беренче. 1926 ел.

Дәүләт архивында Парсинның КПССның Татарстан өлкә комитеты секретаре Салих Батыевка язган хатының караламасы саклана. Ул 1954 елның 25 апрелендә язылган. «Несмотря на прошедших длительного времени с момента возвращения из ссылки и снятие судимости по амнистии до сих пор не могу устроиться работать по своей специальности лишь потому, что местные органы не дают возможность из-за боязни и перестраховки»*.

Парсин хатта үзенең төп һөнәре – матбугат һәм әдәбият өлкәсе икәнен искәртә. 1953 елда ул берничә тапкыр эшкә урнашырга тырышып карый. «Совет Татарстаны» газетасының Яшел Үзәндәге хәбәрчесе булырга тели, әмма редактор Рябков аңа бу мөмкинлекне бирми. Шул ук елны «Совет әдәбияты» журналына өч шигырен җибәрә: әсәрләре дә басылмый, үзенә бернинди җавап та килми. Соңрак бу шигырьләр «югалган» булып чыга.

1953 елның 10 октябрендә Татарстан халык иҗаты йорты Париж коммунасы исемендәге клуб директоры иптәш Шуловка хат юллый. Иҗат йорты бу клубның татар театр коллективы җитәкчесе итеп Мөхәммәт Парсинны билгеле һәм, аны рәсми рәвештә эшкә алуга, хәбәр итүләрен сорый.

Париж коммунасы исемендәге клуб 1929 елда ук «Красный металлист» заводы янында ачыла. Хәзер аның урынында «Волга» профилакторие урнашкан. Озак еллар буена әлеге клуб Яшел Үзән бистәсенең һәм шәһәренең мәдәни тормышы үзәге булып тора. Монда драма түгәрәкләренә йөрүчеләр спектакльләр куя, кинофильмнар күрсәтелә, бал-маскарадлар, тантаналы җыелышлар һәм башка совет бәйрәмнәре үтә. Ләкин бу клубка да Парсинны эшкә алмыйлар. Хат клуб директоры үзе таләп иткән документ була. Аны Парсин Казанга барып үзе яздырып ала. Әмма Шулов, «Казаннан направление» булуга карамастан, Парсинны кабул да итми, эшкә дә алмый.

Батыевка хатын йомгаклап, Парсин болай дип яза: «Человек не может же вечно носить пятно или вечно быть наказуемым. Я хочу работать по своей профессии и служить своему народу пером и словом».

Мөхәммәт Парсинга шәһәрдә үткән үзешчәннәр кичәләрендә үз шигырьләрен укыр өчен дә бюрократик киртәләр аша үтәргә кирәк була. Архивтагы документларның берсе – мәдәният сараеның сәнгать җитәкчесе С. Шәкуловның иптәш Морзахановка мөрәҗәгате. Ул Парсинга шигырьләрен укырга рөхсәт алуда һәм шигырьләрен «шомартырга» ярдәм сорый.

«Родина» мәдәният сараеның татар ансамбле җитәкчесе Хәйруллин да 1954 елның 20 декабрендә Морзахановка шундый эчтәлектә хат җибәрә: Парсинның 2 шигырен укырга рөхсәт сорый.

Бер төркем иптәшләре белән бергә. Парсин уңнан беренче. 1959 ел.

Эш эзләү мәшәкатьләре дәвам итә. 1955 елда Идрис Туктарның Парсин Мөхәммәт иптәшкә бәяләмәсенә юлыгабыз: «Я лично верю, что т. Парсин будет честно и добросовестно работать администратором Татгосфилармонии». Шундый ук эчтәлектәге характеристиканы Яшел Үзәннең шәһәр газетасы мөхәррире Кушаев та бирә. Аның бәяләмәсеннән без Парсинның бу елларда Яшел Үзәндәге бер предприятиенең торак-хуҗалык бүлегендә эшләвен беләбез.

Шулай итеп, сөргеннән кайткач та Парсинга әле дистә ел буена диярлек үз исемен аклау, кара таптан арыну өчен көрәшергә туры килә. Ниһаять, Мөхәммәт Парсинның исемен аклау 1956–1957 елда үзенең кульминацион ноктасына җитә. Ул аклана. 1957 елда генерал-лейтенант Якуб Чанышев һәм партиянең күренекле әгъзасы Нур Сәйфи кул куйган бәяләмәдә Парсинның 1920 елдан башлап совет идеяләре хакына башкарган эшләре тасвирлана.

1955 елның 1 апреленнән Мөхәммәт Парсин Бөтенроссия сукырлар җәмгыятенең районара оешмасын җитәкли.

Шигырьләр язуын дәвам итә, аларны иҗат кичәләре, концертларда һәм Яшел Үзән радиосында укый. 1957 елның 1 сентябреннән Парсинга җирле дәрәҗәдә персональ пенсия бирелә башлый.

1963 елның 8 апрелендә Яшел Үзәндә вафат була. «Тормышта, эшендә, семьясында һәрвакыт гадел, саф күңелле, югары культуралы Мөхәммәт ага Парсинның үлүе безнең барыбыз өчен дә зур югалту», дип язалар матәмнамәдә.

МӨХӘММӘТ ПАРСИН ЯЗМЫШЫНДА БЕР ГАҖӘП НӘРСӘ ДӘ ЮК ШИКЕЛЛЕ. ӘММА БУ БИОГРАФИЯ 20 НЧЕ ГАСЫРНЫҢ ҮЗ БАЛАЛАРЫН БЕР КҮТӘРҮЕ, БЕР АТЫП БӘРҮЕНӘ МИСАЛ ТҮГЕЛМЕ?

* *Хатта авторның орфографиясе һәм стилистикасы сакланган.*

китап к

«ӘЛИФБА» БЕЛӘН ХАЛЫК ӘКИЯТЛӘРЕН БАЛАЛАРЫМА БҮЛӘК ИТӘЧӘКМЕН»

Татарстанның атказанган артисты, М.Җәлил исемендәге Республика премиясе лауреаты Илүсә Хуҗина иseме соңгы елларда татар музыка сәнгатен сөючеләр өчен затлылык, зәвык кына түгел, өрфия матурлык һәм сихри аһәң символына да әверелде. Без аның спорт һәм сәяхәтләр ятарканын беләбез, ә менә китаплардан ниндиләргә өстенлек бирә икән?



Иң беренче хәтерләгән китабым – «Әлифба». Ул һәр баланың иң яраткан китабыдыр. Ә икенчесе – «Татар халык әкиятләре». Ул шундый зур, калын, соры тышлы китап иде... Рәсемнәре юк, шрифты бик вак, әмма андагы тарихлар шулкадәр мавыктыра, аерыла алмыйсың... Хәзер, еллар узгач, әниемнәрдә бу ике китапны да киштәдә эзләп таптым, кадерләп саклап куйдым. Беренче «Әлифба»мны да, «Татар халык әкиятләре»н дә киләчәк буынга – балаларыма, ә аннан инде оныкларыма тапшырачакмын. Шулар аша аларга үз телемне, милли байлыгыбызны да бүләк итәрмен, дип ышанам.

Бала чакта иң яратып укый торган журналым «Салават күпере», үсмер елларда «Сабантуй», «Ялкын» иде. Әнием аларга махсус мин укысын өчен язылa, алар безнең өйгә килә, мин бик көтеп алам. Тагын миңа «Музыкальная жизнь» дигән журналны яздырып алдырдылар.

Мин күбрәк профессиональ, ягъни музыкага кагылышлы китаплар укыйм. Алар нигездә – вокал техникасы, җырчы-

Фотолар Илүсә Хуҗина архивыннан алынды

иштәсе



ның сәхнә күнекмәләре, осталыгы турында. Миңа боларны уку, белеп, өйрәнеп бару бик кызык. Чөнки син ничек кенә талантлы булсаң да, тавышың нинди генә яхшы булса да, аны тәрбияләмәсәң, үзеңне үстермәсәң, бер талант белән генә ерак китеп булмый. Тагын психологиягә караган китапларны бик яратам.

Иң тетрәндергән әсәрләрнең берсе – Гүзәл Яхинаның «Зөләйха күзләрен ача» китабы. Мин аны бик әсәрләнеп укыдым, ә менә киләсе китабы – «Дети мои» – алай ук тәэсирләндермәде.

Бүгенге көндә безнең бик күп вакытыбызны Интернет, социаль челтәрләр «урлый». Әлбәттә, алар кирәкле, файдалы да, әмма мәгълүмат шулкадәр күп, хәтердә сакланып калмый. Кайбер нык җәлеп итмәгән әсәрләр дә онытылып бара, күрәсең, баш мие үзен шулай саклый.

Һәркемгә укырга киңәш итә торган китабым – Мөхәммәт Мәһдиевнең «Без кырык беренче ел балалары». Аны укыганда рәхәтләнеп елыйсың да, көләсең дә. Бер үк вакытта ул бик җиңел, гади, халыкчан тел белән язылган.

Шигырьләр укырга яратам. Үзебезнең татар шагыйрьләрен дә, рус шагыйрьләрен дә, чит ил әдәбияты вәкилләрен дә.

Сергей Лазаревның «Диагностика кармы» – өстәл китабым. Без, артистлар, гастрольләргә еш һәм күп йөрибез. Лазарев китабы һәрчак минем белән. Ул миңа бик булыша, төрле сорауларга җавап табарга ярдәм итә. Узып барышлый гына укый торган китап түгел, аңа тулаем кереп китәргә кирәк.

Мәктәп дәреслекләренә кергән, университетларда укырга бирелә торган язучыларның әсәрләре, ягъни үлмәс классика һичшиксез укылырга тиеш. Алар юкка гына гасырлар буе кешелек тарафыннан сайлап алынмаган.

Кәгазь китапларга өстенлек бирәм. Электрон форматта да укырга була, әмма кәгазь китапның – үз тәме, үз яме.

Музыкант буларак, аудиокитапларның күбесен кабул итә алмыйм. Моның өчен китапны укыган тавыш иясе мине бик ышандырырга, якын булырга тиеш, икенчедән сыйфат ягы гаять мөһим. Интонацияләр, тавыш тембры... Укыган затның китапны чынлап та тоеп, бар нечкәлекләрен тыңлаучыга җиткерә алуы.

Китап ул – мин генә белә, тоя, кичерә алган дөньяга ишек. Шуңа аны һәркем үзенчә кабул итә, кичерә, яши.

ШИШКИН МАНЗАРАЛАРЫ (0+)

Рәсем сәнгатенең реалистик пейзаж остасы әсәрләре «ТР Дәүләт сынлы сәнгать музееның шедеврлары. Иван Шишкин» күргәзмәсендә урын алган. Рәссамның Казандагы эшләре тупланмасы әһәмияте буенча илдә өченче урында тора (Третьяковка һәм Рус музееннан кала). Анда 38 картина, 25 рәсем һәм 350дән артык басма графика әсәре саклана. Экспозиция рәссамның иҗади үсешен күзәтергә мөмкинлек бирә, чөнки ул 1850-1860 нчы елларга караган беренче эшләрен дә, рәссам булак җитлегү чорына кагылышлы картиналарын да, тормышының соңгы елларында иҗат иткән әсәрләрен үз эченә ала.

16 мартка кадәр
Көн саен 11:00 дән 20:00 сәг.кә кадәр
ТР ДССМның «Хәзинә» Милли сәнгать галереясы
Казан Кремле, 3 подъезд



«РУС КИРПЕЧЕ: КЕЛӘЙМӘ, ТАМГАЛАР, БИЛГЕЛӘР» (0+)

Рус крепостьлары һәм сарайлары салынган кирпечне, борынгы төзелеш материалын ясау һәм тамгалау технологиясен күрсәтергә мөмкинлек бирә торган иске коралларны, формаларны Свияжск утрау–шәһәрендәге үзенчәлекле экспозициядә күрергә мөмкин. Сирәк экспонатларның күбесе – шәхси коллекцияләрдән, шулай ук күргәзмә партнеры – башкаладагы «Царицыно» музейтыюлыгыннан. Экспозицияне кирпеч осталары, кирпеч заводлары (сарайлар), кирпечтән архитектура һәйкәлләре, кирпеч өемнәре сурәтләре тулыландыра. Аерым бүлек заманча кирпеч җитештерүгә багышланган.

23 мартка кадәр
Көн саен 9:00 дән 16:30 сәг. кә кадәр
(шимбә – 9:00 дән 18:00 гә кадәр
Свияжск тарихы музееның Күргәзмә залы
Свияжск утрау-шәһәре, Успенская ур., 22, корпус 4

МАТИСС, СЕЗАНН, ПИКАССО ҺӘМ ГҮЗӘЛ ЭПОХА (0+)

Belle Époque, яки Гүзәл эпоха – Европа тарихының XIX гасыр азагыннан алып 1914 елга кадәрге чоры шулай атала. Әлеге дәвер сынлы сәнгатьтә һәм бөтендөнья тарихында үзгә бер урын алып тора. Европа өчен иң бәхетле һәм ваемсыз еллар бу, гөрләп үсү, тынычлык, муллык эрасы. Һәм барыннан да бигрәк Франция өчен - Belle Epoque атамасы шунда туган. «Эрмитаж-Казан» үзәгендә ачылган экспозиция кешелекнең бөек мирасы – Гүзәл эпохада иҗат ителгән картиналар, графика, декоратив-гамәли сәнгать әсәрләре белән таныштыра. Казан экспозициясендә Камиль Писсарро, Клод Моне, Поль Гоген, Андре Дерен, Огюст Ренуар, Анри Море, Альфред Сислей, Поль Сезанн, Анри Матисс, Пабло Пикассо, Анри Руссо, Альфред Моурер, Альфонс Муха, Анри де Тулуз-Лотрек, Эжен Грассе һәм башка осталарның даһи әсәрләре урын алган.

Көн саен 10:00 дән 18:00 сәг. кә кадәр
(җомга – 11:00 дән 20:00 гә кадәр)
Ял көне – дүшәмбе
«Эрмитаж-Казан» үзәге, 3 кат
«Казан Кремле» музей-тыюлыгы

афиша

Фото: kazan-kremlin.ru, tinchurinteatr.ru, izo-museum.ru, ostrovgrad.ru, tatar-inform.ru, kamalteatr.ru

ИДЕГӘЙ МИРАСЫ (12+)

Каһарманлык һәм туган җиргә мәхәббәт, дуслык һәм дошманга нәфрәт, гаделлек һәм фидакарьлек. Татар халкының мәшһүр эпосы мотивлары буенча куелган «Идегәй» спектакле энә шул турыда. Ә тагын бу спектакль үзара низагларның – дәүләт мәнфәгатьләренә каршы көчле шәхесләр көрәше һәм кешеләр арасындагы бәрелешләрнең нәрсә белән тәмамлануы хакында да сөйли. Спектакль безне сәхнәдә тарихи дөреслеккә туры китереп диярлек реконструкцияләнгән Алтын Урда чорына күчерә. Әлеге максатта артистлар өчен хәтта төрки көрәш сәнгате буенча мастер-класслар оештырылган. Сугыш алып бару үзенчәлекләре турында консультацияне традицион көрәшләрне тикшерү үзәге җитәкчесе, фланкировка һәм кылыч-хәнҗәр йөртү буенча тренер Виктор Тарасов биргән.

18 март, 18:30 сәг. тә
К. Тинчурин исем. Татар дәүләт драма һәм комедия театры
Казан, Горький ур., 13

БАШМАГЫ ДА БАШМАГЫ (16+)

Нигезенә алтын белән чигелгән бер пар хатын-кыз туфлиенең юкка чыгу вакыйгасы салынган, галиҗәнап мәзәк (дөрес, интриганың кайбер катнашучылары өчен ахыры шактый күңелсез тәмамлана) идарә иткән спектакль бик оста язылган. Монда тормыш картиналары үткен театраль провокация көзгесендә чагылыш таба. Җәүдәт Фәйзинең Таҗи Гыйззәт либреттосына язылган «Башмагым» музыкаль комедиясендә вакыйгалар агышы энә шундый. Һәм болар барысы да искиткеч музыкага үрелеп бара. Драма актёрлары башкаруында нәфис музыкаль партияләр сәхнәдәге вакыйгаларга мәхәббәт тарихлары өчен мәҗбүри булган романтик рух өсти. Вакыйгалар урыны – Казан. Заманы – XX гасыр башы һәм бүгенге көн. Тиздән – Сабан туе...

25 март, 19:00 сәг. тә, Зур зал
Г. Камал исем. Татар дәүләт Академия театры
Казан, Татарстан ур., 1

ВАРИСЛАР: XIX ГАСЫР КЛАССИКЛАРЫННАН XXI ГАСЫР КЛАССИКЛАРЫНА КАДӘР (0+)

Күргәзмә ике гасыр дәвамында сәнгать традицияләренең өзелмәвен, аның үсешен күзәтеп, сәнгать дөньясына чумуның уникаль мөмкинлеген бирә. Тамашачы, XIX–XX гасырларның һәм XXI гасырның танылган рәссамнарының эшләре белән танышып, үткән заман осталарының идеяләре һәм техникасының бүгенге осталарга ничек йогынты ясавын күрә ала. Экспозиция сәнгатьтә төп темаларны чагылдырган җиде бүлекне үз эченә ала: мифология, шәһәр, пейзаж, жанр күренешләре/интерьер, натюрморт, тарих, портрет. Күргәзмә – иҗади ысуллар эволюциясе үрнәге, сәнгать медиумнарының күптөрлелегенә ачык дәлил. Бу рәсем сәнгатеннән һәм графикадан цифрлы сәнгатькә һәм интерактив инсталляцияләргә кадәр чагылыш тапкан.

Көн саен 10:00 дән 18:00 сәг. кә кадәр (җомга – 11:00 дән 20:00 гә кадәр)
Кабул итү урыннарының Күргәзмә заллары
«Казан Кремле» музей-тыюлыгы

«АК ҖИЛКӘННӘР» (0+)

Фәрит Яруллинның «Шүрәле» балетыннан Анданте, Александр Ключаревның «Туган җирем – Татарстан», Мансур Мозаффаровның «Җиләк җыйганда», Сара Садыйкованың «Вальс турында вальс», Фасил Әхмәтовның «Күрешербез әле», Рөстәм Яхинның «Җырланмаган әле безнең җыр»... Татар композиторларының әлеге һәм башка искиткеч матур әсәрләре Татарстанның халык артисты Владимир Васильев җитәкчелегендәге Филармония музыкаль-әдәби лекторие кысаларында оештырыла торган «Ак җилкәннәр» концерт программасына кертелгән. Биредә милли музыканың алтын фондына караган җырлар, романслар, арияләр, көйләр белән ләззәтләнеп кенә калмыйча, Татарстан Республикасы музыкаль мәдәнияте вәкилләренең тормышы һәм иҗаты турындагы тарихларны да тыңларга мөмкин булачак.

25 март, 18:30 сәг. тә
Г. Тукай исем. Татар дәүләт филармониясе
Казан, Павлюхин ур., 73

ай кәефе: бәйрәмә

Фотолар «Татэнерго» компаниясенең матбугат хезмәтеннән алынды

ГҮЗӘЛЛЕК ҺӘМ ОСТАЛЫК АЛИҺӘЛӘРЕ

Кайчандыр телевизордан барган «А ну-ка, девушки!» тапшыруын совет гаиләләре көтеп ала һәм бергәләп рәхәтләнеп карый иде. «Татэнерго» компаниясендә шул иске бәйгене яңа форматта үткәрергә булганнар һәм һөнәри осталык, гүзәллек, иҗат конкурсы уйлап тапканнар. «Җитештерү энергиясе: хатын-кыз карашы» дип аталган бәйге Яр Чаллы җылылык электр үзәгендә (ҖЭҮ) уздырылды.

Конкурста катнашу шартлары гади: җитештерүдә шактый вакыт эшләү тәҗрибәсе булу, актив тормыш позициясе һәм үзеңне камилләштерүгә омтылу.

«Татэнерго» филиалларында эшләүче конкурсантлар сәхнәдә һөнәри осталыкта ярышты:

- «Татэнерго» тарихына һәм аның бүгенгесенә, хезмәтне саклауга һәм сәнәгать куркынычсызлыгына багышланган блиц-викторина сорауларына җавап бирделәр;
- һөнәргә кагылышлы төшенчәләрне һәм телне яхшы белүдә көч сынаштылар;
- хезмәт урынында «зыян күрүчегә» медицина ярдәме күрсәттеләр;
- гидрантка һәм брандспойтка янгын сүндерү шлангларын тоташтырдылар...

Тагын әле хатын-кызлар җыр-биюгә осталыкларын да күрсәттеләр, үзләренең яраткан шөгыльләре турында да сөйләделәр. Залда һәркайсының җанатарлары утыра. Алар үз вәкилләрен алга чыгарырга, рухландырырга тырыштылар, шуңа алкышлар, кычкырып хуплаулар бер дә тынып тормады.

– Мин ышанам, монда җиңелүчеләр булмаячак, – дип тынычландырды аларның барысын да «Татэнерго» АҖ генераль директоры Рәүзил Хаҗиев. – Һәркайсы беренче булырга лаек. Шуңа күрә мин үземнең жюрида утырмавыма сөенәм әле, югыйсә ничек сайлар идем... «Татэнерго» компаниясенең бердәм коллективында 2073 хатын-кыз эшли, һәм шуларның иң уңганнары – бүгенге сәхнәдә. Сез безнең дә, үз коллективларыгызның да кәефен күтәрәсез.

Житәкче фикеренчә, язның беренче бәйрәменең хатын-кызларга багышлануы символик мәгънәгә ия:

– Безнең һәркайсыбыз өчен хатын-кыз – гомер бирүче ул. Кешенең бөтен тәрбиясе дә, бигрәк тә сабый чагында, әнисеннән килә.

Рәүзил Хаҗиев үзенең күп балалы гаиләдә үсүе һәм әнисенең ял иткән чагын хәтерләмәве турында сөйләде:

– Ул бер дә тик тормый иде: барыбызны да ашата, киендерә, мәктәпкә озата... Мин аның йоклаган вакытын бер дә күрмәдем. Безнең бәйгедә катнашучыларыбыз да нәкъ шундыйлар! – дип, генераль директор барлык хатын-кызларны 8 Март белән тәбрикләде һәм бу бәйрәмнең Россиядә аеруча хөрмәт белән уздырылуын искәртте.

РЕКЛАМА



Ольга Сухачева (Яр Чаллы ҖЭҮ) – станциянең пар казаннары цехында 5 нче разрядлы машинист. Ул – Яр Чаллы ҖЭҮндә Сухачевларның өч буынлык данлы династиясе вәкиле. Ольга энергетикага әтисе Николай Сергеевич үрнәгендә килә, ул кызын бик кечкенә чагыннан ук бөтен демонстрацияләргә, шимбә өмәләренә үзе белән йөртә, шимбә саен станциягә эшкә алып килә. Ольга 18 яшеннән Яр Чаллы ҖЭҮндә эшли, бүген пар казаннары цехындагы гаять зур агрегатлар аның карамагында.



Светлана Акатьева (Зәй ГРЭС) – ягулык цехының һава бүлү аппаратчысы. Аның тормыш девизы: «Кыю, тәвәккәл булырга һәм һәрвакыт эшләргә. Кечкенә адымнар белән булса да, куелган максатка таба барырга! Шул очракта гына уңышка ирешеп була». Һәм менә инде 28 ел рәттән ул уңышлы эшли. Спортчы, тынгысыз, гүзәл Светлана иптәшләре белән бергә «Керәшен кызлары» халык җырының авторлык кавер-композициясенә дәртле бию башкарды.

Татьяна Гайфуллина (Казан ҖЭҮ-1) – химия цехының иң яхшы химик анализ лаборанты. Һөнәре төгәллек һәм вак-төяккә игътибарлы булуны таләп итә. Гигант турбиналарның өзлексез эшләве аның көндәлек хезмәтенә бәйле. Тагын әле Татьяна – Казан ҖЭҮ-1 станциясендәге Гайфуллиннар династиясе вәкиле. Бергә аның ире Руслан эшли, кайнатасы белән кайнанасы да озак еллар монда хезмәт куйган. Татьяна фәнгә һәм рационализаторлыкка гашыйк. Аның тормыш кагыйдәсе: «Һәрвакыт янып яшәргә!»

Татьяна Степанова (Казан җылылык челтәрләре) энергетикада һәм нәкъ менә җылылык челтәрләре предприятиеләрендә инде 27 ел эшли. Үзенең фильм-презентациясендә ул практикантның остазы ролендә уйнады һәм аны Казан җылылык челтәрләрендә эшкә калырга күндерде. Моның өчен практикантка үзенең дә кайчандыр «таулар күчерү» нияте белән предприятиегә килү тарихын сөйләп бирде.

Ләйсән Соколова (Түбән Кама җылылык челтәрләре) – квартал эчендәге җылылык челтәрләреннән файдалану хезмәтенең җылылык пункты операторы. Спортчы. Кыю. Кабатланмас. Спортның экстремаль төрләрен ярата. Ул нәфис-чандыр гәүдәдә дә теләсә кайсы киртәләрне җимерергә сәләтле чын көч яшеренә алуына мисал булып тора.

Василиса Максакова (Казан ҖЭҮ-1) – «Савиново» пар казаннары бинасының 3 нче разрядлы су әзерләү аппаратчысы. Авиация буенча белем алса да, ул үз юлын энергетикада тапкан. Конкурста исә тамашачыларны кызы Марина белән бергә җырлап таң калдырды. Ул үз кызының остазы да булып тора. Бүген алар «Савиново» пар казаннары бинасының суны химик чистарту төркемендә әниле-кызлы икәү эшлиләр.

Ирина Куцева (Яр Чаллы җылылык челтәрләре) – электр хуҗалыгы һәм элемтә хезмәтенең сынаулар һәм үлчәмнәр буенча 4 нче разрядлы электромонтеры. Аннан электр тогы гына түгел, шәһәрдәге... тәртип бозучылар да курка. Чөнки ул – предприятиенең халык дружиннигы һәм хезмәтне саклау буенча вәкиле! Ирина шулай ук корпоратив иҗат конкурсларында һәм ату спорты, чаңгы ярышларында актив катнаша. Инде 30 елдан артык үзенең хезмәте белән энергетиканың хатын-кызлар һөнәре дә булуын раслап килә.



Ризида Алимова (Түбән Кама ГЭС) 25 ел элек гидроэлектростанциянең төп идарә пультына кизү электромонтеры булып килә һәм бүген дә шунда эшли. Ә пандемия вакытында алар ире белән яңа туган сабыйны кызлыкка ала. Аннары Ризида Чаллыда тагын өч ятимне әниле итүдә булыша. Аның тормыш девизы: «Һәрвакыт үзең булып кал! Беркайчан да бирешмә! Гел алга!»

Роза Нургатина (ТатАИСЭнерго) – күпкырлы шәхес. Эшендә ул телефон аппаратларын көйләү һәм ремонтлау белән шөгыльләнә, Зәй ГРЭСы белән «Татэнерго» бүлекчәләрен тоташтыра. Буш вакытында Роза фотография белән мавыга һәм хәтта Гомумроссия фотоконкурсында да җиңә. Мәккәгә хаҗга бара. МХО сугышчылары өчен маскировка ятьмәләре үрә, өч инвалидны кайгырта. Роза Нургатинаның тормыш кагыйдәсе оптимистик рухта: «Кирәк икән, планнарны үзгәртү – соң да, иртә дә түгел!»

Об'явление работы худ. Л. Гамбургер.

«Татарстан» журналының реклама бүлеге:

тел.: (843) 222-09-79, 8-9600-487-900, 8-9033-132-741

Реклама 16+